ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№09 (404)
СЕНТЯБРЬ 2025

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

РОССИЯДӘ ИСЛАМ ФИНАНСЛАРЫ ЭКОСИСТЕМАСЫН КЕМ ТӨЗИ

4 612750 670011

Реклама. «ХАЛЯЛЬНОЕ РЕШЕНИЕ» ЖЧҖ

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Татар утары:
Реклама 16+

№09 (404)
СЕНТЯБРЬ 2025

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Олеся Бондаревская, Фәнзилә Җәүһәрова, Айдар Шәйхин, Әхмәт Шакиров
Фотографлар: Александр Ефремов, Евгения Чеснокова, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Ислам Әхмәтшин, HalalGard проекты авторы. Александр Ефремов фотосы
Редакция фотога төшерү урынын тәкъдим иткәне өчен Башир Рәмиев исемендәге IT-паркка рәхмәтен белдерә.

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: М-1792
Басарга кул куелды: 15.09.2025
Чыгу көне: 19.09.2025

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900

Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

ГОРУРЛЫК ҺӘМ ӨМЕТ ВАКЫТЫ

Көзен халыкта күңел төшенкелегенә бирелү еш очрый, кайчакларда ул хәтта депрессиягә кадәр җиткерергә мөмкин. Табигать белән бергә безнең күңелләрдәге җәйге бакчалар да сула, диярсең. Нишлисең, яшәеш кануннары шундый, аларны без уйлап чыгармаган. Без бу кануннарга бары тик буйсына гына алабыз.

Шулай да «Татарстан» көзге мифларны куып тарату миссиясен үз өстенә алырга булды. Чөнки без ышанабыз: журналның әр-яңа саны укучы кулына килеп керү белән... көзге төшенкелекне юып алгандай булачак! Менә күрерсез! Журналны чыгаручылар бу алымны әле безгә кадәр үк, ягъни 1920 елдан бирле кулланган! Һәм ул үзен һәрчак аклап килгән...

Безнең эшебез шундый: ел фасылларының үзгәреп торуына һәм табигать катаклизмнарына карамастан, әллә каян, тирән төпкелләрдән тарихлар казып чыгару, аларны журнал укучысына җиткерү. Бу тарихлар, үз чиратында, көзге моңсулыкны томан кебек эретә, туган республикабыз – Татарстаныбыз өчен горурлык хисләре уята. Халкыбызны яратырга бик күп сәбәпләр барлыгын күрсәтә, һәрчак шуңа өндәп тора...

Бүген нәкъ менә шундый вакыт – горурлык хисләренә урын биреп, алга өмет белән карый торган!

Әйдәгез, шулай итәбез!

Сезнең күңел төшенкелегенә бирелмәүче редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2026 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1998 сум 00 тиен китереп бирешле,
1939 сум 20 тиен соратып алганда.
2026 елга ТР буенча язылу бәясе:
3995 сум 90 тиен китереп бирешле,
3878 сум 29 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 104 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

барысы тик татарстанда

ЙӨРӘКТӘН – ЙӨРӘККӘ

1995 елның сентябрендә катлаулы йөрәк авыруы (порок сердца) белән туган 25 Татарстан сабые Стэнфорд университеты (АКШ) табибларының пациентына әйләнә. Казанга табибларны режиссёр Родион Нахапетов белән аның хатыны Наталья Шляпникофф алып килә. Бу гаилә оештырган хәйрия фонды Татарстанга шулай ук ике миллион ярым долларга төшкән медицина җиһазлары китертә, операцияләрне һәм кардиологларның ике якка да юл чыгымнарын түли.

Безнең республикада ике атна эчендә Америка хирурглары йөрәккә гаять катлаулы 19 ачык операция уздыра. Операциядән тыш, 11 коррекция ясый, тумыштан йөрәкләре сырхау булган 160 баланы тикшерә. Эшләрен тәмамлагач, Америка кардиохирурглары кире кайтып китә. Аппаратура белән медикаментларны Казанда калдыралар – балалар хастаханәсенә бүләк итәләр.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

8. Триллион кайда яшерелгән
Ислам финанслары базарының киләчәге нинди

12. Цифрлы форматтагы хәләл
Хәйрияче булырга нәрсә булышыр

22. Кояш астындагы урын
Бизнес кайда яхшырак үсә

24. XXI гасыр Ефәк юлы
«РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» форумы нәтиҗәләре

30. Илләр арасындагы элемтәләр
Логистика Россия белән Кытайны ничек якынайта

36. Милли мәдәният
Казан циркы безне нәрсә белән гаҗәпләндерде

игелекле эшләр

42. Гамьле әңгәмә
Рәшит Кәлимуллинның коллекциясендә ничә уен коралы бар

46. Коеп яуган яңгыр астында
Ни өчен без һәр елны «Крутушка»га барабыз

52. Редакция кухнясы
Китап белән алма бәлеше арасында нинди уртаклык бар

58. Күршең үзеңнән начар булганда...
Хәзерге заман «плюшкиннары» кайда яши

мәңгелек кыйммәтләр

64. Онытылмас исемнәр
Закир Гали татар тарихында нинди эз калдырган

68. Китап киштәсе
Миләүшә Хәйруллина нинди китаплар укый

70. Әдәбият сөючеләр фестивале
Балалар китабы дөньясы ничек үзгәрә

76. Татарстан авыллары
Уракчы авылының үзенчәлеге нәрсәдә

88. Казанның агач архитектура һәйкәлләре
Берлянд-Филипсон йорты ничек сакланган

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

Фото: vestnik.icdc.ru

Акыллы гамәлләр

08.08

Солтан Ибраһим, Малайзия короле, – Казан Кремлендә, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очрашуда:

« – Безнең үзара икътисади хезмәттәшлекне ныгытуның, нефть химиясе, инновацияләр, ислам финанслары һәм хәләл секторда эшчәнлек алып баруның зур потенциалы бар. Ике илнең югары уку йортлары арасында академик алмашулар киңәя бара. Россия һәм Малайзия арасында авиаюнәлешләрнең яңадан эшли башлавы өмет уята. Бу туризм һәм коммерция өчен яңа юллар ача. Малайзиядә Татарстаннан килгән туристларны һәм студентларны күбрәк күрермен, дип өметләнәм. Сезнең республикага сәфәрем Малайзия белән Татарстан арасында элемтәләрне ныгытуга яңа этәргеч бирер, дип чын күңелдән ышанам.

13.08

Татьяна Покровская, синхрон йөзү буенча Россия җыелма командасы тренеры:

« – Татарстанның спортта ни дәрәҗәдә алга китүен мин башкаларга караганда күбрәк беләмдер. Нәтиҗәләр – әгәр алар бар икән – болай гына тумый, чөнки моның өчен үз командаларын, Россия спортчыларын, халыкара мәйданнарда югары казанышларга ирешеп чыгыш ясарлык итеп әзерләрлек кадрлар җыелган.

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр



15.08

Александр Ширманов, сценарист, режиссёр, – Казанда рәссам Александр Родченконың тормышы турында фильм төшерер алдыннан*:

« – Киноны милли яисә башка берәр билге буенча түгел, кеше йөрәгенә үтеп керерлек итеп төшерергә омтылырга кирәк. Тамашачыга ошый торган яхшы фильмның нигезендә гадел, бик күпләр өчен кызыклы, кеше анда үзен таба алырлык тарих ята. Кино бернәрсәгә дә өйрәтергә тиеш түгел. Иң күп дигәндә, тамашачы җавабын үзе эзләрлек сораулар куярга яисә кешене күркәм гамәлләргә илһамландырырга мөмкин.

** «Бизнес Онлайн»га әңгәмәсендә*

Фото: tatarstan.ru, russwimming.ru, vk.com/shirmanov

игелекле эшләр

акыллы гамәләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Партнёрлык финанслары базары **ничә** триллионга артачак

Россиядә ислам финанслары экосистемасын **кем** төзи

Бизнес алып бару өчен иң яхшы шартлар **кайсы** Россия төбәгендә тудырылган

Логистика Россия белән Кытайны **ничек** якынайта

Чэнь Цзиньсинь әфәндене **ни өчен** Игорь дип атыйлар

«МИН ЯРАТАМ СИНЕ, ТАТАРСТАН!»

Фото: tatar-inform.ru

30 август кичендә Татарстан күгендә бәйрәм салюты балкыды – Казан Республика көне белән 1020 яшьлеген тантаналы төстә әнә шулай билгеләп үтте. Купшы, затлы, бер үк вакытта эшлекле дә. «Ике Кремль» мотоярышы, «Җиңү армиясенә кушыл!» акциясе, Игенчеләр сарае янындагы раритет техника күргәзмәсе, күренекле татарстанлыларга багышланган мемориаль такталар ачылу, «Уйнагыз, гармуннар!» фестивале, Серов урамындагы яңартылган бульварны эшләтеп җибәрү һәм, әлбәттә инде, «Казан» Гаилә үзәге каршындагы концерт программасы... 30 август кичендә анда Татьяна Буланова сәхнә тотты...

Меңләгән казанлы һәм татарстанлы, шәһәр кунаклары хозурына әнә шулар тәкъдим ителде. Әлбәттә, санап үтелгәннәр – вакыйга һәм чараларның бер өлеше генә. Бу көнне республика Рәисе үзенең телеграм-каналына язып элгән сүзләрне һәркем кабатларга әзер булгандыр, хәтта кат-кат кабатлагандыр да, дип ышанабыз: «Мин яратам сине, Татарстан!»



ПАРТНЁРЛЫК ФИНАНСЛАРЫ.
АЛГАРЫШЛЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ЗАМАНЫ

Әхмәт Шакиров

Экспертлар бәяләвенчә, урта сроклы перспективада партнёрлык финанслары базары бер триллион сумга кадәр үсәргә мөмкин. Ислам банкингы буенча ике ел элек башланган экспериментны 2028 елның сентябренә кадәр озайту карары бу кыю фаразның тормышка ашарлык булуына ышандыра кебек.

Исегезгә төшерәбез, партнёрлык (ислам) финанслары буенча эксперимент 2023 елның сентябрендә Башкортстан, Дагыстан, Татарстан һәм Чечня территорияләрендә башланды. Законнар белән билгеләнгән ике ел, нигездә, илдә ислам банкингы продуктларына ни дәрәҗәдә ихтыяҗ булуын күрсәтергә тиеш иде. Өстәвенә, бу инструментларны әле, ким дигәндә, уйлап табарга, җиренә җиткереп эшләргә һәм базарга чыгарырга кирәк булды. Төрле дәрәҗәләрдә глобаль максат та аталды: ислам дөньясы илләреннән партнёрлык инвестицияләрен җәлеп итү.

ИХТЫЯҖ ҺӘМ ТӘКЪДИМ

Узган ике елда нәрсәләргә ирешелде соң? Татарстанда экспериментның беренче унике аенда гына да өч дистәдән артык партнёрлык продукты эшләнде, ә ислам банкингы буенча операцияләр күләме ике тапкырга артты һәм 3,6 миллиард сумга җитте. Күп кенә продуктларның базарга чыгуын исәпкә алсак, сан шактый саллы. Бизнес һәм гади гражданнар, әйтергә кирәк, мөселман булмаганнар да, экспериментның актив тарафдарлары фикерен расладылар: рибачылык процентлары һәм күзгә күренми торган башка каршылыклар булмаган гадел һәм үтә күренмәле партнёрлык (ислам) финанс инструментлары җәмгыятькә кирәк.

Ислам банкингын җәелдерүгә комачаулый торган проблемаларның да аз булмавы ачыклануы – икенче мәсьәлә. Әлегә дүрт төбәктә дә партнёрлык финанслары операцияләренең алгарышлы үсешенә ирешелмәде. Аерым алынган төбәккә караганда, ил күләмендәге уңышлар күпкә тыйнаграк булып чыкты, чит ил инвестицияләрен җәлеп итү турында да әле һаман киләчәк заманда сөйлибез. Алай гына да түгел, бүген РФ Үзәк банкы реестрына экспериментта катнашучы буларак теркәлгән 33 оешманың яртысы диярлек Татарстаннан, ә Дагыстан һәм Чечен Республикасы бүгенгә ике-өч оешма тәкъдим итә.

Хәер, бу тәүге ике елда реестрга теркәү үзе дә кимчелексез булмады. Югыйсә, теркәлгәннән соң бер ай узуга, мәгълүм бер банкның лицензиядән мәхрүм ителүен ничек аңлатып булыр иде....

Фото: tatar-inform.ru, ru.freepik.com

АЛГАРЫШ ЭТӘРГЕЧЕ

Ә кем җиңел булыр диде? Әле ике ел элек «Татарстан» журналы оештырган түгәрәк өстәлдә Россия ислам институты каршындагы Россия ислам икътисады һәм финанслары үзәге эксперты Руслан Хәлиуллин җитди каршылыкларның берсен атады:

– Халыкның финанс белеме – нульгә якын. Дини белемнәр – шул ук дәрәҗәдә. Һәм бер проблема икенчесенә өстәлә. Моңа каршы көчебез җиткәнчә көрәшәчәкбез. Бүген кеше күп нәрсәне бер бизмәндә генә үлчи: монысы – отышлы, ә монысы – отышсыз. Ә беренче урында хәләл яки хәләл түгел булырга тиеш. Моны аңлар өчен кешенең дә эчке дөньясы башка булырга тиеш.

Татарстанда хәләл финанс продуктларын куллануучыларның финанс грамоталылыгын күтәрүгә, мөгаен, ислам продуктларын эшләү һәм танытуга караганда кимрәк көч түгелмидер. Һәм моның белән дини структуралар гына шөгыльләнми. Аерым алганда, республика дин әһелләре һәм базарда катнашучылар белән бергә ислам финансларының бердәм порталы эшләнде. Анда уку-укыту материаллары һәм базарда катнашучыларның тәкъдимнәре бер цифрлы мәйданчыкка тупланды. Шуңа күрә Татарстан Республикасында ирешелгән уңышны күп очракта эксперимент өчен кирәкле оештыру эшләренең дөрес үткәрелүе белән аңлатып буладыр.

ҮСЕШ ЧИРЛӘРЕ. НИЧЕК ДӘВАЛАРГА?

Иң беренче хәл ителергә тиешле тагын бер бурыч – партнёрлык продуктларының ислам банкингы нормаларына туры килүен сертификацияләү. Татарстанда бу юнәлештә дә оптималь юл табылды. Шәригать нормаларына туры китереп сертификацияләүнең үтә күренмәле һәм уйланылган механизмын ТР мөселманнары Диния нәзарәте оештырды, һәм республикада эшләнелә торган яңа ислам финанслары продуктлары тиешле бәяләмә ала башлады.

Кызганыч, сертификатны ТР мөселманнары Диния нәзарәте генә бирми. Теоретик яктан дини структуралар тарафыннан сертификацияләнгән продукт көйләүче, ягъни Үзәк банк таләпләренә туры килмәскә дә мөмкин. Тагын бер нәрсә: безнең сертификатлар һәрвакытта, бөтен яктан инвестицияләр кертә алырлык илләрдә кабул ителгәннәргә туры килеп бетми... Эксперимент башында ук пәйда булган бу проблема ике ел эчендә тулысынча хәл ителеп бетмәде.

Хәер, партнёрлык финансларын гамәлгә кертүнең ике елында ачыкланган проблемалар, беренче уңышлар белән беррәттән, экспериментны дәвам итәргә кирәклекне дәлилләп торган аргументларның берседер, мөгаен. Шуңа күрә Федераль законда экспериментны төгәлләүнең яңа датасы (2028 ел) аталу белән бергә, үсеш чирләреннән котылырга ярдәм итәргә тиешле механизмнарның да билгеләнүе очраклы хәл түгел.

«АЛТЫН УРТАЛЫКНЫ» ЭЗЛӘГӘНДӘ

«Без бүген укучылар сыйфатында, партнёрлык финанслары инструментларын үстерә генә башладык, – дип аңлатты РФ финанс министры урынбасары Иван Чебесков экспериментны дәвам итү турындагы карарны кабул итәр алдыннан. – Эксперимент нәтиҗәләрен алганнан соң, без аны көйли торган карарларны бөтен ил буйлап таратырга әзер булачакбыз. Хәзерге вакытта ислам финанслары таянырга тиешле стандартларны билгеләү таләп ителә».

Партнёрлык финансларын дәвам итәргә рөхсәт биргән закон, ниһаять, бөтенесе өчен мәҗбүри булган уртак стандартларны билгеләргә ярдәм итәчәк. Экспертлар билгеләп үткәнчә, алда торган бурыч – партнёрлык финанс хезмәтләре күрсәтүнең дөрес һәм бердәм кагыйдәләрен формалаштыру, экспериментның үтә күренмәлелеген һәм җәлеп итүчәнлеген күтәрү, шул исәптән чит ил инвесторлары өчен дә.

ТАТАРСТАНДА ИСЛАМ ФИНАНСЛАРЫНЫҢ БЕРДӘМ ПОРТАЛЫ ЭШЛӘНДЕ, АНДА УКУ-УКЫТУ МАТЕРИАЛЛАРЫ ҺӘМ БАЗАРДА КАТНАШУЧЫЛАРНЫҢ ТӘКЪДИМНӘРЕ БЕР ЦИФРЛЫ МӘЙДАНЧЫККА ТУПЛАНДЫ.

«Кабул ителгән закон экспериментны тагын өч елга – 2028 елның 1 сентябренә кадәр дәвам итүне күздә тота. Экспериментта катнашучыларның мөмкинлекләре киңәя, кыйммәтле кәгазьләр белән идарә итү һәм үзара иминият операцияләре рөхсәт ителә», – дип аңлатты Федерация Советының Бюджет һәм финанс базарлары комитеты рәисенең беренче урынбасары Мухарбий Ульбашев үзенең газета-журналларга биргән комментарийларында.

Ихтимал, яңа документ, ниһаять, партнёрлык продуктларын сертификацияләү кебек үтә сизгер өлкәдә «алтын урталыкны» табарга ярдәм итәр. Партнёрлык финансларының бердәм стандартларын эшләү һәм раслау механизмнары кертелә, алар мәҗбүри тәртиптә Россия Банкы белән килештерелергә тиеш. Ислам банкингы стандартларын эшләү белән эре кредит оешмалары – экспериментта катнашучылар ассоциациясе тарафыннан оештырылган махсус комитет шөгыльләнәчәк. Шунысына аерым басым ясыйк: стандартлар дәүләт теркәве узарга тиеш түгел, әмма компетенцияләр өлешендә Россия Банкы белән килештерү мәҗбүри.

Эксперимент башланганда безнең басма оештырган түгәрәк өстәлгә тагын бер кат әйләнеп кайтыйк әле. Россия ислам инсти-

туты каршындагы Россия ислам икътисады һәм финанслары үзәге эксперты Руслан Хәлиуллин ул чакта болай дигән иде: «Ислам финанслары, гади тел белән әйткәндә, ул – кыйммәтле кәгазьләр, иминиятләштерү һәм банк. Кыйммәтле кәгазьләр – төп өлеш, беренче урында. Кыйммәтле кәгазьләрдән башка без пенсия фондын оештыра алмыйбыз. Алардан башка ислам кагыйдәләре буенча эшли торган инвестиция фондын, иминият компаниясен дә төзеп булмый. Һәм ахыр чиктә без банк та ача алмыйбыз. Ә аңардан башка алга хәрәкәт итү юк, һәм без, ихтыяҗ күпкә зуррак булган очракта да, дистәләгән миллион диапазонында гына эшләячәкбез».

Әмма ике ел эчендә «төп өлеш» проектта гына калды һәм бу һичшиксез нәтиҗәләрдә дә чагылыш таба. Ләкин хәзер күп нәрсә үзгәрер, дигән өмет бар. Яңа закон экспериментта катнашучыларга рөхсәт ителгән операцияләр һәм килешүләр исемлеген баетты. Хәзер ул исемлеккә шул исәптән кыйммәтле кәгазьләр белән идарә итү дә кертелгән.

ЦИФРЛЫ ЯҢАЛЫКЛАР ЗАМАНЫ

Мин өметле һәм гадел ислам банкингы идеясенең илебез киңлекләренә тараласына һәм партнёрлык финансларының базарда үз урынын табачагына ышанам. Әмма экспертлар тарафыннан билгеләнгән максатка – триллион сумлык партнёрлык финанслары базарына якынаю өчен тәкъдим ителгән продуктларның ислам нормаларына гына түгел, замана рухына да туры килүе шарт, дип уйлыйм. Чынбарлык бүген шундый: Малайзия, Индонезия, Якын Көнчыгыш илләре, шул исәптән Бәхрәйн, БГӘ, Катар һәм Согуд Гарәбстаны бүген цифрлы стратегияләр эшли.

Заманча финанс технологияләренең яңа мөмкинлекләре һәм җәлеп итүчәнлекләре экспертларның прагматик исәп-хисаплары һәм потенциаль клиентлар арасында үткәрелгән сораштыруларга нигезләнә. Бүген дөнья күләмендә яшь мөселманнарның 80 проценты үзләре өчен онлайн-банкинг вариантының хәлиткеч фактор булуы турында әйтә. Алай гына да түгел, 70 проценты, кем беләндер очрашмыйча гына инвестицияләр кертү мөмкинлеген мөһим, дип саный. Яшь мөселманнарның 80 проценты, үзләре өчен теләсә кайсы вакытта һәм урында банк хезмәтләреннән файдана алу принципиаль яктан мөһим, дип белдерә. Потенциаль кулланучы билгеләгән вектор, күргәнебезчә, төгәл шәйләнә.

ОЧРАШУ УРЫНЫ – ИНВЕСТПЛАТФОРМА

Онлайн-банкинг, акчалар ислам счетында саклангандa партнёрлык (ислам) исәп-хисап-касса хезмәте күрсәтү... Бу очракта клиент банк аның акчасын хәләл булмаган максатларга тотмаячагына ышана. Мондый цифрлы партнёрлык продуктлары Татарстанда экспериментның беренче елы ахырында пәйда булды. Шуның артыннан ук диярлек физик затларга беренче хәләл дебет карталары тәкъдим ителде. Бүген, әйтергә кирәк, теләге булганнарга мондый карталарны берничә банк бирә, шул исәптән Татарстаннан читтә дә. Алай гына да түгел, ТР мөселманнарының Диния нәзарәте экспертлары тарафыннан хупланып, рөхсәт ителгән һәм сертификацияләнгән хәләл кешбэклы дебет карталары да чыгара башладылар.

Һәм алай да югарыда аталган цифрлы продуктлар – тулысынча цифрлаштырылган партнёрлык необанкына яисә мөселманнарның яшь буыны хыялланган виртуаль, ягъни алар беркем белән дә шәхсән очрашмыйча гына инвестицияләр кертә алырлык мәйданчыкка таба ясалган мөһим, әмма шул ук вакытта әле шактый кыюсыз адымнар. Әмма өметсез түгел.

Чөнки бу юнәлештә әзер проект инде бар. Татарстанда берничә ай элек «Иннополис» резиденты тарафыннан беренче ислам инвестицион цифрлы платформасы төзелде. Оештыручылар билгеләп үткәнчә, аның бурычы – «инвесторларга һәм эшкуарларга шәригать кануннарына ярашлы рәвештә эшләргә һәм үз эшчәнлекләрен партнёрлык финанслары нигезендә оештырырга ниятләгән РФ, Якын Көнчыгыш илләре яисә башка илләрнең инвесторларыннан инвестицияләр алырга мөмкинлек бирә торган финанс чараларын тәкъдим итү».

Әлеге ислам платформасы эшчәнлегенең схемасы гади һәм аңлаешлы. Тиешле теркәүне һәм верификацияне узып, ихтимал булган инвестиция финанс куркынычлары белән танышып, сез платформа операторы белән килешү төзисез, аннан соң инвестицион мөмкинлекләрнең барысына да ия була аласыз. Алга таба – гамәли эшчәнлек. Платформада үзегезнең номиналь счетыгызны тутырып, мөмкин булган инвестиция тәкъдимнәре белән танышасыз, үзегезгә туры килгән,

мәнфәгатьләрегезгә җавап биргәнен сайлыйсыз. Һәм модарәбә, мөрабәхә, мөшарәкә яки сокук кебек финанс инструментларын кулланып, сайланган проектка акча кертәсез. Аннары платформада үз инвестициягезнең ничек эшләгәнен, аның нәтиҗәләрен даими күзәтеп торасыз. Инвестицияләр өчен проект тәкъдим итә торган компания яки шәхси зат гамәлләренең алгоритмы да шундый. Бу – проектны тәкъдим итү, акча җыю өчен туры килә торган финанс инструментын сайлау.

Платформаны уйлап табучыларның сүзләренә караганда, монда кулланыла торган инструментлар процент алуга, артык билгесезлеккә һәм спекуляциягә юл калдырмый, шулай ук акча югалту куркынычын һәм табышны гадел бүлүне тәэмин итә, өстәлгән бәя һәм кичектереп түләүне күздә тота, болар барысы да Ислам финанс учреждениеләренең бухгалтерлык исәбе һәм аудиты оешмасының (AAOIFI) шәригать стандартларына туры китереп эшләнә.

Платформаның үзенчәлеге – теләсә кайсы проектның реаль базар (гадел) бәясен ачыклау. Платформаны уйлап табучылар хәбәр иткәнчә, алар инвестицияләнүче компанияләрне алдан капиталлаштыру өчен үз методикаларын куллана, нәтиҗәдә компания активларының бәясе аның инвестицион потенциалы белән тигезләнә.

Инвестиция проектларының шәригать нормаларына туры килүенә килгәндә, монда күпфункцияле ислам инвестиция платформасы күпбаскычлы контроль системасын куллана. Беренчедән, җәлеп ителгән гыйльми совет катнашында инвестицияләр сорый торган компанияләр тикшерелә. Икенчедән, инвестиция проектлары үзләре дә шәригать нормаларына туры килү-килмәүгә аерым тикшерү уза. Кирәк булганда, ислам инвестицияләрен җәлеп итә торган компанияләргә инвестиция проектын аерып чыгарырга, аны чагылдыру өчен аерым бухгалтерлык балансы булдырырга, аерым банк счеты ачарга һәм ислам инвестицияләрен җәлеп итә торган инвестиция проектын башка эшчәнлектән «аерып» торучы башка гамәлләр башкарырга киңәш итәләр.

Ислам инвестицияләрен җәлеп итүче компанияләр, аларның инвестиция проектлары, шулай ук көтелгән нәтиҗәләр AAOIFI халыкара стандартлары нигезендә тикшерелә, алга таба барысы да платформада чагылыш таба.

КРАУДФАНДИНГТАН БЛОКЧЕЙН ҺӘМ НЕОБАНККА КАДӘР

Ислам банкингы һәм партнёрлык финансларының ике елга якын вакыт эчендә пәйда булган цифрлы продуктлары турында сөйләгәндә, советлардан соңгы киңлекләрдә аларның берничә ел элегрәк барлыкка килүен дә искә төшерик. Аерым алганда, Россиянең PayZakat компаниясе әле биш ел элек үк зәкят җыю һәм бүлү платформасын эшләгән иде, ул проектларга юнәлтелгән акчаларның дөрес кулланышын күзәтергә мөмкинлек бирә.

Якынча шул ук вакытта Үзбәкстанда ислам финанслары принципларында сатучыларны, сатып алучыларны һәм инвесторларны берләштерә торган IMAN сәүдә мәйданчыгы эшли башлады.

Әмма ни дисәк дә, бүген дөньяда ислам финанс технологияләре буенча танылган үзәкләр башка илләрдә урнашкан. Якын Көнчыгышта бу – Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Көньяк-Көнчыгыш Азиядә – Индонезия белән Малайзия. Тиз үсеш алган өлкәләр арасында – тигез хокуклы (яки бер ранглы) финанслау (банклар һәм инвестфондлар кебек традицион арадашчыларны җәлеп итмичә) һәм хәйриячелек, бу мөселман кыйммәтләренә тулысынча туры килә.

Күрәсең, партнёрлык финанслары өчен финанс хезмәтләре бәяләрен түбәнәйтергә, халыкара акча күчерүләрне тиз арада, арзанга башкарып чыгарга сәләтле блокчейн-технологияләр дә тыелмаган. Хәер, хөкүмәтләрнең блокчейнга һәм криптовалюталарга мөнәсәбәте билгеле сәбәпләр аркасында бер генә төрле түгел.

ЭКСПЕРИМЕНТТА КАТНАШУЧЫЛАРНЫҢ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ КИҢӘЯ БАРА, ҮЗАРА ИМИНИЯТ ҺӘМ КЫЙММӘТЛЕ КӘГАЗЬЛӘР БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ ОПЕРАЦИЯЛӘРЕ РӨХСӘТ ИТЕЛӘ.

Хәйрия өлкәсендә кулланыла торган ислам финанс технологияләре – икенче мәсьәлә, анда цифрлы карарлар рәхәтләнеп эшли. Иң танылган ислам краудфандинг платформаларының берсе – Америкадагы LaunchGood, аның ярдәмендә ун ел эчендә дөньяның 150 илендәге 890 мең мөселманнан 30 меңнән артык хәйрия проектын гамәлгә ашыруга 250 млн доллар җыелган.

Татарстанда заманча технологияләрне, финанс карарларын һәм рухи кыйммәтләрне берләштерә алган компанияләр арасында HalalCardны атап була. Танылган бер банк белән хезмәттәшлектә ул кешбэклы хәләл дебет картасы базасында мобиль кушымта булдырды, аннары «Минем мәхәллә» системасын формалаштырды. Нәтиҗәдә мәчетләргә ярдәм итү буенча яңа технологик карарлар кабул ителде. Хәзер мәчетләрдә урнаштырылган сәдакамат дисплейларында намаз вакыты, мөселман календаре һәм иганә акчасын тиз арада күчерү өчен QR-кодлар чагылыш таба.

Бүген компанияләр партнёрлык финанслары өлкәсендә яңа цифрлы чишелешләр эшләү белән мәшгуль. Проектлар төрле, миссия бер – мөселманнарга макроикътисадта да, гаилә икътисадында да шәригать принциплары нигезендә яшәргә ярдәм итү.

HALALCARD:
ТАТАР ЭШКУАРЛАРЫ РОССИЯДӘ ИСЛАМ ФИНАНСЛАРЫ ЭКОСИСТЕМАСЫН НИЧЕК ТӨЗИ

Наилә Хәйретдинова

Соңгы елларда «финанс технологияләре» сүзтезмәсе көнкүрешебезгә шактый тирән үтеп керде. Цифрлы технологияләр тормыш рәвешен үзгәртә, әмма иман, намуслылык һәм якыннарыңа булышу татар мәдәниятенең нигезендә һәрвакыт сакланып кала. Бүген бу кыйммәтләр заманча яңгыраш ала. HalalCard – Россиядә ислам принципларын һәм инновацияләрне берләштергән беренче проект. Ул финанс продукты гына түгел, яңа гасырда мәхәллә системасының кабат торгызылуына, үтә күренмәлелеккә һәм байлыкларның гадел бүленешенә таба бер адым да.

Проектның авторлары – Казан эшкуарлары Ислам Әхмәтшин һәм Тимур Хәкимов. Максатлары – финанс технологияләренең заманча инструментларын кулланып, тормышыбызга үзара ярдәмләшү, гаделлек кыйммәтләрен кайтару: сәдакаматлардан алып, вакуф-вендингларга кадәр, мәчетләргә ярдәм итүдән алып, яшьләрне иганәчелек культурасына җәлеп итүгә кадәр. HalalCard – дини принципларны икътисадый нәтиҗәләлек белән берләштерү мөмкинлегенең бер үрнәге.

Бу юлның нәрсәдән башланганын, нинди сынаулар узарга туры килгәнен һәм үзара ышаныч белән ачыклыкның бүген ни өчен төп капиталга әверелүен белер өчен, без проектка нигез салучылар белән очраштык.

– Бүген цифрлы сервислар, экосистемалар, финтех турында күп сөйлиләр. Әмма сезнең очракта бу сүзләр артында бизнес-идея генә түгел, ә күпкә тирәнрәк фәлсәфә ята. Проектның чишмә башы кайда?

– Чыннан да, безнең юл технологияләрдән башланмады. Татарларның гореф-гадәтләрен искә төшерсәк, кайчандыр һәр авылда кешеләр зур мәхәллә булып яшәгән: бергәләп йортлар салганнар, бөтен урам җыелып мәчет төзегәннәр, мохтаҗларга ярдәм кулы сузганнар. Хатын-кызлар барысына да берьюлы ашарга пешергән, балалар биек коймаларның ни икәнен дә белми үйнаган, беркем дә ялгыз калмаган.

XIX гасыр татар сәүдәгәрләре – Апанаевлар, Яушевлар, Галиевлар, Үтәмешевлар һ.б. ны искә төшерик. Алар бөтен Россия буйлап һәм аннан читтә дә сәүдә иткәннәр, әмма бу сәүдәгәрләрнең көче акчада гына булмаган. Алар мәчетләр, мәдрәсәләр төзеткән, мәктәп һәм хастаханәләр тоткан, ярлыларга ярдәм иткән, китаплар бастырган. Аларның байлыгы бөтен өммәтнекенә әйләнгән.

– Ә XX гасырда әлеге үзара ярдәмләшеп яшәүгә нәрсә булды соң?

– Совет чоры сынаулар алып килә. Мәхәлләләр көчсезләнә, күп мәчетләр ябыла. Кешеләр һаман да бер-берсенә булышып яши, ләкин бу инде та-

Фото: dumrt.ru. «ХАЛЯЛЬНОЕ РЕШЕНИЕ» ЖЧЖ. РЕКЛАМА

выш-тынсыз, гаиләләр арасында гына эшләнә. Без игелекле гамәлләрдә ачыклыктан мәхрүм калсак та, ярдәмләшү рухын югалтмадык. Һәм бүген, заманча технологияләргә таянып, нәкъ менә шушы рухи мирасны яңартырга телибез.

– Һәм бу яңарышны сез үз проектыгыз белән бәйлисезме?

– Нәкъ шулай. Элеккеге кебек мәхаллә булмаган, һәркем үз фатирында бикләнеп яши торган зур шәһәрдә мөселманнарны ничек берләштерергә дигән сынауга тарыдык һәм, хәзер мәхаллә цифрлы була бит, дип уйладык. Безнең сервислар: HalalCard, мәчетләрдәге экраннар һәм сәдакаматлар, имам өчен цифрлы ярдәмче, хәләл сканер, белем бирү сервислары, вакуф-вендинг аппаратлары – болар кайчандыр мәхаллә башкарганнарны тормышка ашыра торган инструментлар булып тора. Алар кешеләрне берләштерә, мәчетләргә ярдәм итә, һәркемгә игелекле эшләрдә катнашырга мөмкинлек бирә.

– Әлеге идея ни рәвешле конкрет проектка әйләнде?

– Барысы да безнең «Халяльное решение» компаниясендәге эшчәнлектән башланды. Эшләнмәләребезне күреп алган «Ак Барс Банк» безгә: «Сез клиентларны кызыксындыра беләсез, ә ислам карталары өчен хәләл кешбәк ясый алыр идегезме?» – дип мөрәҗәгать итте. Гадәти ислам карталары «буш» иде: картада калган акчага процент алу тыела, бонуслар юк, банк кешбәгы шәригать тарафыннан тыелган. Шуннан соң без кешбәк банктан түгел, ә шәригать принциплары кысаларында эш алып барган кибет һәм сервислардан кайтарыла торган карта ясарга тәкъдим иттек.

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм Голәмәләр шурасы белән берлектә, без кешбәк исәпләү механизмын эшләдек. Ул, ислам финанс нормаларына тулысынча туры килә дип, рәсми хуплау тапты. Бу – Россиядә һәм, мөгаен, дөньяда да мондый төрдәге беренче тәҗрибәдер.

– Ислам карталарының популярлыгын арттыра алдыгызмы?

– Башта продуктның популярлыгы артмады. Без базарны өйрәндек, тикшердек һәм шуны аңладык: Россиядә әлеге продуктларны кулланырга тиешле максатчан аудитория еш кына гадәти карталардан файдалана, чөнки шәригать кануннарын бозам дип уйламый. Шул ук вакытта базарда башка ислам продуктлары да бар иде, алар да халык арасында киң таралмаган.

Без шундый нәтиҗәгә килдек: массакүләм ихтыяҗ тудыру өчен я колачлы маркетинг кампаниясе уздырырга, я аңлату эшләре алып барып, гадәти банк кешбәкларының ни өчен шәригатькә туры килмәвен һәм ни өчен акчаларны «хәләл» саклауның мөһим булуына төшендерергә кирәк.

Стартап өчен бу табышлы юл түгел, вакыт ягыннан да чыгымлы. Димәк, кулланучыларның реаль «борчу»ларын хәл итә һәм бер үк вакытта масштаблана торган продукт булдырырга кирәк. «Борчу»ларның асылы банкта түгел, ә мәчетләрнең социаль инфраструктурасында иде.

– Тирәнрәк өйрәнә башлагач, нәрсәгә юлыктыгыз?

– Без мәчетләрнең һәм мөселман учреждениеләренең финанс процесслары мәсьәләсендә артта калганын күрдек. Сәдака акчалары йозаклы металл тартмаларга җыела яки имамның шәхси картасына онлайн күчерелә. Бу исә уңайсызлык тудыра, акчаның кая китүендә, нәрсәгә тотылуында үтә күренмәлелек тә югала.

Шул ук вакытта күп кеше карта белән яки мобиль кушымта аша түли. Без хәйрия өчен заманча ысул уйлап табарга мөмкин булуын күрдек. Сәдакамат цифрлы панельдән гыйбарәт. Анда намаз вакыты һәм һиҗри календарь гына күрсәтелеп калмый, барлык популяр түләү системалары аша, тиз, куркынычсыз һәм ачыктан-ачык күзәтерлек итеп, сәдака да бирергә мөмкин.

Шул рәвешле без, сәдака бирү йоласын заманча технологияләр белән берләштереп, мәхаллә мәчетләренә ярдәм итүнең уңайлы һәм үтә күренмәле ысулын тәкъдим иттек.

– Әңгәмәдә гел «мәхаллә» сүзен искә аласыз. Укучыларыбызның күбесе өчен ул, матур яңгырашлы сүз генә булып, ахыргача аңлашылып бетмидер. Хәзергә кеше өчен мәхаллә нәрсәне белдерә?

– Мәхаллә – мөселман каласының яисә авылының йөрәге ул. Аерым бер квартал гына түгел, ә уртак кыйммәтләр белән бәйле кешеләр берлеге. Ислам мәдәниятендә үзара ярдәмләшү һәм ышаныч галәме булып тора. Мәхалләдә һәрвакыт имам, мәчет, мәктәп булган, хөрмәтле аксакаллар һәм биредә тәрбия күреп үскән яшьләр иңгә-иң яшәгән. Әгәр гаиләдә бәби туа икән, күршеләр бергә шатланган, әгәр кемдер авырып китә икән, барысы да ярдәм кулы сузган, туй яки җеназа була калса, беркем дә читтә калмаган. Бүген, зур шәһәрдә яшәгәндә, бигрәк тә күченеп килгән булса, кеше еш кына үзен ялгыз хис итә. Без цифрлы сервислар, мәчетләр, уртак игелекле эшләр аша мәхаллә бердәмлеге хисен кайтарырга телибез. Бу – гасырлар дәвамында сыналган иске принципның яңа формасы.

– Мәхалләдә хөкем сөргән җылы мохитне заманча технологияләр аша кайтарырга мөмкинмени?

– Мөмкин дә, кирәк тә. Технология асылда салкын, әмма без аңа җылылыкны үзебез өстибез. Безнең сервислар сүз өчен генә «цифрлы» түгел. Мәсәлән, бүген теләсә кайсы кеше, төймәгә бер тапкыр басып, сәдака бирә һәм акчасының нинди ихтыяҗларга тотылганын белә ала. Хәтта туган шәһәреннән еракта яшәүче студент та мобиль кушымта аша мәчет тормышында катнаша, имамның үгет-нәсихәтләрен тыңлый һәм җәмгыятькә ярдәм итә ала. Әбиегезнең баланы йоклатыр алдыннан дога укыганын исегезгә төшерегез әле, бүген

БҮГЕН ИНДЕ СИСТЕМАГА РОССИЯНЕҢ 8 ТӨБӘГЕНДӘ 53 ТӘН АРТЫК МӘЧЕТ ҺӘМ 10 ИСЛАМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ТОТАШТЫРЫЛГАН. **ҺӘР АЙ САЕН HALALCARD АША 1 МЛН СУМНАН АРТЫК СӘДАКА БИРЕЛӘ**, ШУЛАРНЫҢ ЯРТЫСЫ АВТОМАТ РӘВЕШТӘ АЛЫНА.

без һәр гаиләгә рухи якынлык хисе бирә алабыз – хәтта телефон аша да.

– Димәк, туган йортыннан киткән кешеләр дә үз авылларындагы мәчеткә булышлыгын дәвам итә ала?

– Әйе, нәкъ менә шул мөһим дә. Хәтта йөзләрчә чакрымнар аерып торганда да, күп кенә кулланучылар өчен ул – үз тамырларыңа якынрак булу ысулы. Цифрлы мәхалләнең мәгънәсе шунда: ул бер урынга бәйләнмәгән, шул ук вакытта кешеләрне уртак эш һәм кыйммәтләр аша берләштерә.

– Һич кушыла алмастай тоелган традиция белән инновацияне берләштерү омтылышы кебек яңгырый. Булдыра аласызмы?

– Безнең миссиябез шуннан гыйбарәт тә. Без үткәнне һәм киләчәкне каршы куймыйбыз – без аларны бәйлибез. Балалар вакытларын телефонда үткәрә икән, бу уеннар гына түгел, ә үз динең, тарихың, мәдәниятең турында белем алу мөмкинлеге дә булсын. Әгәр мәчет сәдакаларны терминал аша ала икән, безнең сервис сәдака тартмасын юкка чыгармый, ә аның эшен дәвам итә. Әгәр имам вәгазьләр әзерләү өчен цифрлы ярдәмчене куллана икән, бу – аның зирәклеген, акылын алыштыру түгел, ә булышу. Без гадәти цифрлы продуктлар ясамыйбыз, ә үткәннән – киләчәккә, традициядән хәзерге заманга күпер салабыз.

– Сез бик мавыктыргыч итеп сөйлисез. Гамәли як турында да сөйләгез

әле: система хәзер ничек эшли? Сәдакамат нәрсә ул?

– Сәдакамат – мәчеттә куелган цифрлы панель ул. Намаз вакытларын, ислам календарен һәм бу мәчеткә килгән акчаларны күрсәтә. QR-кодны сканерлап, мәхәллә кешесе T-Pay, Mir Pay, SberPay яки башка системалар аша 1 сумнан башлап теләсә нинди суммада сәдака күчерү мөмкинлеге каралган сәхифәгә күчә. Барысы да бик тиз, куркынычсыз һәм үтә күренмәле.

– Бу системага ничә мәчет һәм мәхәллә тоташтырылган һәм киләчәккә планнар нинди?

– Беренче мәчетләрне без бу елның мартында тоташтырдык. Хәзер аны Россиянең 8 төбәгендә 53 мәчет һәм 10 ислам учреждениесе куллана. Киләсе елга максат – Татарстанның уңышлы моделен бөтен илгә, аннары Урта Азиягә һәм ислам илләренә җәелдереп, 500 дән артык мәчетне тоташтыру. Хәзер төп кыенлык – мәхәллә кешеләренә барысы да бик уңайлы һәм куркынычсыз булсын өчен, түләү инструментларын интеграцияләү һәм банклар белән килештерү.

– Ә имамның дини вазыйфасына йогынтысы ничегрәк? Финанс мәсьәләләре аның вәгазьләренә комачауламыймы?

Имам үзендә андый даими түләүләрнең санын-күләмен күрә. Бу торак-коммуналь хуҗалык чыгымнарына, ремонтка, мохтаҗларга ярдәмгә акча җитәрме-юкмы икәнен алдан планлаштырырга мөмкинлек бирә. Бу айда акча булырмы дип, башын катырмый диярлек, чөнки ул халыкның даими булышып торуын аңлый.

Бүген инде безнең сервистагы барлык түләүләрнең яртысы автомат рәвештә башкарыла. Сәдака акчалары әйләнеше аена 1 млн сумга җитте, шуларның 500 меңе – язылу формасында. Проектны эшләтеп җибәргән көннән 26 меңнән артык транзакция башкарылды, аларның гомуми күләме 6 млн сумнан артты, 5700 гә якын кулланучы теркәлде. Сүз уңаеннан, хәзер безнең платформа аша бара торган рәсми җыем – Мөхәммәтҗан Хөсәенов исемендәге Мәскәү Үзәк җәмигъ мәчете комплексы төзелешенә сәдакалар.

– Тулы бер мәчет төзү яки мәдрәсә тоту мөмкинлеге булмаса да, һәркем үзен иганәче итеп тоя ала, димәк.

– Әйе, һәм бу безнең проектның төп идеяләреннән берсе. Элек бай сәүдәгәрләр, хәйриячеләр, өммәткә ярдәм итү традициясе булган гаиләләр генә меценат була алган. Бүген исә автомат күчерелә торган сәдака ярдәмендә һәр кеше меценатка әйләнә ала. Бер тапкыр куштырасың да, мәчеткә ярдәм эшендә, студентларны укытуда, мохтаҗларны ашатуда яки районның барлык халкы өчен эчәр сулы кое төзүдә катнашасың.

Дини яктан караганда, бу аеруча мөһим. Хәдистә болай диелә: «Кеше үлгәч, аның өч гамәленнән кала башка бөтен гамәлләре бетә. Бу өчесе: өзлексез сәдака (сәдака-җария), башка кешеләр файдалана алырлык белем, аның өчен дога кылачак тәкъва балалар». Хәзер теләсә кем, бакыйлыкка күчкән туганнарының әҗер-саваплары дәвам итсен һәм алар үлгәннән соң да әҗер алсын өчен, изге эшләрне шул туганнары исеменә атап башкара ала.

Без, сәдака исәннәргә дә, үлгәннәргә дә файда китерерлек булсын, дип эшләдек. Пәйгамбәребез: «Көртлек оясы зурлыгында гына булса да мәчет салган кешегә Аллаһы Тәгалә җәннәттә йорт салачак», – дигән. Бүген безнең система ярдәмендә һәр кеше иман йортын төзүче була ала: автомат сәдака бирүне куша һәм ут-суга, уку-укытуга түли, мохтаҗларга ярдәм итә ала. Болар барысы да инде бакыйлыкка күчкән якыннарыбыз хакына эшләнә.

Мәчет-мәдрәсәләребез намаз уку һәм белем алу гына түгел, өммәтнең җанлы аралашу-берләшү урынына да әверелә бара. Кешеләр өммәт тормышында катнашуларын реаль вакытта күреп торалар, җәмгать белән бәйләнешне тоялар. Бу безгә мәхәлләнең асылын кайтара – син үзеңне ниндидер зуррак нәрсәнең бер өлеше итеп тоясың, гамәлеңнең кешеләргә чын мәгънәсендә ярдәм итүен, Аллаһка якынайтуын сизәсең.

Без үткән һәм киләчәк арасында күпер төзибез: цифрлы заманда ата-бабаларыбызның күркәм йолаларын үтәү өчен һәркемгә юл ачыла, ә игелекле эшләр өзлексез рәвештә һәм ачыктан-ачык башкарыла. Шулай итеп, һәркем, үзеннән соң эз калдырып, үзен һәм якыннарын мәңгелек савап белән тәэмин итә ала.

– Эшегезнең икенче юнәлеше – вакуф турында сөйләгез әле.

– Вакуф – хәйрия фондына якын, әмма матди базалы ислам институты. Элекке заманнарда бизнес мәчеткә ярдәм итеп торсын өчен, Аллаһ йорты янында үзенә күрә бер «таяныч» төзелгән – кибетме, остаханәме, башка шундый нәрсәме. Әгәр заманча, идарә ителешле бизнес оештырсак, нәрсә була дип уйладык. Шулай итеп, снеклар сата, кофе әзерли торган вендинг аппаратлары барлыкка килде.

– Ягъни кеше, намазга килгәч, чәй яки чәкчәк сатып алып та мәчеткә булыша?

– Нәкъ шулай! Һәм бу теләсә нинди сүздән дә яхшырак эшли. Күз алдыгызга китерегез: эштән ачыгып килгән кеше, мәчеткә кереп, бер стакан чәй сатып ала һәм шул рәвешле даими игелекле гамәл – сәдака-җария дә кыла. Һәр автомат мәхәллә кешеләре агымын мәчеткә тотрыклы ярдәм чыганагына әйләндерә.

Башта: «Кеше боларны кулланыр микән соң?» – дип шикләндек. Әмма беренче ике автоматны урнаштырганнан соң, нәтиҗәләр көтелгәннән 2,5 тапкырга югарырак булып чыкты. Һәм без моның идея генә түгел, ә эшли торган модель икәнен аңладык. Хәзер һәр автоматка, монда нидер сатып алып, безнең белән бергә мәчеткә һәм мәхәлләгә ярдәм итүең шунда ук аңлашылсын өчен, «вакуф» дигән сүз язып куелган.

– Ничә автомат куярга ниятлисез?

– Ел ахырына кадәр – тагын 38не, киләсендә – Россия буйлап 500гә якын автомат. Ихтыяҗ бик зур: аларны куюны имамнар үзләре сорый. Һәр аппарат якынча 1,5 млн сум тора. Әмма киңәйтү өчен җитди инвестицияләр кирәк.

Без булачак преференцияләр хисабына аппаратларны бушлай диярлек алу өчен, автомат сатучылар белән сөйләшүләр алып барабыз. Чөнки вакуф-вендинг

XIX ГАСЫРДА ТАТАР СӘҮДӘГӘРЛӘРЕ МӘЧЕТЛӘР ТӨЗЕТКӘН, МӘКТӘПЛӘР ТОТКАН ҺӘМ ЯРЛЫЛАРГА ЯРДӘМ ИТКӘН. **БҮГЕН ЦИФРЛЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР АША ҺӘР КЕШЕ, ХӘТТА КӨНЕНӘ 10 СУМ АКЧА БИРЕП ТӘ, ШУНДЫЙ МЕЦЕНАТ БУЛА АЛА.**

– Нәкъ менә шундый сорау безне рекуррент (автомат рәвештә) түләүләр идеясенә илһамландырды да инде. Сәдака бирү культурасын өйрәнгәндә, без бер мөһим нәрсәне аңладык: имам рухи остазлык эше белән шөгыльләнергә тиеш. Ә бүген ул еш кына намаздан соң мәхәллә кешеләре алдына басып: «Туганнар, безгә ашыгыч рәвештә түбәләрне төзәтергә, бинаны җылытырга, суга түләргә кирәк», – дип сүз кузгатырга мәҗбүр. Әйе, имам – матди яктан җаваплы зат, әмма иң элек ул – рухи остаз. Имам кеше кулын сузып соранып йөрергә түгел, мәңгелек кыйммәтләр турында сөйләргә тиеш.

Хәзер теләге булган һәркем автомат рәвештә акча күчерүне көйләп куя ала: әйтик, ай саен 500 сум яки көн саен 10 сум акча бирергә телим, ди. Төймәгә басуга, акча сайлап алынган мәчетнең банк хисабына күчерелә. Кайчан, күпме һәм ничек җибәрергә икәнен уйлап торасы юк. Мәсьәләнең дини ягы да бар: мәсәлән, җомга көнне сәдака бирү аеруча савaплы санала, һәм кеше автомат рәвештә акча күчерүне нәкъ менә шушы көнгә көйли ала.

мәчеткә керем чыганагы гына түгел, реклама мәйданчыгы да: аппарат экраннарында мөселман аудиториясе өчен роликлар, мөһим белдерүләр һәм социаль контент трансляцияләнергә мөмкин. Шул рәвешле вакуф-вендинг, автомат сәдака күчерү технологиясен тулыландырып, безнең экосистеманың икенче кирпеченә әверелә. Дини һәм матди башлангычның, үткән һәм хәзерге заманның шулай берләшүе мәчетләр һәм мәхәлләләр өчен тотрыклы финанс нигезен хасил итә.

– Читтән караганда, сез бик тиз эш итәсез шикелле...

– Чынлыкта исә барысы да күпкә акрынрак. Бу эш белән көн саен янып йөреп, без үзебезгә гел сорау биреп торабыз. Нәрсәләр эшләнде? Кайсы чыннан да эшли? Нәрсәне яхшыртырга мөмкин? Идеяләр сәгать саен туа, әмма аларның системага органик рәвештә үрелеп кереп китүе мөһим. Яңа сервис, яңа функционал – сүз өчен генә түгел. Без һәр элемент экосистеманы көчәйтсен, мәчет һәм мәхәлләгә ярдәм итсен, үтә күренмәлелек һәм ышаныч тудырсын дип эшлибез.

– Юлыгыздагы кыенлыклар?

– Иң зур кыенлык – ышаныч. Кешеләр вәгъдәләрнең үтәлмәве белән еш очраша. Шуңа күрә без эшне күренеп торырлык итеп эшлибез: һәр сум хисапларда чагыла, һәр проект күз алдында.

Бүген барыбыз да бөтен нәрсәне үтәли күрергә, күзәтергә күнеккән. Такси чакыртасыз һәм машинаның каян барганын, сәфәр өчен күпме акча алып калынганын күзәтәсез. Ашарга заказ бирәсез һәм курьерның, сезгә дигән өчпочмак белән чәкчәкне күтәреп, кайсы юлдан барганын белеп торасыз. Кытайдан берәр товарга заказ бирәсез һәм тәүлекнең теләсә кайсы вакытында аның юлын күзәтәсез: менә ул сатучының иленнән киткән, менә районыгызның почта бүлегенә килеп җиткән. Без контрольгә, һәр адымны күреп торырга күнектек. Бу инде – безнең яшәү рәвешебез.

Мәчетләр өчен безнең система да нәкъ әнә шулай эшли. Теләсә кайсы кеше үз телефонында акчаның нәрсәгә җыелуын, күпме тупланганын, максат суммага кадәр күпме җитмәгәнен күрә. Сәдака бирү функциясен кушканда яисә акча күчергәндә, кулланучыга хәбәрнамә һәм рәхмәт сүзләре килә. Имам исә мәчет сервисының шәхси кабинеты аша тулы контроль ясап тора. Ул банк хисабына күпме акча кергәнен, күпме кешенең автомат түләү функциясен кушканын, ай ахырына күпме акча күтәелүен күрә. Барысы да үтә күренмәле һәм аңлаешлы – ышаныч үзеннән-үзе барлыкка килә.

Ә аның белән бергә, өммәтнең һәр әгъзасына изге эштә катнашу хисен тоярга ярдәм итеп, килачәгебезне бергәләп төзи, мәчетләргә булыша һәм белем тарата алуыбызга өмет-ышаныч кире кайта. Үтә күренмәлелек – бер-береңә ышаныч ул, ә мондый ышаныч теләсә нинди проектның нигезен тәшкил итә.

– Командагыз бик саллы. Проект артында кем тора?

– Без көчле нигездән. Безнең командада «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен, Россия ислам университетын, шулай ук Каһирәдәге атаклы Әл-Әзһәр университетын тәмамлаучылар бар. Без татар һәм гарәп телләрендә камил сөйләшәбез. Бөек галимнәрнең, татар гыйлемдарларының мирасын өйрәнәбез һәм дин әһелләре белән бер телдә аңлашабыз. Бу бик мөһим, чөнки ышаныч цифрлы код аша гына түгел, мәдәни код аша да корыла. Шуның нәтиҗәсендә безгә Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте һәм Россиянең башка төбәкләрендәге имамнар ышаныч белдерә.

– Сезнең проектны ислам лайфстайлының яңа этабы дип атап буламы?

– Әлбәттә. Ислам һәр чорда дин генә түгел, яшәү рәвеше дә булган. Без бу тойгыны цифрлы заманда торгызабыз.

– Чит ил базарларына чыгарга ниятлисезме?

– Әйе, әмма башта барысын да камил дәрәҗәдә өйдә – Татарстанда, Россиядә эшләргә телибез. Шуннан соң Урта Азия, Якын Көнчыгыш илләренә, MENA төбәге дәүләтләре – Катар, Оман, бәлки Согуд Гарәбстанына чыгарбыз. Бездә экспертиза һәм сынау проектлары өчен мәйданчыклар бар. Әмма без тизлеккә омтылмыйбыз, һәр инвестор реаль нәтиҗә һәм киң таралу потенциалын күрсен өчен, модельнең нәтиҗәлелеген исбатларга телибез.

– Һәм соңгы сорау: бу интервьюны укыган кешедә нинди хисләр уятырга теләр идегез?

– Һәр кешенең үз тамырларын искә төшерүен, өлкәннәрне хөрмәт итәргә һәм рәхмәтле булырга өйрәткән, күршеләр белән бер гаилә булып яшәгән чакны, туган йорттагы җылылыкны хәтердә тотуын телибез. Боларның барысын да яңа, заманчага әйләндереп кире кайтарырга мөмкин булуын укучыларыбыз аңласын иде. Без берләшәбез икән, конкрет бер шәһәрдә генә түгел, һәркемгә ачык булган цифрлы киңлектә дә көчле мәхәллә булдырачакбыз. Кайчандыр урамнар һәм авыллар изге эшләр өчен берләшкән кебек, бүген безнең цифрлы чараларыбыз миллионлаган кешеләрне берләштерергә ярдәм итәр, дип ышанабыз. Һәм бу тәҗрибә Россия өчен генә түгел, ә кешелеклелек, гаделлек кебек төшенчәләрне югары бәяләгән һәм исламны кадерләгән башка илләр өчен дә үрнәк була алачак.

ОЛЕГ ГАНИЕВ:
«КЕШЕНЕ ҮЗӘККӘ КУЕП ЭШЛӘҮ СТРАТЕГИЯБЕЗ ИСЛАМ ФИНАНСЛАРЫ ТАРМАГЫН ҮСТЕРҮГӘ ТУЛЫСЫНЧА ТУРЫ КИЛӘ»

Семён Кучеров

«Безнең төп максат – ислам финансларының асылын клиентка дөрес һәм аңлаешлы итеп җиткерү: сөйләү һәм күрсәтү, халыкның финанс белеменә игътибарны арттыру, бүгенге традицион банкинг белән ислам финанслары арасындагы аерманы бәяләргә мөмкинлек бирү…» Үз вакытында Саклык банкының партнёрлык финанслары экспериментындагы миссиясен әлеге финанс оешмасының Партнёрлык финанслары һәм махсус проектлар үзәге башлыгы Бехнам Гурбан-Заде* шулай дип билгеләп үткән иде. Банк әлеге максатка никадәр якын килә алган һәм партнёрлык финанслары базары ничек үзгәргән? Бүгенге әңгәмәбез шул хакта.

*«Татарстан» журналы, №9, 2024

ФИНАНС МӨМКИНЛЕКЛӘРЕГЕЗ ҺӘМ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫГЫЗНЫ УЙЛАП ЭШ ИТЕГЕЗ

Фотолар «Саклык банкы» ГАЖ матбугат хезмәтеннән алынды. РЕКЛАМА

– Эксперимент башында Саклык банкы Татарстанда партнёрлык финанслары буенча үз офисын ачкач, бу галәмгә очу белән бер тоелды, чөнки илдә моңа охшаш бернәрсә дә булганы юк иде. Бүген партнёрлык финанслары базарында вазгыять ни дәрәҗәдә үзгәрде?

– Уңай динамика, һичшиксез, бар – бу аналитикадан да, эшчәнлек нәтиҗәләреннән дә күренә. Үсеш темплары, бәлки, артык зур да түгелдер, әмма без Финанс министрлыгы һәм башка дәүләт органнарының ярдәмен тоябыз, Россия банклары ассоциациясенең стандартлар эшләүдә һәм тармакны үстерүдә актив катнашуын күрәбез. Әйтергә кирәк, узган ел базар сизелерлек алга китте: системалы эшләргә һәм сыйфатлы продуктларны үстерергә әзер компанияләр өчен мохит формалаша башлады. Экспериментны 2028 елга кадәр озайту турындагы карар алдан фаразлана торган хокукый мохит тудыра. Бу катнашучыларга киләчәкне күздә тоткан планнар төзергә һәм яңа юнәлешләрне ышанычлы үстерергә ярдәм итә. Һәм безнең өчен, әлбәттә, бу Россиядә ислам финанслары индустриясенә этәргеч бирәчәк стандартлар формалаштырырга мөмкинлек тудыра.

– Россиядә ислам финанслары экзотика булудан туктады. Димәк, партнёрлык (ислам) продуктларын тәкъдим итә торган банклар саны да арта. Саклык банкы бу үзгәрешләргә ничек карый, ислам финанслары өлкәсендә алдынгылыкта калу өчен нәрсәләр эшли?

– Банкның кешене үзәккә куеп эшләү стратегиясе асылда ислам финанслары тармагын үстерүгә тулысынча туры килә. Бер үк вакытта без озакка исәпләнгән стратегия кысаларында эшлибез, көчебезне бүгенге өчен мөһим булган юнәлешләргә сарыф итәбез. Беренчедән, сату каналларын киңәйтү юнәлешендә эшлибез: безнең продуктлардан кеше цифрлы каналлар аша файдаланырлык булсын, бу очракта барлык операцияләрнең уңайлылыгы һәм үтә күренмәлелеге тәэмин ителә. Без шулай ук көйләүче оешма, хакимият органнары һәм мөселманнарның диния нәзарәтләре белән тармак стандартларын эшләү юнәлешендә актив хезмәттәшлек итәбез. Бу, таләпләргә туры килү белән беррәттән, бөтен тармак өчен нигез формалаштырып, сыйфат принципларын эшләргә мөмкинлек бирә.

– Бүгенге көндә Татарстанда партнёрлык финансларының нинди продуктларына ихтыяҗ зур?

– Физик затлар арасында «Адаф» дебет картасы һәм «Аман» исәп-хисап счеты белән кызыксыну аеруча зур. Корпоратив сегмент өчен «Иҗарә» лизингына, исәп-хисап-касса хезмәтенә, төзүчеләр өчен инструментларга ихтыяҗ бар. Бу шәригать принциплары нигезендә бизнесны нәтиҗәле үстерергә ярдәм итә торган карарлар.

– Әйтегез әле, потенциаль клиентлар традицион банкингның гадәти моделе белән ислам финанслары арасындагы аерманы ни дәрәҗәдә бәяли, тоя ала?

– Әлбәттә, хәбәрдарлык дәрәҗәсе шактый артты. Әгәр башта ислам банкингының төп принципларын бик азлар гына белгән булса (без моны белем бирү программасының беренче агымын эшләтеп җибәргәндә күрдек), бүген катнашучыларның күбесе теманы шактый аңлап килә, шуңа күрә алга таба башка нәтиҗәләргә дә өмет итәбез. Төп хәбәр чыганаклары бергә эшли: массакүләм мәгълүмат чаралары һәм рәсми ресурслар нигез булып торган мәгълүматны формалаштыра, ә шәхси киңәшләр мөһим канал булып кала, чөнки үзеңә якын даирәгә ышану кеше өчен аерым әһәмияткә ия. Шул ук вакытта дәүләт университетлары бу эшкә актив кушыла:

ӘЛБӘТТӘ, ХӘБӘРДАРЛЫК ДӘРӘҖӘСЕ ШАКТЫЙ АРТТЫ. ӘГӘР БАШТА ИСЛАМ БАНКИНГЫНЫҢ ТӨП ПРИНЦИПЛАРЫН БИК АЗЛАР ГЫНА БЕЛГӘН БУЛСА, БҮГЕН КАТНАШУЧЫЛАРНЫҢ КҮБЕСЕ ТЕМАНЫ ШАКТЫЙ АҢЛАП КИЛӘ.

– Ә ТР мөселманнарының Диния нәзарәте сезгә партнёрлык финанс продуктларын шәригать принципларына туры китерү юнәлешендә ярдәм итәме?

– Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте белән партнёрлык стратегик характерда. Без бергәләп продуктларның шәригать принципларына туры килүен тикшерәбез һәм яңа алымнар турында фикер алышабыз. Татарстан безнең пилот проект эшләп киткән беренче төбәк булды, һәм монда тупланган тәҗрибә барлык төп регионнардагы экспертларны берләштерү өчен оештырылган Шәригать консультация советы аша федераль дәрәҗәдә файдаланыла. Мондый хезмәттәшлек сыйфат стандартларын эшләргә һәм барлык катнашучылар арасында системалы эшчәнлек оештырырга мөмкинлек бирә.

– Эксперимент башланганнан соң ике ел узды, бүген потенциаль инициативалар белән чыгалар, халык өчен проектлар эшләтеп җибәрәләр.

– Банк үз продуктларын сынап карау һәм аннан соң РФнең башка субъектларында кертү максатында пилот төбәк буларак Татарстан Республикасын сайлады. Бу планнар ничек тормышка ашырыла?

– Бүген без бөтен игътибарыбызны гамәлдәге карарларга таянып эшләүне көчәйтүгә, методологик база булдыруга һәм стандартлар формалаштыруга юнәлтәбез, алар башка төбәкләрдә партнёрлык финансларын эшләтеп җибәрү өчен таяныч булачак. Якын киләчәктә сату каналларының нәтиҗәлелеген арттыруга, хезмәт күрсәтүләрне үстерүгә һәм эшлекле мәйданчыкларда катнашуга өстенлек бireләчәк. Анда без тупланган тәҗрибәне күрсәтәчәкбез. Болар барысы да базарның тотрыклы үсешен тәэмин итәргә мөмкинлек бирә, без шуңа омтылабыз да..

ИСЛАМ БАНКИНГЫ: ГАДЕЛ ФИНАНСЛАР ДӨНЬЯСЫ

Беренче җитди килешүләр, базарга яңа финанс продуктларын чыгару, бизнес ягыннан кызыксынуның артуы... Россиядә күптән түгел генә бары тик теориядә яшәгән ислам банкингы бүген тотрыклы үсеш күрсәтә.

Илдә партнёрлык (ислам) финанслары буенча ике ел элек башланган эксперимент тотрыклы рәвештә үсүен дәвам итеп кенә калмый, кешеләргә конкрет файда китерә, икътисад өчен яңа этәргеч көчкә әверелә. Бу бигрәк тә ислам финансларының флагманы булган Татарстанда ачык чагылыш таба.

ХӘЛӘЛ КАПИТАЛГА АЧКЫЧ

2023 елда кабул ителгән Федераль закон, исегезгә төшерәбез, дүрт төбәктә (Татарстан, Башкортстан, Чечен Республикасы, Дагыстан) пилот режимда ислам финансларын кертеп җибәрде. Финанс мохитендә үзгәрешләр башланды. Экспериментның беренче елында ук Үзәк банк реестрына 20 оешма теркәлде, ә килешүләр күләме 15 млрд сумнан артып китте. Хакимиятнең ярдәме һәм бизнесның актив катнашуы нәтиҗәсендә партнёрлык (ислам) финансларын үстерүдә Татарстан лидерга әйләнде.

2025 ел башына партнёрлык (ислам) финансларының күләме 3,1 млрд сумнан артты, ҮБ реестрына теркәлгән катнашучы оешмалар саны да утыз бергә җитте. Шуңа да игътибар итик: якынча 5 млрд сумлык ислам облигацияләре, ягъни сокук чыгару мөмкинлеге карала. Ә бу, әйтергә кирәк, иң зур хәләл капитал тупланган чит ил инвесторлары тарафыннан әлеге экспериментка карата кызыксынуның үсүен чагылдыра торган күрсәткеч.

Ислам финанслары аерымланган урын алып торган продукт булудан туктап, реаль икътисадның бер өлешенә әйләнә. Ә экспериментны 2028 елга кадәр озайту турындагы карар кануннар һәм салым системасының яңа чынбарлыгына җайлашуны дәвам итәргә, катнашучылар санын һәм географиясен дүрт төбәктән читтә дә киңәйтергә, халыкара финанс институтлары белән хезмәттәшлекне тирәнәйтергә һәм илебез халкының киң катламы өчен ислам продуктларыннан файдалану мөмкинлеген арттырырга мөмкинлек бирә.

ПРОЦЕНТСЫЗ ЗАЙМ? «АМАЛЬ»ГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

«Амаль» финанс йорты, пилот режимында иң актив катнашучыларның берсе буларак, инде берничә мең клиентка хезмәт күрсәтә. Мөрабәхә (мөсавәмә) һәм модарәбә продуктлары, шулай ук процентсыз займнар аеруча популяр. Тагын алар Россиядә физик затларның киң даирәсе куллана алырлык беренче продуктны да эшләтеп җибәрде. Бу – конкрет максатларга тәгаенләнгән «Кард әл-Хәсән» процентсыз займы.

Бу займ мөселманнарга финанс мәсьәләләрен дини кагыйдәләрне бозмыйча хәл итәргә мөмкинлек бирә. Продукт төп тыюга – рибачылык процентына юл куймый. «Кард әл-Хәсән» продуктын эшләтеп җибәрү – ислам финансларының эре бизнес өчен генә түгел, гади кешеләр өчен дә эшли алуын дәлилли торган мөһим адым.

** Юридик атамасы – «Амаль» Кулланучылар җәмгыяте.*

ФИНАНС МӨМКИНЛЕКЛӘРЕГЕЗ ҺӘМ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫЗНЫ УЙЛАП ЭШ ИТЕГЕЗ

Фото: amal.ru. РЕКЛАМА. «Амаль» КҖ. РФ ҮБ тарафыннан экспериментта катнашучылар реестрына теркәлгән, 25.01.2024

ЫШАНЫЧ КУРКЫНЫЧНЫ КИМЕТӘ

Ислам финанслары мөселман җәмәгатьчелегенә генә түгел, ә тулаем төбәк икътисадына да файда китерә. Ул тотрыклы үсеш бурычларын хәл итәргә сәләтле көчле ысул. Партнёрлык (ислам) финанслары буенча экспериментта актив катнашучы Татарстан – этика принципларының тулаем икътисад файдасына ничек эшли алуына ачык мисал.

Беренчедән, әлбәттә, бу – инвестицияләр агымы. Татарстан БГӘ, Согуд Гарәбстаны, Төркия, Малайзия капиталларын җәлеп итә. Без югарыда атаган сокук чыгару тәкъдиме әлеге кызыксынуның барлыгын яхшы дәлилли. Икенчедән, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү – партнёрлык схемалары алар өчен идеаль туры килә. Өстәвенә, әлбәттә, финанс инклюзиясе – системага элек дини сәбәпләр аркасында банкларга мөрәҗәгать итә алмаган кешеләр керә. Кайбер мәгълүматлар буенча, халыкның 10-15% ы ислам банк хезмәтләрен куллана башлаган.

Финанс куркынычларын диверсификацияләү турында да онытмыйк – альтернатив ысуллар икътисадны тотрыклырак итә. Моннан тыш, этик тәкъдимнәр финанс оешмаларында да, кулланучыларда да җаваплылык культурасын формалаштырырга ярдәм итә. Бу ышанычны ныгыта һәм куркынычсызлык дәрәҗәсен арттыра.

Ислам банкингы – ул дини тәҗрибә генә түгел, ә стратегик ресурс та. Ул ышаныч, гаделлек һәм тотрыклы үсешкә нигезләнгән икътисад төзергә мөмкинлек бирә.

(сатып алу хокукы белән аренда) буенча килешүләргә икеләтә салым салынырга мөмкин, бу куркыныч тудыра һәм продуктны сайлау мөмкинлеген киметә.

ИСЛАМ ФИНАНСЛАРЫНЫҢ ТӨП ПРИНЦИПЛАРЫ – РИБАЧЫЛЫК ПРОЦЕНТЛАРЫННАН, СПЕКУЛЯЦИЯЛӘРДӘН һӘМ ЭШЧӘНЛЕКНЕҢ ТЫЕЛГАН ТӨРЛӘРЕН ФИНАНСЛАУДАН БАШ ТАРТУ. БАНК КРЕДИТ БИРМИ, УЛ КЛИЕНТНЫҢ ПАРТНЁРЫНА ӘВЕРЕЛӘ, ТАБЫШНЫ ДА, ФИНАНС КУРКЫНЫЧЛАРЫН ДА АНЫҢ БЕЛӘН БЕРГӘ БҮЛӘ.
КИЛЕШҮЛӘРДӘ КУЛЛАНЫЛА ТОРГАН ТӨП ТӨШЕНЧӘЛӘР:
МОДАРӘБӘ һӘМ МӨШАРӘКӘ – ТАБЫШНЫ БҮЛҮ ЮЛЫ БЕЛӘН УРТАК ФИНАНСЛАУ;
МӨРАБӘХӘ – ТӨГӘЛ БИЛГЕЛӘНГӘН ӨСТӘЛГӘН БӘЯ КУЮ ЮЛЫ БЕЛӘН СӘҮДӘ ФИНАНСЛАВЫ;
ИҖАРӘ – САТЫП АЛУ ХОКУКЫ ЮЛЫ БЕЛӘН АРЕНДАЛАУ (ЛИЗИНГ);
КАРД ӘЛ-ХӘСӘН – СОЦИАЛЬ МАКСАТЛАРГА ПРОЦЕНТСЫЗ ЗАЙМ.

ҖАВАП БИРЕРГӘ КИРӘКЛЕ ЗАМАНА ТАЛӘПЛӘРЕ

Россиядә ислам банкингының уңышына карамастан, бу юнәлеш кайбер кыенлыклар белән дә очраша. Алар үтәп булмаслык түгел, бәлки, теләсә кайсы яңа финанс моделенә хас авырлыклар, бигрәк тә хокукый нормаларга яраклашуны таләп иткәннәре. Әмма, һичшиксез, аларны вакытында хәл итү тотрыклы үсеш, тәҗрибәне тарату өчен бик мөһим.

Шундый проблемаларның берсе – законнар һәм салым киртәләре. Гамәлдәге кануннар ислам нормаларының үзенчәлеген һәрвакытта да исәпкә алмый. Мәсәлән, иҗарә

Икенче проблема – квалификацияле кадрлар җитмәү. Ислам финанслары шәригать һәм юридик нормаларны үзара җайлаштыруны таләп итә. Бүгенге көндә Россиядә мондый белгечләр бик аз. Бу проблеманы хәл итү өчен белем бирү программалары, сертификацияләр булдырырга, халыкара университетлар һәм институтлар белән хезмәттәшлек оештырырга кирәк.

Халыкның хәбәрдарлыгы түбән булу да комачаулый. Әлегә күпләр ислам финансларының дини альтернатива гына түгел, ә дингә бәйсез рәвештә һәркем өчен мөмкин булган тулы кыйммәтле этик модель булуын аңламый. Агарту чаралары, ислам финансларын финанс ягыннан белем күтәрү программаларына кертеп җибәрү һәм башкалар кирәк.

Ислам банкингы системалы ярдәм таләп итә - һәм ул моңа лаек.

КИЛӘЧӘККӘ КАРАШ

Экспериментны 2028 елга кадәр озайту мантыйкка туры килә торган адым. Татарстан ислам финансларының дини альтернатива гына түгел, ә тотрыклы үсешнең заманча ысулы булуын күрсәтә. Халыкара тәҗрибә шуны раслый: мондый модельләр төрле илләрдә эшли.

Россия глобаль ислам финанс системасына интеграцияләнергә, озак вакытлы инвестицияләр җәлеп итәргә һәм гражданнарга этик, үтә күренмәле һәм гадел финанс чишелешләрен тәкъдим итәргә мөмкинлек ала.

Ислам банкингы – чикләү түгел, бу – мөмкинлек.

AIGUL.USMANOVA
КЕЙТЕРИНГ
«Уңышка ирешкән кешеләр – 2025» бизнес-премия версиясе буенча иң яхшы кейтеринг компаниясе
Банкетлар | Фуршетлар | Бокслар
Бер персонага 700 сумнан меню
Зәвыклы такталарда тәкъдим ителә торган ризык сервировкасы
Казан шәһәре, Крутая ур., 3
+7 (843) 203-45-00
+7 (937) 154-00-16
kazan.aigul-usmanova.ru
aigul.usmanova_kazan
aigul.usmanova1
*Айгуль Усманова
Реклама. ИП Усманов Линар Марселевич, ИНН:022802159874, ОГРНИП:318028000118867

СКАНДИНАВИЯ
ИГЪТИБАРЛЫ МЕДИЦИНА КЛИНИКАСЫ

(843) 200-10-65

«Скандинавия» клиникасының бала тудыру йортында ислам кануннарына туры китереп бәби табарга була

Клиникабыз Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты тарафыннан бирелгән таныклыкка ия, ул ислам кануннары нигезендә бәби таптыру мөмкинлеген раслый.

- Палатада кеше һәм хайван сурәтләре, шулай ук исламның әхлакый-этик нормаларына каршы килгән предметлар һәм рәсемнәр юк.
- Намаз уку өчен кирәкле атрибутлар (Коръән, намазлык, тәсбихләр) бар. Изге Кәгъбә юнәлеше билгеләнгән.
- Туалет бүлмәләрендә тәһарәт алу өчен кирәкле һәрнәрсә бар.
- Хатын-кыз табиблардан гыйбарәт махсус бригада оештырылган.
- Хәләл ризык бирелә.
- Дарулар һәм дәвалау максатларында кулланыла торган әйберләрнең ислам кануннары буенча медицина хезмәтләре күрсәткәндә файдалануга рөхсәте һәм шуны раслаган документлары бар.
- Хатын-кыз бала табу бүлегендә йөргән чакта, махсус кагыйдәләр үтәлә: аны чит кешеләр һәм клиника хезмәткәрләре күрми.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты» продукция сыйфатын контрольдә тоту шәхси учреждениесе.

Бала тудыру йорты сайтына күчү өчен, QR-кодны сканерлагыз.

ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЛӘШҮ ТАЛӘП ИТЕЛӘ

ЛИЦЕНЗИЯ БЕЛӘН КЛИНИКА САЙТЫНДА ТАНЫШЫРГА БУЛА. РЕКЛАМА

БИЗНЕС

РФ СУБЪЕКТЛАРЫНДА ИНВЕСТИЦИОН КЛИМАТ

1 МӘСКӘҮ

3 МӘСКӘҮ ӨЛКӘСЕ
БАШКОРТСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

5 КАЛУГА ӨЛКӘСЕ
СМОЛЕНСК ӨЛКӘСЕ
ЧИЛӘБЕ ӨЛКӘСЕ

7 КЫРЫМ РЕСПУБЛИКАСЫ
ВОРОНЕЖ ӨЛКӘСЕ
КРАСНОДАР КРАЕ

9 НОВГОРОД ӨЛКӘСЕ
МАГАДАН ӨЛКӘСЕ
МОРДОВИЯ РЕСПУБЛИКАСЫ

Милли рейтинг
8 юнәлештә
110 күрсәткеч
буенча исәпләнә:

- Күчемсез милек
- Инженер челтәрләре
- Бизнесны яклау
- Бизнеска ярдәм чаралары
- Экспорт эшчәнлеге
- Инфраструктура һәм технологияләр
- Кадрлар һәм хезмәт ресурслары
- Базарны һәм көндәшлекне үстерү

Инвестицион климат торышының милли рейтингы бизнесны алып бару өчен уңайлы шартлар тудыру буенча төбәк хакимиятләренең тырышлыкларына бәя бирә һәм иң яхшы тәҗрибәләрне ачыклый, **ә аның нәтиҗәләре төбәк дәрәҗәсендә инвестицияләр өчен ярышта көндәшлеккә этәргеч бирә.**

ӨЧЕН ҖЫЛЫ УРЫН КАЙДА

ТОРЫШНЫҢ МИЛЛИ РЕЙТИНГЫ*

2 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН НОВГОРОД ӨЛКӘСЕ

4 САХАЛИН ӨЛКӘСЕ
ТӨМӘН ӨЛКӘСЕ

6 САНКТ-ПЕТЕРБУРГ

8 ЛИПЕЦК ӨЛКӘСЕ
ЧЕЧЕН РЕСПУБЛИКАСЫ

10 СВЕРДЛОВСК ӨЛКӘСЕ
САРАТОВ ӨЛКӘСЕ

Рейтинг эшкуарлар һәм экспертлар арасында сораштырулар үткәрү нәтиҗәләре, шулай ук статистика күрсәткечләре нигезендә формалаша. Быел мондый сораштыруларда **400 меңнән артык эшкуар** катнашты.

Рейтинг лидерлары Мәскәү һәм Татарстан – 2019 елдан бирле алдынгы урыннарны бирми.

Эшли башлаганнан бирле рейтинг төбәкләрдә эшлекле мохиткә йогынты ясый торган факторларга комплекслы анализ үткәрүнең тикшерелгән һәм универсаль ысулына әйләнде. **11 ел дәвамында алып барылган мониторинг нәтиҗәсендә барлык төбәкләрдә дә бизнесны алып бару шартлары яхшырды. Төбәкләр арасында, инвестицияле циклның иң мөһим сюжетлары буенча иң начар һәм иң яхшы күрсәткечләр арасындагы аерма кимеде.**

** Милли рейтинг – Яңа проектларны алга этәрү буенча стратегик инициативалар агентлыгы, РФ Сәүдә-сәнәгать палатасы, Россия сәнәгатьчеләре һәм эшкуарлары берлеге, «Эшлекле Россия», «ОПОРЫ РОССИИ» оешмаларының уртак проекты.*

XXI ГАСЫР

«РОСТКИ: РОССИЯ ҺӘМ КЫТАЙ – ҮЗАРА ФАЙДАЛЫ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК»

БИЗНЕС-ФОРУМ 商业论坛 РОСТКИ 萌芽

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЫТАЙ ИНВЕСТИЦИЯЛӘРЕНӘ ЯРДӘМ ИТҮ ҮЗӘГЕ АЧЫЛДЫ

77 ЭШЛЕКЛЕ СЕССИЯ

ТӨРЛЕ ДӘРӘҖӘДӘГЕ **100** ЧАРА

ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ТУРЫНДА **33** КИЛЕШҮ

10 000 нән АРТЫК КАТНАШУЧЫ

КЫТАЙДАН **28** АДМИНИСТРАТИВ СТРУКТУРА

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ **66** СУБЪЕКТЫ

40 ИЛ

ЧЖАН ХАНЬХУЭЙ, КЫТАЙ ХАЛЫК РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНДӘГЕ ГАДӘТТӘН ТЫШ ҺӘМ ТУЛЫ ВӘКАЛӘТЛЕ ИЛЧЕСЕ:
«Татарстан Кытай эшкуарлары өчен тагын да кызыклырак була бара. Биредә безнең компанияләр арасында элемтәләр урнаштыру өчен мөһим мәйданчык оештырыла. Татарстан Кытай белән Россия арасындагы төбәкара хезмәттәшлекнең яхшы үрнәген булдырды. Республиканың күп кенә өстенлекләре бар. Монда инвестицияләр кертү шартлары бик яхшы. Татарстан Рәисе һәм хөкүмәте Кытай төбәкләре белән хезмәттәшлеккә зур әһәмият бирә. Безнең күп кенә предприятиеләр Татарстанга килергә һәм җиһазлар, инженерлык техникасы, цемент һәм башка әйберләр җитештерү өчен уртак заводлар төзергә ниятли».

Фото: rais.tatarstan.ru, duma.gov.ru

ЕФӘК ЮЛЫ

КАЗАН
18 – 19
август
2025

III ХАЛЫКАРА ФОРУМЫ

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ:
«Форум – Россия белән Кытай арасындагы хезмәттәшлектә иң мөһим вакыйгаларның берсе. Ул безнең илләрнең делегатларын, экспертларын һәм партнёрларын берләштерә. Россия һәм Кытай күп еллар дәвамында ике як арасында үзара аңлашуга һәм хөрмәткә нигезләнгән стратегик мөнәсәбәтләрне үстерә. Бүген ике дәүләт җитәкчесенең шәхси тырышлыгы нәтиҗәсендә безнең дуслык икътисад өлкәсен генә түгел, гуманитар аспектларны да колачлый».

RUSSIA CHINA EXPO 2025 КҮРГӘЗМӘСЕ

93 ЭКСПОНЕНТ

22 КЫТАЙ КОМПАНИЯСЕ

71 РОССИЯ КОМПАНИЯСЕ

ЭШЛЕКЛЕ ПРОГРАММА:

- дәүләтара диалог
- икътисад
- сәнәгать
- мәгариф
- бизнес һәм эшкуарлык
- эшлекле берләшмәләр
- финанслар һәм инвестицияләр
- мәдәният
- медиа
- хокук
- транспорт
- авыл хуҗалыгы
- туризм
- төзелеш

«РОСТКИ»: «УҢЫШ» ӨЧЕН УҢДЫРЫШЛЫ ТУФРАК

Дмитрий Сивков

«Нихао!», «Исәнмесез!», «Хәерле көн!» – бу сәламләүләр «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» Өченче форумы эшләп торган көннәрдә берөзлексез яңгырады.

Август уртасында Татарстан башкаласында узган форум ике ил арасындагы диалогны һәм гамәли хезмәттәшлекне үстерү буенча төп мәйданчыкларның берсе булуын тагын бер мәртәбә раслады. «РОСТКИ-2025» форумына 40 илдән 10 меңнән артык катнашучы килде. Болар – хакимият, бизнес, фән һәм мәдәният вәкилләре. Кытай бизнесының төрле тармакларына караган эре компанияләр үзләре ике йөзләп иде: энергетикадан һәм авыр сәнәгатьтән башлап, суднолар төзелеше, логистика һәм төзелешкә кадәр.

БЕР-БЕРЕБЕЗНЕ ТАНЫР ВАКЫТ

«РОСТКИ» эшлекле элемтәләрне генә түгел, тулаем илләр турындагы белемнәрне дә киңәйтергә мөмкинлек бирә. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина фикеренчә, Татарстан Кытай белән мөнәсәбәтләрдә әле шактый юнәлешне колачлап бетерми. Әлеге ил үсеш алган күп кенә тармакларны үзебез өчен ачарга һәм тирәнгәрәк үтеп керергә тиешбез.

– Без Кытайны начар беләбез, эшмәкәрләр белән сөйләшкәндә, бу бигрәк тә ачык күренә. Без аларның провинцияләрен, зур предприятиеләрен җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнмәгән әле, – дип билгеләп үтте Талия Миңнуллина форум кысаларындагы иртәнге бизнес-ашта.

Хәер, «РОСТКИ» сәнәгать һәм бизнес өлкәләрендә генә түгел, гуманитар хезмәттәшлектә дә белемнәрен шактый киңәйтте. Бу хакта форум программасы да сөйли, анда хәзер

Фото: Александр Ефремов

Кытайдагы аждаһа көймәләре бәйрәменә дә, коллектив рәвештә гортензия утыртуга да, өстәл теннисы буенча ярышларга да, ТР Рәисе Кубогына хәйрия гольф-турнирын уздыруга да, тугандаш шәһәрләр һәм партнёр шәһәрләр командаларының шахмат турнирына да урын табылды. Шулай ук форум кысаларында кытай, татар һәм рус чәй зоналарында чәй эчү сәнгате белән танышу мөмкинлеге дә булды. Ә сессияләр вакытында тышкы икътисади хезмәттәшлеккә милли бизнес-мәдәниятләр белән эшлекле этикет ракурсында төшенергә мөмкинлек бирелде.

ИСӘНМЕСЕЗ, РОБОТ!

Russia China Expo халыкара күргәзмәсе Татарстан форумының иң мөһим вакыйгаларыннан берсе булды. «Казан-Экспо»да – 22 Кытай, 71 Россия компаниясе үзләренең соңгы еллардагы казанышларын һәм перспективалы проектларын тәкъдим итте.

Күргәзмә стендлары белгечләргә генә түгел, форум кунакларына да кызыклы булып чыкты. Милли татар костюмын киеп алган «гуманоид тибындагы робот прототибы» белән ничек танышмый һәм аралашмый булсын, ди, я? Яки Россия операцион системасы нигезендә эшләнгән ясалма интеллектлы тәрҗемәче күзлек һәм телефонны сынап карамый түзеп булыр идеме?

Тагын бер җәлеп иткән нокта – автосәнәгать күргәзмәсе. Кытайның TANK һәм Lixiang компанияләре эшләнмәләре белән янәшәдә «Алабуга» МИЗ заводында җитештерелгән «Соллерс» SP7 локальләштерелгән минивэн машинасы да тәкъдим ителде. Бизнес-купе классында чыгарылырга тиешле 7 урынлы пассажир автомобиле инде конвейерда икән, һәм ул тиздән сатуга чыгачак, диделәр. Ә менә бәясе турындагы сорауга җитештерүчеләр турыдан-туры җавап бирмәде әлегә, «сатып алырдай булачак», дип кенә чикләнделәр.

Сәнәгать локацияләре белән янәшәдә генә «Мәдәниятләр кисешкән урын» дип исемләнгән мәйданчыклар да урнашкан иде. Анда Татарстан һөнәрчеләренең эшләре күрсәтелде һәм остаханәләр узды: традицион уен коралларында уйнау, тәңкә сугу, гжель техникасында рәсем ясау, иероглифлар язу һ.б. Кытай язуы нигезләрен без фәкыйрегез дә үзләштерергә омтылып карады. КФУ студенты – язарга өйрәтүче остаз Юлия, Кытай язу сәнгате нечкәлекләренә төшендерергә тырышып, болай диде: «Гади Кытай крестьяны, мәсәлән, мең ярымга якын иероглиф белә, берәр оешманың гадәти хезмәткәре яки эшче – аннан биш йөзгә артыгракны, ә менә урта мәктәпне тәмамлаган укучы инде – 3000 не...» Әгәр дә кытайлы 900 дән дә азрак иероглиф белә икән, аны, гафу итегез, үз илләрендә наданга саныйлар. Ягъни андыйлар кайчандыр бездәге укый-яза белмәүчеләр исәбендә йөриячәк, ди ул. Корреспондентыгыз активына, ни кызганыч, бары бер генә иероглиф туры килә – «фу» (fú). Ләкин ул бик зур кыйммәтләр турында сөйли торган иероглиф: «бәхет», «уңыш» һәм «иминлек» дигәнне белдерә.

ЧЭНЬ ЦЗИНЬСИНЬ. Ә БЕЗНЕҢЧӘ – ИГОРЬ

«Татарстан Республикасы үрнәгендә Россия һәм Кытайның төбәкара хезмәттәшлеге» түгәрәк өстәле форумдагы төп чараларының берсе булды. Түгәрәк өстәл барышында Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, Россия – Кытай мөнәсәбәтләренең киләчәктәге үсешен тәэмин итүдә төп факторларның берсе булып инвестицион проектларны гамәлгә ашыру тора.

«Везума» фәнни-җитештерү үзәгенең директорлар советы рәисе Чэнь Цзиньсинь мондый алымны сүз белән дә, эш белән дә хуплый. Чыгышында хәбәр иткәнчә, сентябрь азагында аның компаниясе «Алабуга» МИЗда кабызу шәмнәре җитештерү буенча завод эшләтеп җибәрәчәк икән. Моннан тыш, «Иннополис» МИЗда ачылачак яңа заводның концепциясе дә расланды, ул техник яктан үтә чыдам керамика белән кабызу шәмнәре корпусларын җитештерү буенча махсуслашачак. Проектка инвестицияләр 1,5 миллиард сумны тәшкил итә, диделәр.

– Безгә гади татарстанлылардан алып зур җитәкчеләргә кадәр – барысы да ярдәм итте. Һәм шуны да билгеләп үтәсем килә: сез бик булдыклы, яхшы җитәкче, ә командагыз искиткеч көчле, – дип мөрәҗәгать итте республика башлыгына Чэнь Цзиньсинь әфәнде.

Хәер, шәхси әңгәмәдә ул үзен Игорь Чен дип атарга һәм шулай мөрәҗәгать тә итәргә сорады.

– Игорь, сез рус телен каян шулай яхшы беләсез? – дип сорамый кала алмадык, билгеле.

– Ике ел дәвамында Мәскәү дәүләт статистика, информатика һәм икътисад университетында магистратурада укыдым, – дип җавап бирде әфәндебез.

Дипломны 2012 елда алган. Ике ел Кытайда эшләгән, ә аннары кабат Россиягә кайткан һәм Мәскәүдә автомобиль компонентлары белән сәүдә итү буенча компания ачкан.

– Аларны җитештерү – безнең гаилә бизнесы, дөрес, хәзер инде дәүләт капиталы катнашында. Без Кытайда – беренче номерлы оешма, ә дөньяда – үз сегментыбызда икенче урында, – ди ул. – Россиядә клиентларыбыз бик күп, продукцияне АвтоВАЗ, УАЗ һәм ГАЗ конвейерлары өчен җитештерәбез һәм тәкъдим итәбез. Шуңа күрә сезнең илдә завод ачарга булдык.

– Ә нишләп моның өчен нәкъ менә Татарстанны сайладыгыз?

– Башта без берничә урынны карадык, шул исәптән, Мәскәүгә якынрак шәһәрләрне дә. Аерым алганда, Калуганы. Ләкин Татарстанга сәфәр кылганнан һәм Рөстәм Миңнехановн белән танышканнан соң, анык бер карарга килдек: безгә Татарстан туры килә. Монда тиешле ярдәмне шунда ук күрсәттеләр, төзелеш өчен яхшы урын бүлеп бирделәр, логистика күзлегеннән караганда, бу урын отышлы да, уңай да. Юллар да бик яхшы сездә. М-12 трассасыннан мин гомумән бик канәгать, еш кына ул юл буйлап сезгә Мәскәүдән киләм һәм кире кайтам. Озакламый гомумән Казанда төпләнергә ниятлим.

– Бизнестан тыш, Казан сезгә нәрсәсе белән ошады?

– Миңа шәһәрнең архитектурасы бик ошый, җирле кухня да бик тәмле һәм үзенчәлекле. Бигрәк тә сезнең пешкән әйберләрегезне яратам, теге итле өч яклы ризык ничек атала әле... исемдә калмаган бит...

– Өчпочмак.

– Хәзер исемен атый алмам, мөгаен, әмма вакыт узу белән... өйрәнәчәкмен.

Без моңа һич кенә дә шикләнмибез. Игорь планнарын тормышка ашырырга ияләшкән кеше – күренеп тора.

РОСТКИ – «Россия – Татарстан – Кытай» ил атамалары аббревиатурасы гына түгел. Ул – бер-берсен тапкан партнерларның эшлекле мөнәсәбәтләре һәм шуларның мәгънәви чагылышы да, бу төшенчәнең үзендә үк потенциал аермачык күренеп тора. Яшь үсентеләрне ничек кадерләп тернәкләндереп җибәрергә кирәк, бизнес белән мөнәсәбәтләрдә дә – шулай бит. Димәк, без киләчәктә, «уңыш»ның уңдырышлы туфракка төшеп, гөрләп уңачагына да ышана алабыз, дигән сүз.

ЛОГИСТИКА АРАЛАРНЫ ЯКЫНАЙТА

Әскәр Сабиров

Кытайдан – Россиягә, ә Россиядән Кытайга йөк ташуны ничек тизләтергә? Һәм әлеге йөкне китереп җиткерү бизнесны бөлгенлеккә төшермәсен өчен нәрсә эшләргә кирәк? «РОСТКИ: Россия – Кытай» халыкара форумы мәйданчыгындагы дискуссиянең нигезен нәкъ менә шул мәсьәләләр тәшкил итте.

«Тотрыклы партнёрлык нигезе буларак логистика бәйләнешләре» – оештыручылар утырышның темасын шулай билгеләгән иде. Темасы шактый тантаналы яңгыраса да, асылына зыян китермәде: стратегик партнёрлар арасындагы транспорт коридорларының бүген ничек үсүе һәм бу үсешне нәрсәләр тоткарлавы турында файдалы сөйләшү булды.

ИҢ МӨҺИМЕ – ВАКЫТ ҺӘМ АКЧА

Оештыручылар иң кыска чыгыш өчен приз бирергә уйласа, Shenzhen Hongtu Ruida International Trade Co., Ltd компаниясе хуҗасы Тан Цзие, мөгаен, төп дәгъвачы булыр иде. Асылда, аның чыгышы ике төп проблеманы билгеләде: вакыт һәм акча. Россия белән Кытай арасында сәүдә үсешендә ихтимал булган кыенлыклар исәп-хисап ясауга (SWIFT түләү системасыннан хәзер мәгълүм сәбәпләр аркасында файдаланырга мөмкин түгел) һәм товарны тимер юл белән ташу вакытына бәйле, дип төгәлләштерде Кытай партнёры.

Проблеманың икенче өлешенә килгәндә, монда Тан Цзие оптимист булуын күрсәтте: тимер юл челтәре шактый тиз үсә, хәзер, аның әйтүенчә, күп товар Кытайдан Россиягә якынча 7–8 көн эчендә килеп җитә. «Күп», аңлашыла ки, барысы да дигән сүз түгел, шулай да Кытай партнёрының бу урында бераз арттыргань

Фото: Александр Рюмин/ТАССның фотохост-агентлыгы, tatar-inform

сизелә. Моны раслау өчен, хәбәрчегез кечкенә генә сынау да үткәрде: форум барган көннәрдә электрон мәйданчыкта Кытайдан товарга заказ бирде. Трекинг исә әлеге товар үткән юлны тәфсилләп күзәтү мөмкинлеген бирде. Нәтиҗәдә: товар сатучы складыннан чик буена кадәр ике көн барды, бер көн – Кытай ягында, аннары дүрт көн Россиядә таможня рәсмиләштерүе узды, шуннан соң бер атна логистика үзәгенә кадәр барды...

Аерым очракны тенденция дип санап булмый, әмма ул иң мөһим нәрсәне күрсәтә: эшне тиешенчә оештырган очракта илләр арасында йөкләрне тизрәк, арзанрак, зуррак күләмдә ташып була. Нәрсә хисабынамы? Дискуссиядә катнашучыларның конкрет тәкъдимнәре җитәрлек булып чыкты.

ТӨЯП БАРА, БУШ КАЙТА

Мәскәү янындагы Селятинодагы логистика үзәге, безнең көннәр. Керү юлларында Кытайдан килгән бик күп контейнерлар тезелгән. Бирегә Россиянең дистәләгән төбәгенә китәргә тиешле йөк агыла. Үз чиратында, моннан Кытайга да экспорт йөкләре китә. Тик шунысы бар: һәр ун импорт контейнерына уртача бер экспорт контейнеры туры килә, дип искәртте форумда катнашучылар.

Ягъни буш ун контейнерның тугызын я йөк көтү урынына куярга, я буш килеш аларга ихтыяҗ булган җиргә – йөзләрчә километр ераклыкка алып китәргә туры килә. Өстәвенә, тимер юлларның үткәрү сәләте чиксез түгел, ә бер урында буш контейнерлар артык булса, икенче урында аларга кытлык күзәтелә. Нәтиҗәне алдан әйтеп була: йөкләрне адресатка җиткерү вакыты да арта, артык манёврлар аркасында, ташу бәясе дә арзанаймый.

Вазгыятьне яхшы якка үзгәртергә сәләтле вариантлар бармы? ТР транспорт һәм юл төзелеше министры Фәрит Хәнифов дискуссиядә катнашучыларга Татарстанның логистика потенциалы турында сөйләде. Бу – Кама агломерациясендә Ден Сяопин исемендәге күпфункцияле логистика үзәге, анда бик күп йөк, шул исәптән экспорт йөк агымы да формалаша (2030 елга агломерациядә 20 миллион тонна продукция җитештереләчәк). Бу – гамәлдәге Зөя мультимодаль логистика үзәге. Аның составында ике километр ярым озынлыктагы причал һәм һәркайсы бер километрдан артык озынлыктагы өч тимер юл бар. Анда параллель рәвештә бер сәгать эчендә 70 вагонны бушатырга һәм зур елга судноларын төяргә була. Бу – әһәмиятле елга, автомобиль магистральләре кисешкән урын һәм халыкара аэропортларга якын ара. Бу, ниһаять, күп кенә сәнәгать үзәкләренә – потенциаль сатып алучыларга һәм, иң мөһиме, Кытайга йөк җибәрүчеләргә кадәр якынча бертигез ераклыкта булу...

ТР транспорт һәм юл төзелеше министры Фәрит Хәнифов «РОСТКИ: Россия – Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» халыкара форумы кысаларында узган «Россия – Кытай: тотрыклы партнёрлык нигезе буларак логистика бәйләнешләре» сессиясендә («Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге).

Нәтиҗә үзеннән-үзе сорала. Потенциаль клиентлар, йөкнең бер өлешен Кытайдан Татарстан логистика үзәкләренә күчереп, вакытны һәм акчаны янга калдыра һәм китерүне дә, җибәрүне дә тизләтә ала. Өстәвенә, Татарстан Республикасында Кытай Халык Республикасына китә торган йөкләр шактый күп, шулай булгач, «унга бер» нисбәте монда була алмаячак.

БАШКАЛА АША – КЫЙБАТРАК

Мәскәүгә юнәлгән йөк агымнарын Татарстанга җибәрүдән мәгънә бармы? Ихтимал, кайберәүләр монда «юрганны үзеңә тарту» омтылышын күрер. Әмма бу очракта мондый шикләр дөрес түгел. Кемгәдер файда эшләүдә берничек тә гаепләп булмый торган бер белгеч, дискуссиядә чыгыш ясап, моны гади һәм профессиональ дәрәҗәдә нигезләп күрсәтте.

– Мәскәүгә бара торган барлык йөкләр дә башкала өчен булмаска мөмкин. Аларның гаять зур өлеше яңадан башка шәһәрләргә, шул исәптән ерак Иркутск, Красноярск, Новосибирск, Владивосток һәм башкаларга таратыла, – дип аңлатты FESCO транспорт төркеме вице-президенты Герман Маслов. – Бу бурычны Татарстанга күчерү һәм анда Мәскәүдәге кебек бүлү үзәге оештыру идеясе – бик яхшы. Башкалага болай да артык күп эш йөкләнгән.

FESCO – дистәләгән диңгез судносы, дистәләгән мең контейнер, бөтен дөнья буенча сузылган маршрутлар һәм күпьеллык тәҗрибә ул. Шулай булгач, шик юк – аның

FESCO линияле логистика дивизионы вице-президенты Герман Маслов.

вәкиленең фикере транспорт-логистика кырындагы вазгыятьне җентекләп белүгә һәм аек акылга нигезләнә. Шунлыктан компаниянең Владивосток – Казан – Владивосток маршруты буенча даими йөри торган дүрт йөк поезды оештыруы, ә агымдагы елның җиде аенда Татарстанга, алдагы 12 ай белән чагыштырганда, ике тапкырга күбрәк йөк ташуы да очраклы хәл түгел.

РФ Президенты киңәшчесе Игорь Левитин.

ТОТКАРЛЫК СӘБӘБЕ ҺӘМ «САКАЛЛЫ» ПРОЕКТ ТУРЫНДА

Аңлашыла ки, Россия кебек зур илдә заманча логистика хаблары ике-өч кенә була алмый. Герман Маслов әйтүенчә, бездә транспорт-логистика үзәкләре, терминаллар һәм деполар үсеше өчен перспективалы шәһәрләр бар. Бу перспективаларның мөмкин кадәр тизрәк чынбарлыкка әйләнүе мөһим. Монда да Татарстаннан өйрәнер нәрсәләр бар, чөнки биредә кыска вакыт эчендә Ден Сяопин исемендәге терминалны эшләтеп җибәрүне күз уңында тоткан масштаблы проект гамәлгә ашырылды.

Икенче яктан, логистика хаблары – идеаль тәэминат чылбыры буыннарының берсе генә бит әле. Әгәр контейнерлы составлар, тимер юлга төшкән зур йөкләнеш аркасында, ташбака тизлеге белән генә шуышса, тәүлекләр буе таможня һәм чик пунктларында документ көтсә яки, транспорт челтәре үсмәгәнлектән, йөзләрчә километр артык юл урап узса, хабларның барлык өстенлекләре юкка чыгарга мөмкин.

Һәм бу, әйтергә кирәк, фаразлар гына түгел. РФ Президенты киңәшчесе һәм РФ Президентының транспорт өлкәсендәге халыкара хезмәттәшлек буенча махсус вәкиле Игорь Левитин гади мисал китерде. Россиядәге киң тимер юл колеясы дустанә ил чикләрен кичкәннән соң ук тәмамлана дияргә була. Димәк, безнең чикне үтүгә тар колея башлана. Шул сәбәпле, йөкләрне рәсмиләштерү һәр якта кечкенә генә участокларда алып барыла, бу, әлбәттә, үткәрү сәләтен нык тоткарлый. Совет чорында исә «чит» колея – безгә, ә безнеке күршеләргә шактый эчкәрәк керә торган булган. Бу йөкне таможня аша уздыруны һәм чик буе тикшерүен тизләткән. Шулай булгач, нигә әлеге уңай тәҗрибәне кире кайтармаска соң?

Фәрит Хәнифов тагын бер күптәнге проблеманы искә төшерде. Аның әйтүенчә, совет чорында ук Яранскидан Котельничка кадәр юл участоклары төзү идеясе булган. Бу 180 километрлы участок Транссибның төньяк һәм көньяк юлларын тоташтырырга мөмкинлек бирергә, якын арага гына түгел, ерак җирләргә дә йөкләр илтүне сизелерлек тизләтергә тиеш. Үз вакытында проектның техник-икътисади нигезләмәсе әзерләнгән булган, ләкин эш башланмаган. Бүген Татарстан Республикасы инициативасы белән яңадан шул эшкә алынмакчылар...

ДИҢГЕЗ БУЙЛАП – САНКЦИЯЛӘРСЕЗ

Йөк ташуларны диверсификацияләү – җитди резерв, аңардан башка йөкләр күләмен сизелер дәрәҗәдә арттыру, тарифларны оптимальләштерү өчен кирәкле сәламәт көндәшлекле мохит булдыру мөмкин түгел. Татарстанда шул максаттан, аерым алганда, елга транспортында пассажирлар ташуны үстерү каралган. Юллар челтәрен камилләштерү – шулай ук тимер юлларга йөкләнешне киметү ысулы: бүген автомобиль транспорты инде йөкләрнең шактый өлешен ташый. Ә дәүләтара масштабтагы мөһим адымнардан берсе – бернинди санкцияләр янамый торган Төньяк диңгез юлын үстерү.

– Без инде өченче ел бу маршруттан файдаланабыз, – дип сөйләде форумда NewNew Shipping генераль директоры Кэ Цзинь. –

NewNew Shipping генераль директоры Кэ Цзинь.

Кызганыч ки, ул ел әйләнәсе эшләми, июльдән ноябрьгә кадәр генә файдаланыла. Шул арада без мөмкин кадәр күбрәк йөк ташып калырга тырышабыз.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Төньяк диңгез юлы Кытайдан РФнең Европа өлешенә Архангельск аша принципиаль яңа маршрут ачарга мөмкинлек бирә, бу тимер юлларының артык йөкләнеше шартларында бик кирәк. Алай гына да түгел, «Архангельск экспрессы» – бу маршрутны шулай атаганнар – тиздән сезонлы гына булмаячак. Төньяк диңгез юлын үстерү федераль проекты нигезендә, анда навигация ел әйләнәсе булачак, бу бизнес өчен, шул исәптән Кэ Цзинь әфәнде һәм аның компаниясе өчен яңа мөмкинлекләр ачачак.

ЦИФРЛАШТЫРУ ЯРДӘМЕНДӘ ИСКЕЛЕКТӘН КИТҮ

Катнашучылар фикер алышкан проблемаларга бәя биреп, иң җитдиләрен хәл итү өчен тиешле югарылык кирәк, дигән нәтиҗәгә киләсең. Төбәкләр һәм ике илнең бизнес-структуралары дәрәҗәсендә хезмәттәшлекне үстерү өчен шулай яхшы эшли торган Казан форумы, ихтимал, кайвакыт әлеге югарылыкка күтәрелә алмыйдыр. Һәрхәлдә, «РОСТКИ: Россия – Кытай» халыкара форумында яңгыраган тимер юл челтәрен камилләштерү буенча конструктив тәкъдимнәр, сөйләшүдә РФ Транспорт министрлыгы һәм Россия тимер юллары җитәкчелеге дә катнашса, мөгаен, тизрәк тормышка ашырылыр иде. Кызганыч...

Хәер, форумда Игорь Левитинның катнашуы әлеге тармактагы проблемаларның, буш сүз генә булып калмыйча, җитди өйрәнеләчәгенә өмет уята, шул исәптән профильле федераль ведомстволар тарафыннан да. Сүз уңаеннан, нәкъ менә Президент киңәшчесе халыкара транспорт юлларын оптимальләштерү юнәлешендә тагын бер җитди киртә турында искә төшерде. Сүз йөкләр өчен документлар рәсмиләштерүнең искергән технологиясе турында – ул һаман узган гасырдан күчкән килеш саклана. Бүген, спикер сүзләренчә, йөккә 136 (!) төрле документ рәсмиләштерергә кирәк, һәм болар барысы да кулдан эшләнә икән. Бурыч – аларның санын унсигезгә кадәр киметү, цифрлаштыру ярдәмендә искелектән һәм бюрократиядән китү.

Цифрлы технологияләр – оптималь логистика маршрутлары төзергә һәм аларның максималь тотрыклылыгын, нәтиҗәлелеген тәэмин итәргә сәләтле төп ресурсларның берсе, мөгаен, шушыдыр. Форумда билгеләп үтелгәнчә, бурыч – аерым бер чишелешләрдән транспорт инфраструктураларын, логистика сервисларын һәм норматив процедураларны системалы интеграцияләүгә күчү. Яңа заман юлның үткәрү сәләтенә, йөкләрне эшкәртү тизлегенә, логистика схемаларының аңлаешлы булуына югары таләпләр куя, һәм монда цифрлы технологияләрдән башка бернишләп тә булмый инде.

Алардан файдалану исә – инде киләчәккә ориентир түгел. Игорь Левитин хәбәр иткәнчә, Россия Президенты кыска вакыт эчендә Милли транспорт цифрлы платформасын булдыру бурычын куйган. Глобаль һәм бик катлаулы бурыч, монда безгә дустанә ил тәҗрибәсе ярдәм итә ала: Кытайда милли цифрлы транспорт платформасы инде булдырылган һәм уңышлы эшли.

КЫТАЙГА ЙӨЗ ТОТКАН ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЫ

КФУ НИ ӨЧЕН КЫТАЙ БЕЛӘН ИКЕ АРАДА МӘГАРИФ КҮПЕРЕ ТӨЗИ

Олеся Бондаревская

Геосәясәт фән һәм студентлар кооперацияләре өчен яңа маршрутлар ачкан дәвердә Казан федераль университеты Көнчыгышка йөз тота. Татарстан югары уку йортлары арасында халыкара бәйләнешләр буенча иң алдынгы уку йортларының берсе – КФУның Идарә, икътисад һәм финанслар институты Кытайның төп университетлары белән партнёрлык элемтәләре урнаштыра. Беренче чиратта Кытай Халык Республикасының инженерлык тармагындагы иң абруйлы югары уку йорты – Пекин технологияләр институты (BIT) белән студентлар алмашы программасы.

BIT – 30 меңнән артыграк студент, җитди академик база һәм глобаль фәнни контекст. Безнең студентлар өчен ул чит илдә белем алу гына түгел, ә киләчәктә инженерлык, цифрлы һәм икътисади трансформацияләр лидерларының дөньякүләм мохитенә эләгү дә, – дип сөйли Икътисад институтының халыкара эшчәнлек буенча директор урынбасары Руслан Галиәхмәтов.

КФУ белән BIT арасындагы килешүгә 2023 елның октябрендә кул куелган. Программа КФУ студентларына Кытайда «Халыкара икътисад һәм сәүдә» һәм «Компьютер фәннәре» юнәлешләрендә берәр семестр укып кайту мөмкинлеге бирә, укыту инглиз телендә алып барыла.

– Дисциплиналарны студент мөстәкыйль рәвештә үзе сайлап ала. Әгәр предметлар КФУның уку планы белән туры килә икән, аларны кертеп җибәрергә була. Бу бик мөһим: без халыкара тәҗрибәне мондагы уку йортындагы академик процесска зыян салмыйча интеграцияләргә тырышабыз, – дип төгәллек кертәләр икътисад институтында.

Семестр программаларыннан тыш, интенсив форматлар да бар – BITның җәйге һәм кышкы мәктәпләре, аларда инновацияләр, ясалма интеллект, лидерлык һәм мәдәниятара тәҗрибәгә басым ясала.

НИ ӨЧЕН КЫТАЙ? НИ ӨЧЕН ХӘЗЕР?

Россия һәм Кытай университетлары арасындагы хезмәттәшлек бүген, формаль партнёрлык кысаларыннан чыгып, бу ике илнең уку-укыту стратегиясенең мөһим өлешенә әверелә бара.

– Татарстан тарихи яктан Азия юнәлешенә ачык. Кытай югары уку йортлары үзләре үк хезмәттәшлек итүгә кызыксыну белдерә, ә КФУ – Россиядәге иң билгеле һәм ышанычлы партнёрларның берсе. Бу – синергия, аны ныгытырга кирәк, – дип ассызыклый институт вәкиле.

Әлеге башлангычка ике ел да юк әле, әмма бүген инде программада КФУның дистәләгән студенты катнаша, аларның яртысы – Идарә, икътисад һәм финанслар институтыныкы. Университетта шуны ассызыклыйлар: бу әле башы гына. Алда – студентлар алмашын киңәйтү, берьюлы ике диплом бирү программасы һәм тотрыклы академик бәйләнешләр булдыру. Шул ук вакытта ике диплом программасын рәсмиләштерү вакыт таләп итә: аның гамәлгә ашыру 2026/27 уку елына планлаштырылган.

МӘДӘНИЯТАРА ҮСЕШ МӘЙДАНЧЫГЫ

Икътисад институты студентлары өчен программада катнашу ул – академик тәҗрибә генә түгел, мәдәниятара үсеш өчен гамәли мәйданчык та. BITта алар кытай телен өйрәнә, башка уку-укыту системасының көндәлек тормышы белән таныша, болар барысы да киләчәктә файдалы булачак.

– Безнең студентлар үзенә күрә мәдәни илчеләр булып китә. Алар Кытайда КФУны гына түгел, Татарстан, Россияне дә тәкъдим итә. Халыкара проектларда катнашу – төбәкнең халыкара имиджына инвестицияләр ул, – диде институт вәкиле.

Кытай ягыннан да кызыксыну зур: уку-укытуда алмашу – «Пояслар һәм юллар» дәүләт стратегиясенең бер өлеше, һәм Россия партнёрлары анда фәнни-уку-укыту интеграция өлкәсендә потенциаль автордашлар буларак карала.

ЯҢА БУЫН КОМПЕТЕНЦИЯЛӘРЕ

Университетлар арасында уңышлы хезмәттәшлек рәсми килешүләр генә таләп итеп калмый, белгечләрнең тиешле компетенцияләре булуы да мөһим. Икътисад институтында инглиз теле аралашу теле булып кала, шул ук вакытта кытай телен белү шактый зур өстенлек бирә, дип ассызыклыйлар.

– Мәдәниятләрне һәм телне белү беренче планга чыга. Кытайдагы хезмәттәшләр белән аралашу күнекмәләрен камилләштерү, эшлекле һәм уку-укыту мәдәниятен аңлау бик мөһим булуын күрәбез. Институтта әлеге юнәлешне тирәнәйтү буенча эшлибез, – дип раслыйлар икътисад институтында.

МАСШТАБНЫҢ НӘТИҖӘСЕ: ИНСТИТУТ КҮЛӘМЕНДӘ ҺӘМ ШӘХСИ МИСАЛДА

Университет дәрәҗәсендә проект КФУның халыкара мәйдандагы урынын, абруен ныгыта. Идарә, икътисад һәм финанслар институтында, мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек максатыннан, инде Кытайның башка университетлары белән дә сөйләшүләр алып барыла. Беренче нәтиҗәләр дә бар: ул – студентларның трансформациясе.

– Мондый программаларда катнашкан студентлар белем генә алып калмый. Алар халыкара мохиттә эшләү тәҗрибәсе туплый, фикерләүдә сыгылмалылыкка өйрәнә, дөньядагы үзгәрешләргә җавап бирергә һөнәри яктан әзерлек ала. Һәм бу аларны Россиядә генә түгел, дөнья базарында да көндәшлеккә сәләтле итә, – дип, сүзен йомгаклый институт вәкиле.

КФУның халыкара хезмәттәшлек даирәсендә Кытай юнәлеше – стратегик адым, ул булачак белгечләрнең һөнәри һәм шәхси үсешенә менә дигән мөмкинлекләр бирә. Мондый проектлар глобаль мәгариф даирәсендә университетның урынын ныгыта һәм күптелле, күпмәдәниятле, заманча технологияләргә йөз тоткан мохиттә эшләргә әзер белгечләрнең яңа буынын тәрбияли.

Фото: КФУның Идарә, икътисад һәм финанслар институтыннан. РЕКЛАМА



«МИРАС»: КАЗАННЫ ЯРАТЫР ҺӘМ ДӨНЬЯ КҮЛӘМЕНДӘ ТАНЫТЫР ӨЧЕН...

Луиза Янсуар

Быелгы җәйге мәдәни вакыйгалардан казанлылар белән килгән кунаклар, туристларның хәтерендә иң тирән эз калдырганы, мөгаен, Казан циркының «Мирас» («Мираж») программасы булгандыр. Ул 12 июньнән старт алды да 14 сентябрьгә кадәр бара. Сентябрь тамашаларына билетлар инде август аенда ук сатылып беткән иде. Без милли программа чыгару бурычын цирк алдына ТР мәдәният министры Ирада Әюпова куйганын һәм спектакль-фэнтезиның өч ел дәвамында әзерләнгәнен беләбез. 2025 елның 27 августында, Республика бәйрәме һәм шәһәр көне программасы кысаларында, «Мирас»ны Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов та карады.

ЭКЛЕКТИКА ҺӘМ БАЛАНС

Әйтүләре буенча, Рәис яңа милли тамашаны бик ошаткан – артистларны аягүрә басып алкышлаган. Җәйге тамашаларга Петербургтан кайткан туганнар һәм башка шәһәрләрдән килгән дусларны да алып барган идек, алар да, нәкъ Рәис кебек, аягүрә басып, «Афәрин!» дип алкышладылар. «Дөньяның теләсә кайсы почмагына алып барып, федераль һәм аннан да киңрәк масштабта күрсәтә торган универсаль эчтәлекле, бик колоритлы тамаша килеп чыккан», – дип сокландылар. Республика халкы, бигрәк тә журналистлар белән мәдәният өлкәсендә кайнашучылар да, яңа тамашаны карап, бик рухланды. Бераз гына сарказм өстәүдән дә тәм тапты: ниһаять, цирк татар тамашачысына, үз милләтенә йөз белән борылды, болай булгач, әле опера-балет театрына да өмет сүнмәгән, диештеләр...

Фотолар: ТР Рәисе матбугат хезмәтеннән һәм ТР Казан дәүләт циркы архивыннан

Дөресен генә әйткәндә, пилот рәвешендәге сынау проекты инде моңа кадәр үк эшләнгән иде – 2024 елда цирк, яшь тамашачыларны һәм яңа аудиторияне җәлеп итү максаты белән, Илгиз Зәйниевне чакырып, «Печән базары»н чыгарды. Ул чакта ук театрның яңа директоры Эльмира Булатованың болай дип әйткән сүзләре хәтергә уелып калды:

– Сәнгатьнең ике бу төрен – театр белән циркны бербөтенгә берләштерү гаять катлаулы эш, чөнки цирк ул – тавыш-тынсыз гына башкарыла торган могҗиза.

Миңа иң башыннан ук сюжет корылышы, драматургик башлангыч белән пролог ошады, әмма, кызганыч, ул алга таба онытылды. Бик шәп, техник һәм сәнгати югарылыкта куелган бер чылбырны тәшкил иткән тамашаны күбрәк «связка»лар бәйли башлады. Кыскасы, миңа сценарий ягыннан эзлеклелек, бөтенлек җитеп бетмәде. Мин безгә Милли Мирас турында яңа бер мавыктыргыч тарих сөйләүләрен, көчле нарратив көткән идем... Әмма үземне нәкъ менә әлеге дә баягы Эльмира ханым әйткән сүзләр белән тынычландырдым: чынлап та, без бит драматик тамаша үзәгендә утырмыйбыз, бу – башка жанр һәм аның кануннары икенче.

Иң ошаганы – интерактив бик күп, һәм ул тамашага килгән балаларны гына түгел, ә өлкәннәрне дә мавыктыра, җәлеп итә. Дөрес, клоунада тулаем русчага корылган, ул бик оста куелган, ләкин милли контексттан бераз «чыгып киткәли», димме соң... Хәер, клоунададан да миллилек эзләргә тырышу дөрес нәрсә түгелдер инде ул...

Этнографик нигез белән аутентик детальләрне, җирлекне һәм мифологик катламны алып, аны заманча бирелештә тәкъдим итәләр, нәтиҗәдә, куелыш теләсә кайсы милләт вәкиле өчен аңлаешлыга әверелә. Ике телдә дә бара «Мирас», билгеле, русчасы күбрәк. Ләкин моны халыкта киң таралган, чын мәгънәсендә «милли хит» булып киткән җырлар каплый, тигезли. Музыкаль мирасны чынлап та туплап бирәләр – «Әллүки» белән «Зәңгәр шәл» яңгыраганда, зал елап утыра. «Туган як», «Кайтам әле Әлдермешкә» җырлары яңгыраганда, оркестрга кушылып, кубарылып җырлый. Карале, кем әйтмешли, чыннан да үз вазыйфасын башкара икән бит бу җырлар, дип гаҗәпләнеп утырдым. Мин үзем, дөресен генә әйткәндә, тулаем яңа музыкаль партитура көткән идем...

Куелыш эклектик, синтетик характерда. Костюмнар белән декорацияләр, күренеп тора, искиткеч бай, затлы, җиренә җиткереп эшләнгән. Гомуми бизәлештә дә гармония белән баланс бар. Вакыт-вакыт чуарлык күп тоелса да, стилизацияләрдән караш уйнакласа да, эстетик яктан барысы да уйлап башкарылган. Матур табышлар бар, алардан елмаеп җибәрәсең. Ут куючыларга сокланып карадым – ул бөтен спектакльне могҗизаи итеп өретә, сихерле төсмер өсти.

Мин беренче мәртәбә караганда, тирәягымда татар журналистлары – «Татмедиа» системасында эшли торган хәбәрчеләр утырды. Барыбыз да, цирк артистлары белән аның командасына, анда тәрбияләнгән яшь буынга сокланып, тел шартлаттык. «Без һаман драма артистлары белән эстрада йолдызлары турында язабыз, аларны пьедесталга күтәрәбез, ә бу бит – тир түгеп, еллар буе әзерләнеп эшләнә торган бәһасез хезмәт, аларны күрмибез-белмибез», – диеп, үзебездән үзебез оялыштык. Чыннан да, цирк артистларының хезмәте баш иеп, рәхмәт әйтеп, үзләрен кулда гына күтәреп йөртергә лаек.

Ярар, монысы – эмоцияләр, күзәтүләр. Ә хәзер саннарга, фактларга һәм анализга күчик. Цирк җитәкчелеге белән иҗат командасына һәм тамашачыга сүз бирик.

Бала чактан циркны яратмаган, анда принципиаль рәвештә йөрмәгән мине «Мирас» спектакле үзгәртте дә куйды! Циркка, анда хезмәт куючыларга бөтенләй башкача карый башладым!

Гөлүсә Батталова, «Мирас» спектакленең җыр текстлары авторы

«ХАЛЫК ҮЗЕ СОРАП АЛДЫ!»

Циркның пиар бүлеге, тыйнаклык күрсәтеп: «Без, һәрвакыттагыча, башка проектларны таныткан кебек үк, үз эшебезне генә эшләдек», – дисә дә, «Мирас»ның рекламасы шаккаткыч, бик югары дәрәҗәдә булды. Аның республика җитәкчелеге тарафыннан бурыч итеп куелган, чын мәгънәсендә, Казан халкын һәм бар дөньяны шаккатыруга йөз тоткан кыйммәтле, бай, стратегик проект булуы шунда ук үзен сиздерде. «Казан циркындагы өр-яңа милли спектакль-

фэнтези», «тиңсез шоу» турында мәркәзебез буйлап таралган барлык баннерлардан, радио, телевидение, социаль челтәрләрдән тәүлек әйләнәсе ишетеп тордык. Промо-роликлар, рәсми тизерлар да җәлеп итәрлек иде. Кыскасы, экияти җен чыгып, лампа белән үтүктән генә кычкырмады. Билет бәяләре башта бераз тешләшә торган тоелды, әмма сатып алган беркем дә үкенеп кайтып китмәгәндер, дип уйлыйм. Куелышы тулысы белән 100 миллион сумга төшкән, әле моңарчы Россия күләмендәге шоу индустриясендә дә кулланылганы булмаган «ут дивары»на кадәр дөрләп күтәрелгән 2 сәгать тә 40 минутлык (антракт белән) бу шоу үз бәясен акларлык дәрәҗәдә иде.

> Әгәр кешене көн саен аның яраткан ризыгы, ягъни бертөрле тамаша белән генә «сыйлап» тора башласаң, озакламый ул аны бик нык туйдырачак.
>
> **Эльмира Булатова, Казан циркы директоры**

Казан циркы директоры Эльмира Булатова белән сүз башлаганда, иң беренче эш итеп, республика Рәисенең тәэсирләрен белештек.

– Бик ошатты, рәхмәт әйтте. Безнең тамашаны барлык дәүләт эшлеклеләре белән республика кунакларына күрсәтергә кирәк, диде. Өч ел элек, Казанга күчеп килгәндә үк, мондый милли программаның соралып торганын аңлый идем инде, – дип сөйләде Эльмира ханым. – Мәдәният министры Ирада Әюпова бу бурычны минем алдыма конкрет куйды. «Печән базары»н чыгаргач, чынлап та, халыкның үз милли тамашасына сусавы никадәр көчле булуын аңладык. Нибары 8 генә тамаша күрсәттек, ә рәхмәтләр белән яңа милли программа эшләргә тәкъдимнәр олаулап килде. Шуңа да «Мирас»ны канатланып, рухланып эшләдек – моның халыкка кирәк икәнлеген төгәл белеп. «Мирас»ны халык үзе сорап алды, дисәк тә, ялгыш булмас.

Киң колачлы милли спектакль-фэнтезины тормышка ашырыр өчен, Мәскәүдәге Цветной бульварда урнашкан Никулин циркы режиссёры Евгений Швецов сайлап алына. «Мирас»ны сәхнәгә Мәскәүдән килгән чын профессионаллар командасы куя: балетмейстер Ольга Полтарак, рәссамнар Надежда Русс һәм Анатолий Нежный, композитор Дмитрий Кузнецов, клоунада режиссёры Андрей Шарнин. Проектның музыкаль юнәлештә консультанты, музыкаль җитәкчесе буларак җырчы, музыкант, «Болгар кызлары» триосы солисты Айгөл Зәйнуллина чакырыла. Һәм, әлбәттә инде, җыр текстларын язуны да җирле иҗатчыга тапшырырга кирәк табалар – шагыйрә, драматург Гөлүсә Батталованы җәлеп итәләр.

– «Бишек җыры» һәм «Зөһрә җыры»ның текстларын язганда, режиссёрның теләк-тәкъдимнәрен исәптә тоттым, милли фольклорга нигезләнгән материал тудырырга тырыштым, – ди Гөлсүә Батталова. – Иҗат командасы белән эш процессы минем өчен яңа тәҗрибә булды. Проектның җитәкчесе Илназ Хәйбуллин турында аерым әйтеп үтәсем килә. Иҗат кешесенә булган игътибарлы мөнәсәбәте, алга карап эш итә белүче чын стратег икәнлеге ачылды. «Мирас»ны гаиләбез белән карадык. Премьера көннәре күптән узган булса да, зал шыгрым тулы иде. Балаларым белән театр-концертларга еш йөргән әни буларак, алдан ук хәл итеп куйган идем: 30-40 минуттан арый-туячаклар, антрактка кадәр түзеп утыра алсалар, кайтып та китәрбез, янәсе. Тик кая ул! Спектакль башланган мизгелдән ахыргача, авызларын ачып, аһ итеп карады улларым! «Мирас»ны караган башка таныш-белешләр, дуслардан да бары яхшы сүзләр генә ишеттем. Цирк тамашаларына да милли төсмер керүенә, милли спектакльләрнең аншлаг белән узуына шатмын. Киләчәктә тагын да сыйфатлырак, кызыклырак спектакльләр тусын өчен ихтыяҗ барлыгын күрсәтә бит ул.

Айгөл Зәйнуллина инде «Мирас»ны хәзер үк сагынуы турында әйтә, ул яңадан сәхнәгә әйләнеп кайтсын, югалмасын иде, дип тели. Килешми булдыра алмыйбыз.

– Безнең милли колорит белән даими очрашып тормаган иҗат командасына, бу җирлекне өйрәнеп, программаны халык үзенеке итеп яратырдай кимәлдә башкарып чыгу – зур батырлык. Алар безнең мираска зур саклык, ярату белән орынды, тәкъдимнәребезгә колак салып эшләде, тыңлады, ишетте. «Мирас» буенча эшне башлап җибәргәнче, проект җитәкчесе Илназ Хәйбуллин белән, Мәскәүгә Никулин циркына барып, режиссёр һәм хореографның «Матрёшка» спектаклен карап кайттык. Бик ошаттык! Йөрәген биреп эшләүләренә сөендек. Миңа калса, без тамашачыга халкыбыз җанында яшәгән моңны күрсәтеп бирә алдык. Эшләү процессында тәүлекләр буе ял итмәгән вакытлар да булды, әмма һәркем бу проектны зур ярату белән, дөньясын онытып тудыр-

ды. Бу яратуны тамашачы да тоя. «Мирас»ны 10 мәртәбә карадым, һәр караганда, беренче тапкыр күргән шикелле... Музыкаль өлешен әзерләгәндә, милләтебезнең үткән мирасын да, заманча мирасын да бер бәйләмдә бирергә омтылдым... Үзем өчен циркны өр-яңадан ачтым, һәм аңа гашыйк булдым!

КАТЛАУЛЫ ГАДИ АРИФМЕТИКА

Чыннан да, программа милли персонажлар, сюжетлар, мотивлар, мифлар, бәйрәмнәр, традицияләр белән шыплап тулган татар энциклопедиясе, диярсең. Барысы да бар монда – Сабан туе да, ат чабышлары да, сарыгы да, Шүрәлесе дә, Батыры да, азакта хәтта Тукай үзе дә... «Милли скреплар» дигәндә, без «алар беркайчан да аз булмый, артып китсә дә, зыян юк, үзебезнеке ич» дигән мантыйк белән эш йөртәбез.

Классик цирк номерлары һава гимнастлары, акробатлар, эквилибристлар, жонглёрлар һ.б. гаҗәеп осталардан гыйбарәт. Мин циркка хайваннарны тилмерткәннәрен күрмәс өчен йөрми торган кеше буларак, бу юлы хәтта аю белән бәтиләр чыккач та, артык авыр тойгылар кичермәдем. Әллә бәтиләре дә «үзебезнеке» булып тоелганга шунда...

Әмма хикмәт башкада – бу искиткеч күп персонаж һәм мотивларны берләштергән тамаша ни дәрәҗәдә чын-чынлап без инде күп еллар буе тел корытып сөйләгән «мәдәни код»ны ача алды икән? Ни дәрәҗәдә декортаив «тамаша» гына булып калмыйча, асылыбызны күрсәтеп бирде? Бәлки, без цирк программасына артык зур таләпләр куябыздыр? Нигездә, бу спектакль бит тамашачыда, бигрәк тә килгән кунаклар белән туристларда татар дөньясына ишекләрне ачты, кызыктырды, сокландырды, аһ иттерде. Димәк, шушы ачык ишекләрдән эчкәрәк узарга, бу халыкның мирасын тирәнрәк белергә дә ихтыяҗ тудырды, дия алабыз. Ә бу – иң мөһиме!

Эльмира ханым әйтүенчә, «Мирас», һичшиксез, коммерцияле проект. Казан циркы аны үз акчаларына чыгара. Билгеле, Мәдәният министрлыгы барлык этапларда бик яхшы булышты, бөтен яклап куәтләп торды, күперләр салды, ди директор, әмма бик күп чыгымнар үз җилкәләренә дә төшкән.

Җәйге каникуллар вакытында «Мирас»ны карарга гаиләләр белән балалар агылды. Без турыдан-туры балаларны алып килмибез бит, моның белән гаиләләр, төрле оешмалар шөгыльләнә, диләр администрациядә. Чынлыкта, хәйрия оешмалары, социаль хезмәтләр, ниндидер предприятиеләр, хезмәткәрләренең балалары өчен сатып алып, күп караган булып чыкты спектакльне. Моны циркның үз статистикасы да раслый, Казан буйлап «карамаучыларга» караганда, «караганнарны» да күбрәк очратасың. Менә шундый гап-гади арифметика.

– 125 мең кеше, – дип, саннар белән уртаклаша цирк директоры. – Тамашачыларыбызның географиясен күзәтәбез. Дөрес, тере акчага үзе кассага килеп билет алучыларны сагалап тора алмыйбыз, ә менә сайтта онлайн алучылар турында хәбәр бар. Һәм бу география безне куандыра: Россия Федерациясенең барлык регионнары! Владивостоктан алып, Калининградка кадәр! Читтән килгән тамашачы искиткеч күп булды – Казахстан, Белоруссия, Әрмәнстан, Азәрбайҗан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Германия, Румыния, Вьетнам, Гарәп Әмирлекләре, Сингапур, Малайзия, Таиланд, АКШ... Татарстан районнарыннан гаиләләп, төркемләп килеп караучылар турында инде әйтеп тә тормыйбыз...

ЕРАК СӘФӘРЛӘР ҺӘМ КИЛӘЧӘК СТРАТЕГИЯСЕ

«Мирас»ны әзерләгәндә үк, Казан циркы, үз артистларыннан тыш, читтән дә артистлар командаларын җәлеп иткән иде. Бу, билгеле, куелышның үзен дә, аны йөртүне дә, түләү системаларын да шактый катлауландыра. Программада Мәскәү, Якутия, Белоруссия циркы артистлары да катнаша, шулай ук – Казан Балалар цирк мәктәбе укучылары. Озын сүзнең кыскасы, шоуда барлыгы – 80 нән артык кеше! Азмы бу? Күпме? Әле бит арена артында калган күпме хезмәткәрне дә исәпкә алсаң, шактый грандиоз картина күз алдына килеп баса. Юкка гына «Мирас»ны дөнья буйлап гастрольләрдә йөри торган күчмә программалы кабатланмас Дю Солей белән чагыштырмыйлар бу очракта. Читтән килеп караган кунаклар кат-кат кабатлап та әйтте, циркның сайтында, социаль челтәрләрендә күпсанлы комментарийлар да калдырды: «Бу тамашаны,

– «Мирас», бүгенге көндә милли мәдәни мирасыбызны музей яссылыгына күчермичә, тере килеш саклап эш итүнең заманча бер үрнәге. Бик көчле идея: татар мифларын, әкиятләрен алып, аларны цирк аренасына чыгару, башка тел белән сөйләп бирү. Динамик видеоларга һәм җете сурәтләргә иярләшкән яшь аудитория белән диалог төзи алу. Техник яктан бар да югары кимәлдә, шунда ук күренеп тора: кыйммәтле, зур көч кертеп эшләнгән спектакль. Масштаблар киң. Әмма сорау кала: ни дәрәҗәдә мәдәни асылыбызны аңлау, мәдәни кодны тою икән бу? Хәер, төгәл реконструкция ясау бурычын куймый бугай «Мирас», аның максаты икенче – тамашачы белән ике арада эмоциональ күпер булдыру, атмосферага кертеп күмү. Бу белгечләрнең махсус акваланг белән тирән төпкелләргә төшүенә түгел, ә матур яхтада хозурланып диңгезне карап йөрүгә тиң. Әмма гаять уңышлы гибрид. Әлбәттә, фольклор ансамбле дия алмыйбыз, әмма технологик яктан искиткеч затлы эшләнгән аттракцион гына да булып калмаган. Казан өчен бу проект аның мәдәни картасында бик әһәмиятле нокта.

Резеда Гарипова, режиссёр, педагог

– Чын күңелдән сокландык, Казанның мондый югары дәрәҗәдәге программа чыгаруы белән горурландык. Фантастика! Мәдәни шок! Гаиләбез белән дөнья буйлап күп сәяхәт иткәнебез, бик күп кызыклы программалар караганыбыз бар. «Мирас» – соңгы арада күргән иң сыйфатлы, мавыктыргыч шоуларның берсе! Казанда да аны әле тагын күрсәтсеннәр, репертуардан алмасыннар! Моны һәр татар баласы күрергә тиеш, республика мәктәпләргә бушлай килеп карау мөмкинлеге тудырса да була, «максатчан күрсәтүләр» оештырса да. Респект сезгә, Казан!

Вероника Кордовина, балалар психологы, педагог, Санкт-Петербург

– Бөтен гаиләбез һәм туганнар белән бардык. Мондый тамашалардан соң, Казанны, туган ягыңны, аның мәдәниятен тагын да ныграк ярата башлыйсың. Залның дәррәү торып, Татарстан циркына кул чабуына сөенеп, горурланып кайттым. Читтән килгән кешеләр, туристлар күп иде. «Без булдырабыз!» диган тойгы калды.

Камил Ә., төзүче, Яр Чаллы

дөньякүләм турне итеп оештырып, барлык илләр буйлап күрсәтеп чыгарга кирәк!»

Бу җәһәттән, кайбер килешүләр инде алдан ук билгеләп куелган, дип беләбез, әйтик, әлеге дә баягы Белоруссия циркы белән. «Казандагы программа тәмамланугa, сез Белоруссиягә юл тотарга җыена идегез, хәзерге вакытта әзерлек барадыр?» – дип, кабат директорга мөрәҗәгать итәбез. Гастрольләргә әзерлек ничек баруы белән кызыксынабыз.

– Әйе, бу бик катлаулы процесс – шундый зур программаны, беренчедән, тәрҗемә итү, программа-буклетларны яңадан эшләү, декорация, костюмнар, реквизитларны җыеп озату, хезмәткәрләрне туплау, хайваннарны ерак юлга хәстәрләү, техник җиһазларны әзерләү, логистиканы дөрес итеп оештыру.

– Сезгә теләсә кайсы пространство да туры килмидер әле, – дип фаразлыйм. – Программаның колачы да зур, үзенчәлеге дә гади генә түгел, техник яктан да яхшы җиһазланган, яңа биналар сораладыр...

– Чынлап та, һәрбер пространство моңа туры килми, – дип килешә Эльмира ханым. – Әмма Минскидагы цирк – стационар, бик иркен, аның «Мирас» кебек тамашаны кабул итү һәм күрсәтү мөмкинлеге бар: зур сәхнә арты киңлеге, гөмбәзнең җитәрлек биеклеге, техник потенциал. Без инде бу сәфәргә июльдән әзерләнә башладык. Минск циркына техник райдер җибәрелде, кабул итү өчен алар тиешле әзерлек эшләре алып бара. Мәсәлән, Казан циркы манежындагы кебек үк матурлыкны кабатларга мөмкинлек тусынга, яктылык җиһазларын арендага алып торачаклар...

Югарыда әйткәнебезчә, Казанда программа 14 сентябрьдә тәгәлләнәчәк, ә 27 сентябрьдән алып 30 сентябрьгә чаклы Казан циркының Минск шәһәрендәге гастрольләре башлана. Белоруссия циркы үзләренең сайтында һәм социаль челтәрләрендә «Мирас»ны зур энтузиазм, горурлык белән «уртак проект» буларак тәкъдим итә. Кереп карадым: билетлар яхшы сатылган, буш урыннар юк диярлек.

Минскидан тыш, программаны тагын кайда күрсәтергә ниятлиләр икәнен белешәм. Чынлап та, Татарстан бренды буларак, «Мирас» белән үзебезне дөньяда танытырга кирәктер һәм буладыр да, дип уйлыйм. Әйтик, шул ук стартегик һәм бизнес-партнёрыбыз булган Кытай тамашачасына, БРИКС илләре вәкилләренә...

– Чит илләрдәге цирклар белән сөйләшүләр бара, – ди Эльмира ханым. – Әмма бу этапта әле исемләп әйтә алмыйм. Шунысын төгәл әйтә алам: «Мирас» турындагы хәбәр бөтен цирк дөньясына таралды. Без алга таба татар мәдәнияте белән, ким дигәндә, берничә илне таныштырырга өметләнәбез.

– Циркның бу юнәлештә, ягъни милли нарратив һәм колорит белән алга таба үсешен күрәсезме? – дип тә сорамый кала алмыйм.

– Шулай да, цирк ул барыннан да элек төрлелек, – дип елмая Эльмира ханым. – Циркта милли колоритлы программалар гына эшләсәк, тамашачылар өчен бу тиздән гадәти хәлгә әвереләчәк, алар андагы матурлык һәм уникальлекне күрми, бәяләми башлар. Шуңа, дөньяның барлык циркларында кабул ителгәнчә, программаны төрле планлы һәм жанрлы итеп формалаштырабыз, тамашачыны яңа, кызыклы нәрсәләр белән гаҗәпләндерергә тырышабыз. Шулай да, киләсе милли программа нинди булыр, дип уйлый башладык инде, бу хакта Мәдәният министрлыгы белән дә актив фикер алышабыз. Ләкин башта безгә көч җыярга, «Мирас» белән тәҗрибәбезне анализларга, «хаталар өстендә эшләргә», алга таба кая һәм ничек хәрәкәт итәргә икәнен аңларга кирәк.

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

Бу санда тәкъдим итәбез:

Рәшит Кәлимуллинның коллекциясендә **ничә** уен коралы бар

Ни өчен без һәр елны «Крутушка»га барабыз

Китап белән алма бәлеше арасында **нинди** уртаклык бар

Күршең үзеңнән начар булганда **нишләргә**

«КЕШЕ ГЕЛ ҮСЕШТӘ БУЛЫРГА ТИЕШ!»

Руфия Фазылова

Бүгенге кунагыбыз зыялы, затлы. Аны Татарстанда гына түгел, Россиядә, дөнья күләмендә дә таныйлар. «Европа – Азия», Muz-Transit кебек халыкара фестивальләргә нигез салучы, дәрәҗәле халыкара конкурсларның жюри әгъзасы, Россия композиторлар берлеге советы әгъзасы... Бу исемлекне тагын дәвам итеп булыр иде. Ә безнең өчен ул – төрки-татар музыкасын дөнья аренасына алып чыккан талантлы композитор. Сүзебез – Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Рәшит Кәлимуллин турында.

– Рәшит Фәһимович, гадәттә без кунаклар белән сөйләшүне аларның бала чакларыннан башлыйбыз. Сез – Яшел Үзәндә туган бала. Шәһәр зур түгел. Иҗатка мәхәббәт ничек башланды? Кем, ә бәлки, нәрсә сәбәпче булды?

– Беренче карашка, Яшел Үзән әллә ни зур шәһәр дә кебек түгел, әмма балаларга иҗат белән шөгыльләнү өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Хәтта без үскәндә дә шулай иде. Миңа калса, Яшел Үзәннең ниндидер бер көчле энергетикасы бар, чөнки анда зур дәрәҗәләргә ирешкән сәләтле кешеләр байтак.

Иҗатка мәхәббәт ничек башланды дигәндә, башлангычта укыганда, үзем теләп, Пионерлар йортына бардым. Анда курчак театры түгәрәге бар иде, берничә ел шунда йөрдем. Тагын әле музыка түгәрәгенә язылдым. Һич онытмыйм: курчак театры түгәрәгеннән чыгам да музыка мәктәбе ягына китәм. (Алар икесе да Пионерлар йортында урнашкан иде.) Һәм шул якта яңгыраган музыка уен кораллары тавышын тыңлап торам. Берсендә укытучы чыкты да: «Син гел шушы ишек тө-

Фото: Александр Ефремов, Рәшит Кәлимуллин архивыннан

Кларнетистлар ансамбле белән. Перу.

бендә торасың, берәр уен коралында уйнап карыйсың килмиме? Теләсәң, сине музыка мәктәбенә укырга алабыз», – диде. Менә шулай итеп, һич уйламаган җирдән музыка дөньясына кереп киттем. Укытучы киңәше белән уен коралы итеп кларнетны сайладым. Армиягә киткәч тә, хәрби оркестрда хезмәт иттем, кларнетта уйнадым. Кыскасы, музыка мәктәбендә укуымның ярдәме тиде. Алай гына да түгел, шул башлангыч алга таба Казан дәүләт консерваториясендә белем алырга, аннан соң аспирантура тәмамларга да этәргеч булды.

– Чынлап та, сез Казан дәүләт консерваториясен тәмамлагансыз. Әле биредә дистә елдан артык укыткансыз да. Ни өчен мөгаллимлек эшен ташладыгыз?

– Мөгаллимлек эшен бик яратып башкардым. Кафедра мөдире дә булдым, әмма консерваториядәге эшем бик күп вакытны алды. Иҗатка вакыт калсын өчен, мөгаллимлек эшен ташларга туры килде.

– Рәшит Фәһимович, сездә музыка уен кораллары коллекциясе барлыгын беләбез. Бүгенге көндә тупланмагызда ничә уен коралы санала? Шуның иң үзенчәлеклесе нинди?

– Бу инде икенче коллекциям. Беренчесен «Татнефть» оешмасы сатып алды, ул бүген Әлмәт күргәзмәләр залының иң затлы экспонатлар тупланмасы булып тора. Анда дөнья халыкларының 624 уен коралы бар. Аны 35 ел җыйган идем. Шуннан соң икенче коллекциямне тупладым: бүгенге көндә миндә 1500 гә якын музыка уен коралы бар. Алар барысы да кабатланмас һәм минем өчен кадерле. Аларга бик сак карыйм: һава дымлылыгын даими тикшерәм, кулга алып тотып карыйм, хәтта сөйләшәм дә. Музыка уен кораллары минем өчен җанлы әйбер. Барысында булмаса да, күбесендә уйный да беләм. Бары тик кыллы уен кораллары гына авыррак бирелә, чөнки аның өчен бармаклар дөрес ятарга тиеш. Аның каравы, тынлы уен коралларында яхшы уйныйм.

Бу кызыксынуым мәктәп яшендә үк башланды: берәр уен коралы күрсәм, тотыптотып карый идем. Инде профессиональ композитор булгач, шундый уй туды – кул астында музыка уен кораллары булса, иҗат итәргә җиңелрәк булачак. Төрле спектакльләргә музыкалар язганда дип әйтүем. Аллаһы Тәгалә шушы уйларымны ишетте, ахры. Берсендә җырчы Ринат Ибраһимов өйгә килде. Без аның белән дуслар идек, аңа күп кенә җырлар яздым. Һәм шунда телевидениедән шалтыраттылар: Ибн Фадлан турында фильм төшерәләр, көй язарга сорыйлар. Төркем Казахстанга бара икән, ә минем аларга иярергә вакытым юк. «Эх, думбра да юк кул астында. Әле шуңарда уйнап, көй язып караган булыр иде», – дидем Ринатка. Ә ул: «Миндә думбра бар, мин сиңа аны бүләк итәм, барыбер тик ята!» – диде. Менә шуннан башланды инде... Дөньяның кайсы гына почмагына барсам да, берәр музыка уен коралы карыйм. Һиндстанда, акчам җитмәгәч, фотоаппаратымны да биреп, үзенчәлекле музыка уен коралы алып кайттым. Кемдер чит илдән затлы кием карый, ә мин музыка уен коралы эзлим. Бүген минем машинам юк, гомумән, дөнья малын

Композитор Рәшит Кәлимуллин эш бүлмәсендә.

5 курс студенты Рәшит Кәлимуллин Казан консерваториясе ректоры Нәҗип Җиһанов (уртада) кабинетында. Янәшәдә – композитор Рафаэль Билалов. 1985 ел.

СӘНГАТЬ – ИҢ ЗУР БАЙЛЫК, УЛ ТАРИХТА КАЛА, УЛ КЕШЕЛӘРГӘ РУХИ АЗЫК БИРӘ, АНЫҢ КҮҢЕЛЕН, ҖАНЫН БАЕТА.

беркайчан беренче урынга куймадым, ә шәп коллекциям бар.

Аллаһы Тәгаләгә мин бик рәхмәтле, әллә нинди затлы, үзенчәлекле уен коралларын юлыма чыгарып тора.

– Сез утыз биш ел буе Татарстан композиторлар берлегенә җитәкләдегез. Бүген инде анда кунак буларак киләсезме? Әллә инде әле һаман хуҗаларча йөрисезме?

– Кадерле кунак буларак киләмдер. Заманында Мирсәет абый Яруллин мине үз урынына калдырды. Бүгенгедәй истә: фатирның ишеген шакыйлар, мин кулымны сындырып, өйдә утыра идем. Ачсам, Мирсәет Яруллин, укытучым Борис Трубин, композитор Алмаз Монасыйпов басып тора. Түргә уздылар. Шунда Мирсәет абый: «Энем, сиңа йомыш белән килдек. Союздан китәр вакыт җитте. Тиздән съездга җыелабыз, синең кандидатураңны күрсәтәбез килә», – диде. Дөресен генә әйткәндә, мондый тәкъдимне көтмәгән идем: дөнья буенча гастрольләрдә йөри башлаган, бик актив иҗат иткән чорым. Ә берлек җитәкчесе, иҗаттан тыш, күпме хуҗалык эшләрен хәл итәргә тиеш бит. Шулай да алар мине ул көнне күндерде. Нәтиҗәдә, сез әйткәнчә, берлекне 35 ел җитәкләргә туры килде. Хәтта озаккарак та сузылды. Вакытында китә белү бик кирәк. Бәлки, бу вазыйфадан иртәрәк тә баш тарткан булыр идем, лаеклы кеше калсын, дип теләдем. Татарстан композиторлар берлегенә бүген талантлы, бик өметле егет – Ильяс Камалов җитәкли. Союз ышанычлы кулларда дип, курыкмыйча әйтә алам.

Һәм үзем өчен дә оят түгел: эшләгәндә күпме композиторга торак проблемасын хәл итәргә булыштым, союз бинасына капиталь ремонт ясалды, Софья Гобәйдуллина исемендәге Заманча музыка үзәге ачылды һ.б. Республиканың һәр районында балалар алдында чыгышлар ясадым. Шул рәвешле яшь буынны татар композиторларының иҗаты белән таныштырдым.

Сәяхәт вакытында. Марокко.



– Сара Садыйкованы үләренә ике ел кала гына ТР Композиторлар берлегенә алганнар. Юкса СССР күләмендә танылган композитор, җырчы. Аны туры сүзле булган, дип сөйлиләр. Бәлки, сәбәп шундадыр...

– Дөресен генә әйткәндә, бу шактый четерекле сорау. Профессиональ композитор булу өчен кешеләр 25 ел укый. Ни кызганыч, Сара апаның белеме җитеп бетмәгән, ул Мәскәүдә бер еллык курсларда гына укыган. Сүз дә юк, ул бик талантлы, Аллаһы Тәгалә аңа зур сәләт биргән. Ләкин бу гына аз, профессиональ композитордан җитдирәк жанрлар да сорала... Мин аны яшьләргә дә, алай гына да түгел, инде композитор исеме йөрткән берничә кешегә дә әйттем: «Укырга кирәк, шунсыз үзешчән булып каласың». Бу очракта мин сатулашмыйм: кемгәдер үзешчән булып калу да җитә...

– Бүген саллы музыкаль әсәрләр языламы? Яшьләр арасында Рөстәм Яхин, Ренат Еникеевларга алмаш бармы? Ягъни татар музыкасын дөнья дәрәҗәсенә чыгарырлык талантлар?

– Ренат Еникеевларны алыштырырга түгел, аларның эшен дәвам итәргә, үзеңнән яңалык кертергә кирәк.

Сәләтле яшь композиторлар бар. Шул ук Ильяс Камалов, Миләүшә Хәйруллина, Эльмир Низамов, Илдар Камалов һ.б. Илдар, Казан дәүләт консерваториясен тәмамлап, Чикагога укырга китте, кино музыкасы жанрында белем ала. Энем, син анда да, монда да эшлә, шулай уңышка күбрәк ирешәчәксең, дип киңәш бирдем. Тагын әле бүгенге өметле композиторлар арасыннан Эльмира Галимова, Алсу Абдуллинаны әйтер идем. Кыскасы, сәләтле, милли көйләр иҗат итүче композиторлар бар һәм мин моңа ихластан сөенәм. Алар – безнең таянычыбыз.

– Опера һәм балет театры, Дәүләт симфоник оркестры репертуары миллилек белән аерылып тормый. Сез минем белән килешәсезме? Бу нидән шулай? Лаеклы әсәрләр иҗат ителмиме?

– Бу сорауны шушы өлкә өчен җаваплы кешеләрдән сорарга кирәк. Шуны гына әйтәм: Дәүләт симфоник оркестры чит илгә бара икән, ул милли көйне сәхнәгә алып чыгарга тиеш, чөнки алар шушы республика хисабына яши.

Советлар Союзында бик дөрес сәясәт бар иде – һәр республикада иҗат базалары төзеделәр. Шул рәвешле, һәр милләтнең сәнгатен, әдәбиятын үстерү юнәлешендә эшләделәр. Татарстаннан гына да күпме кеше, Мәскәүгә барып, махсус курсларда белем алды. Нәтиҗәдә, ул артистлар аннан соң зур танылу алды, иҗатлары гөрләп барды. Ни кызганыч, хәзер мондый иҗат базалары юк дәрәҗәсендә.

– ТР Язучылар берлегендә бүген 301 кеше исәпләнә. Композиторлар берлегендә алтмышлап кына кеше, дип беләм. Бездә музыка сәнгате алай киң җәелмәгәнме, әллә композиторлар берлегенә җиде кат иләк аша иләнеп узалармы?

– Ул яктан миңа бәхет елмайды: армиядә бик акыллы егетләр белән хезмәт иттем. Француз әдәбиятын французча укыйлар иде. Безнең анда шундый шәп китапханә бар иде, Ремарк, Драйзер, дөнья әдәбиятының башка классиклары белән шунда таныштым. Хәрби оркестрдагы коллегаларым минем нәрсә укуымны күзәтеп, киңәшләрен биреп торды.

Музыка өлкәсендә үзеңне даими үстереп тору бик мөһим, чөнки бу һөнәр сине әле ашатырга да тиеш. ТР Композиторлар берлегенә эләгү бер дә җиңел түгел. Өч көй язып кына анда эләгә алмыйсың. Беренче чиратта, син профессионал булырга тиеш. Ә менә ТР Язучылар берлегенә, мәсәлән, төзелештә эшләп йөргән кешене дә кабул итәләр дип беләм, чөнки аның китаплары чыкты, диләр. Ә бүген китап чыгару модага керде.

– Бер кыз, бер ул үстердем.

– Сез күбрәк Мәскәүдә яшисезме? Балалар, оныклар белән еш аралашасызмы?

– Мәскәү белән ике арада йөрим. Җаен туган якта күбрәк булам. Кызым гаиләсе белән Төркиядә яши. Заманында музыка мәктәбен тәмамлады. Әмма сәнгать юлыннан китмәде, югыйсә сәләте дә бар иде. Әмма ул: «Әти, мин үз юлымнан китәм», – диде. Мин каршы килмәдем. Башта КФУны бетерде, аннан Америкага барып, укып кайтты. Инглиз, немец телләрен камил белә, хәзер инде төрекчә дә өйрәнде. Кырык биш яшендә икенче тапкыр әни булды.

Улымның да ике баласы бар, җәмәгате белән бер ул, бер кыз үстерә. Берьюлы музыка мәктәбендә дә, сәнгать мәктәбендә дә белем алды. Ләкин, ике арада йөри торгач, сәнгать мәктәбен генә калдырды. Аннан соң Казан дәүләт төзелеш институтын тәмамлады. Бүген шул юнәлештә эшли.

Балалар үсеп беткәч, икенче тапкыр өйләндем. Җәмәгатем Ләйлә – бүген уң кулым. Минем гастрольләр графигын төзи, концертлар оештырганда ярдәм итә. Ландшафт дизайнеры булып эшләде, шул юнәлеш буенча Венгрия, Англиядә белем алды. Хәзер инде лаеклы ялда.

КЕШЕ ГЕЛ ҮСЕШТӘ БУЛЫРГА ТИЕШ! МИН ҮЗ БАЛАЛАРЫМА ДА ГЕЛ ӘЙТЕП КИЛДЕМ: БЕРЕНЧЕ ҮК БУЛМАСАГЫЗ ДА, АЛДЫНГЫЛАР РӘТЕНДӘ ЙӨРЕРГӘ ТЫРЫШЫГЫЗ.

– Җәмәгатем Ләйлә – бүген уң кулым. Минем гастрольләр графигын төзи, концертлар оештырганда ярдәм итә.

– Рәшит Фәһимович, әгәр тормышны яңадан башларга дисәләр, нәрсәләр үзгәртер идегез?

– Беренчедән, вакытның кадерен күбрәк белер идем. Халкым өчен тагын да юмартрак булыр идем. Шөкер, беркайчан начар яшәмәдем, дөнья гиздем. Әле дә – гел гастрольләрдә. Төрле халыклар өчен музыка язам, бу да – бәхет. Латин Америкасы илләре, Австралия, Вьетнам һ.б. өчен музыка язам. Кавказ республикалары, Тыва, Якутия белә тыгыз элемтәдә. Аеруча төрки телле халыклар белән дуслык зур, алар мине ярата.

Үземне юмарт кеше дип саныйм: күп кенә дус, танышларга әле дә ярдәм итеп торам. Шул исәптән, матди яктан да. Шул ук остазларым белән дә элек булган элемтәләрне югалтмаска, кайчандыр миңа ярдәм иткән кешеләргә рәхмәтле булырга тырышам.

КОЕП ЯҢГЫР ЯУСА ДА...

Евгения Чеснокова

Сәхнәдә халык музыкасы яңгырый. Рус җырларын – балкан, ә аннары әрмән көйләре алыштыра. Өстән коеп яңгыр ява, әмма сәхнә – каплаулы. Сәхнә алдындагы тамашачы исә – кечесеннән алып олысына кадәр – я зонт астында, я яңгырдан саклый торган ябынчага төренеп, электрон фольклор ритмнарына ияреп, рәхәтләнеп бии.

Август азагына якынлаша, җәй бетеп килә, көзге яңгыр сибәли. Болар барысы да «Крутушка» этник музыка фестивале килеп җиткәнлеген раслый. Аның ямен берни боза алмый: кояш булса да шат аның тамашачылары, яңгыр да аларга беркайчан да комачауламый.

ҮЗЕБЕЗЧӘ: ЧЫН, ҖЫЛЫ, ИХЛАС...

Дөресен генә әйткәндә, үземне фольклор музыкасының һәм этник традицияләрнең зур фанаты дип атый алмыйм. Мин заманча шәһәр мәдәнияте кешесе, музыкадан да бард аккордлары белән рок якынрак. Тик мин ел саен «Крутушка»га барам һәм анда үземне бәхетле хис итәм. Һавасында нәрсәдер бармы соң – җылылык, ихласлылык... Хәзер яшьләрдә шундый модалы сүз дә йөри – лампалы!

Фестивальдә ирле-хатынлы иске дусларымны танып алам. Тукта, без монда алар әле өйләнешкәнче үк очраша башлаган идек түгелме? Аннары алар монда яңа туган балалары белән килгән иде. Беренче мәртәбә фестивальгә алып килгәндә, кызларына әле бер ай да булмагандыр... Хәзер инде алар да – яшүсмерләр, ел саен әти-әниләре белән

Автор фотолары

«КРУТУШКА» – ХАЛЫКАРА ЭТНИК ФЕСТИВАЛЬ, УЛ ЕЛ САЕН (СИРӘК ИСКӘРМӘЛӘРДӘН ТЫШ) АВГУСТ АХЫРЫНДА, АНЫҢ ДА СОҢГЫ ЯЛ КӨННӘРЕНДӘ КАЗАН ЯНЫНДАГЫ ШУЛ УК ИСЕМДӘГЕ БИСТӘДӘ, «БАЙТИК» ЛАГЕРЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ УЗА. БЫЕЛ УНБИШЕНЧЕ МӘРТӘБӘ ҮТКӘРЕЛДЕ. БИРЕДӘ ТӨРЛЕ МИЛЛӘТ ҺӘМ ХАЛЫК КӨЙЛӘРЕ ГЕНӘ ЯҢГЫРАМЫЙ, **АЛАРНЫҢ БИЮЛӘРЕ ДӘ БАШКАРЫЛА, ҺӨНӘРЧЕЛЕК ЭШЛӘНМӘЛӘРЕ, РИЗЫКЛАРЫ ДА ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ...**

«Крутушка»га киләләр. Серле тарту көче бар бу урынның...

Халык монда илебезнең төрле төбәкләреннән агыла. Палаткалар белән Кировтан, Уфадан, Йошкар-Оладан, Уралдан һәм Себердән киләләр. «Байтик»ка якын аланда яшиләр. Көндез «фестиваль» шаукымы булса, кичләрен учак ягалар һәм үзләре дә җырлыйлар – гитара, гармун, варган һәм тамтам көйләренә. Еш кына – коеп яуган яңгыр астында. Чөнки җырлар, һава торышына түгел, күңел халәтенә бәйле.

СЕЗ ЛОХИКЕЙТТО ЯРАТАСЫЗМЫ?

Минем өчен, сүз уңаеннан, соңгы вакытта «Крутушка» музыкадан түгел, ә ярминкәдән һәм гастрономик тәҗрибәләрдән башлана. Ярминкәдә нәрсә генә юк: фолк стилендәге кием-салым да, төрле илләрдән килгән традицион уенчыклар белән бизәнү әйберләре дә, ә гадәти булмаган музыка коралларын әйткән дә юк... Варганнар, тамтамнар һәм җырлаучы касәләр музыкаль программада катнашучылар арасында – чын мәгънәсендә сату хиты.

Гастрономиягә килгәндә, беренче елларда фестивальдә кулинар программа булмады.

Ләкин акрынлап төрле халыкларның кухнясы буенча мастер-класслар фестивальнең даими һәм мөһим өлешенә әверелде. «Крутушка»-да инде шактыйдан Мәскәү һәм Петербург шәһәрләренең шеф-повармары Сергей Рахманин белән Михаил Гаврилов халыкны шаккатыра. Аларның рус миче янындагы чын артистларча перформансларына (мичне «Байтик» территориясендә фестиваль өчен махсус төзегәннәр) һәрвакыт бик күп тамашачы җыела.

– Бу – сезнең чын мәгънәсендә көч урыныгыз! – дип, үз тәэсирләре белән уртаклаша Сергей Рахманин. – Кешеләр мастер-класска һәрвакыт янып торган күзләр белән килә, мавыгып катнаша, сораулар бирә. Аларга барысы да кызык.

Бу юлы осталар безне Карелия кухнясы нечкәлекләре белән таныштырды. Мин, дөресен генә әйткәндә, әллә ни оста кулинар түгел, ләкин форельдән лохикейтто – Карелиянең каймак каткан ухасын әзерләү серләре турында рәхәтләнеп тыңладым. Кара һәм ак борыч бербересеннән ничек аерыла, майлы ашка сохари салу ни өчен попса, ухадагы форель нишләп ярымпешкән булырга тиеш... Мастер-класстагы иң күңелле мизгел – ул, әлбәттә, ахырда әзер ризыкны татып карау. Халык йөз кешеләп булса да, пешекчеләр, нинди дер бер хәйлә табып, уханы һәркемгә җиткерде. «Кыздырган йомырка һәм ботка тутырылган корбан балыгына» да бик каласы килгән иде дә, ләкин әле ярминкәдә дә йөрисе бар. Төп сәхнәдәге музыканы да тыңлыйсы. Шулай булгач, корбан балыгы бу юлы корбан булыр инде...

БИК ОЗЫН ҺӘМ БИК МАТУР

Иртәнге якта «Крутушка»да гадәттә – төрле лекцияләр һәм мастер-класслар, шул исәптән халык биюләре һәм инструментларда уйнау буенча да. Бирeдә рус балалайкасыннан алып, Иран ней-флейтасына кадәр бар. Музыкаль сәхнә якынча төшке аштан соң эшли башлый. Кичкә таба, мастер-класслар, уеннар һәм кулинария ивентлары тәмамлангач, фестиваль кунакларының күбесе шунда күчә.

«Крутушка» һәрвакыт милли яктан «чуар» һәм интернациональ булды. Россиянең күптөрле этник коллективларыннан тыш (рус, татар, мари, мордва, бурят, башкорт һ.б.), үткән елларда бирегә Африка һәм Америка континентларыннан да җырчылар килде, фестивальнең берничә мәртәбә кунагы Австралиядә яшәүче татар кызы Зуля Камалова иде. Зуляны хәтерлибез һәм сагынабыз...

Быел бөтенләй ерактан ук килгән кунаклар азрак, шулай да тамашачылар әрмәннәрне дә, болгарларны да, иранлыларны да, хәтта Исландия кульнингларын да тыңлый алды. Кайчандыр ул җырлар белән Скандинавия кешеләре тауларда утлап йөрүче сыерларын өйгә чакырып кайтара торган булган. «Крутушка»да Исландия фольклорын көчле тавышлы һәм гадәти булмаган биографияле, үзе нәзакәтле-нәфис җырчы Анна Халлдорсдоттир тәкъдим итте. Анна хәзер Казанда яши икән, аның әнисе – яртылаш рус, яртылаш татар, ә менә әтисе Исландиядән булган. Бала чагында Анна ерак төньяк утрауда яшәгән, ул хәзер дә әтисенең туган телен яхшы белә һәм Исландия мәдәниятен бик ярата. Анна – профессиональ опера җырчысы, консерваторияне тәмамлаган. Әммa, ди ул, Исландия фольклоры җанына якынрак, ул – аның тормышының аерылгысыз өлеше.

– Скандинавия халык көйләре искиткеч матур һәм бик үзенчәлекле, – ди җырчы кызыбыз. Асылда, Анна башкаруындагы бу борынгы кульнинглар бер озын-озын җырдан гыйбарәт булган. Аннаның исландча фамилиясе, кайбер билгеле исланд географик атамалары кебек үк, бик озын һәм, чыннан да, гадәти түгел. Чыннан да бик матур!

Фестивальдә мин үзем өчен һәрвакыт берәр өр-яңа музыка уен коралрын ачам. Бу юлы, мәсәлән, Балтачның «Орчык» триосы гаҗәеп керәшен гөсләләрендә уйнады. Бик көчле, матур һәм бераз гына чатнап киткәндәй моңлы авазлар... Әйтерсең, алар гасырлар төпкеленнән килә...

ЙОЛДЫЗЛЫ ТАРИХ

Быел мине бернәрсә борчыды ук дип әйтеп булмый, билгеле, ләкин шактый гаҗәпләндерде. Фестивальнең соңгы көнендә сәхнә артындагы һәм алдындагы мәйданны аркан бау белән әйләндереп алдылар, бөтен җирдә сакчылар куйдылар... Сәбәбе – Ay Yola башкорт коллективының чыгышы.

Уфаның әлеге фольклор триосы быел кинәт кенә тик-ток трендлары сафына килеп керде дә Shazam сервисының дөньякүләм топ-лидерлары исемлегендә урнашты. «Урал-батыр» башкорт эпосына нигезләнгән «Һомай» җыры (һәм аңа төшерелгән клип) сәбәпче булды аларның популярлыгына. Бу илаһи кош һәм кыз тарихын халык шунда ук яратты.

Мин профессиональ музыка тәнкыйтьчесе түгел, ә гади тыңлаучы гына, әмма җырны күбрәк электрон фолк-рок жанрына кертеп карар идем. Ул, чыннан да, җәлеп итә, хәзерге яшьләр теле белән әйтсәк, «качовый» җыр. Аны башкаручылар күз ачып йомганчы йолдыз булды, мондый тарихлар сәнгатьтә була торган хәл. Чыгышлары да йолдызлы антураж белән уратып алынган иде. Сәхнәгә терәлеп диярлек торган палаткага кадәр джип китерде үзләрен. Чыгыш ясау белән, музыкантлар шунда ук кире палаткага кереп югалды. Аннан инде, машинага утырып, матбугат вәкилләре белән дә аралашмыйча, көтеп зар-интизар булган җанатарларга автограф та өләшмичә, фотога да төшмичә, китеп бардылар. Оештыручылар кулларын гына җәйде: нишлисең, райдерлары шундый...

«Крутушка» өчен бу гадәти күренеш түгел. Фестиваль һәрвакытта да гадәттән тыш демократик булуы белән аерылып торды. Музыкантлар гадәттә шушында ук, «Байтик» территориясендә яши, лагерь буйлап ял итеп йөри, тыңлаучылары белән бик теләп, рәхәтләнеп аралаша, уратып алган җанатарлары белән фотога төшә. Фолк-башкаручылар гадәттә поп- һәм рок-коллегалары дәрәҗәсендә «йолдыз» булмауга бәйледер бу, бәлки. Сәхнә алдындагы киртәләргә карап, хәтта аккредита-

цияләнгән фотографларны да кертергә теләмәүләрен күзәтеп торып, шуны уйладым: бәлки, ул кадәр «йолдыз» булмаулары яхшыдыр да. Җир йөзендә якын барып булмый торган йолдызлар күп ул, әмма бит «Крутушка» – икенче... Монда килгәндә, «йолдыз»ларга да шуны истә тотарга кирәктер, мөгаен...

Ярар, яңа гына күккә очып менгән «йолдыз»ларга карата артык кырыс булмыйк, дип, туктаттым бу уйларны: иң мөһиме – алар үзләренең көчле энергияле перформансы белән тамашачыны «кыздырды», чыгышлары халык күңеленә бик хуш килде бит. Асылда, барысы да – сәхнә өчен, ә сәхнә артында ни булмас...

ТЕНДЕНЦИЯ, ӘММА...

Фольклорга тартылу – хәзерге заман тренды. Социологлар, төрле позицияләрдән карап, Надежда Кадышеваның берара бик үсеп киткән һәм хәзер яңадан әйләнеп кайткан популярлык феноменын, җир-ана һәм изге Русь турындагы җыры белән «топ» исемлекләргә күтәрелгән яшь йолдыз Татьяна Куртукованың уңышын аңларга, аңлатырга да тырышалар.

Кайбер тикшеренүчеләр фикеренчә, бу трендта үзенә күрә бер постиронияне дә шәйләргә мөмкин: янәсе, яшьләр моны җитди кабул итми, алар бары тик тик-ток өчен генә «уйныйлар»... Ә менә «Крутушка»ның даими катнашучысы, танылган Мәскәү фолк-музыканты, рус фольклорын җыючы һәм тикшерүче этнограф Сергей Старостин «Крутушка» сәхнәсе артындагы әңгәмәсендә шуны раслады: әйе, яшьләр арасында фолкны башкаручылар да, тыңлаучылар да күзгә күренеп артты. Старостин моның сәбәбен үз тамырларыбызга кайтырга омтылуда, кем икәнебезне һәм кайдан икәнебезне аңларга теләүдә күрә. Евгений Багринцев – фестивальнең тагын бер катнашучысы, тумышы белән Омскидан булган артист. Ул рус халык җырларын башкара. Багринцев халык җырлары белән халыкчан трендны киңрәк күзаллап аңларга кирәк дип исәпли:

– 80-90 нчы елларда, безгә кинәт кенә Көнбатыш мәдәнияте ачылгач, барысы да бу яңа, мавыктыргыч, әмма аңлаешсыз юнәлеш белән кызыксынып китте, – ди ул. – Әйе, ул елларда Көнбатыштагы тормыш дәрәҗәсе мондагыдан күпкә югарырак иде. Бездә дә тормыш дәрәҗәсе үскәч, кешеләр тирәнрәк әйберләр, шул исәптән үз мәдәниятләре белән дә кызыксына башлады. Өстәвенә, әгәр элегрәк мәдәни мода чыгаручылар булып Мәскәү һәм Петербург саналса, бүген инде башкаладан ераграк урнашкан төбәкләрдән килгән уңышлы кешеләр дә җитәрлек. Алар, ике башкалада да үзләренең уникальлеген раслап, рәхәтләнеп яши һәм эшли. Кешеләр үзләренең провинциаль чыгышыннан уңайсызланмый башлады. Димәк ки, тамырларын белүдән, алар белән горурланудан да оялмый.

Евгений, сүз уңаеннан, хатыны Екатерина белән дуэтта чыгыш ясый, сәхнәгә алар белән өч яшьлек кызлары Есения дә чыга (әлегә җырламый, әмма инде сәхнәне тояргa өйрәнә). Сәхнә артында коляскада Фёдор көтә, аңа әле бер яшь тә юк. Һәм бу, сүз уңаеннан, мәдәни феноменның тагын бер шәрехләмәсе: фестивальдә без сөйләшкән күп кенә яшь фолк-башкаручылар халык иҗатына мәхәббәтне әнә шулай әниләре, әтиләре, бабалары, әбиләре аша сеңдергән... Дөресен генә әйткәндә, без моны «Крутушка»да үзебез үк аерымачык күрәбез: ул, чын мәгънәсендә, гаилә фестивале.

Аңлашыла, якынча биш меңлек аудиториясе белән «Крутушка» киң, массалы аудиторияле рок-фестивальләрне уздыра алмый. Әмма ул аңа омтылмый да. Ул башка төрлерәк тенденцияне билгели. Яшьләргә янә фольклор кызыклы була башлады, һәм бу гаиләдән дә килә. Киң колачлык һәм саннар мәсьәләсенә килгәндә, фестивальне оештыручылар аудиторияне артык киңәйтергә омтылмауларын үзләре дә таный. Мин алар белән килешәм. Кеше күбрәк булган саен, теге, иң башта әйткән җылылык, үзара якынлык тойгысы юкка чыга төшә, «Крутушка»ның яме дә, ихласлыгы да кими...

Медовая Поляна

редакция кухнясы

ВЕНЕРА ШӘМСЕТДИНОВАДАН «КИТАПЛЫ» АЛМА БӘЛЕШЕ

Татьяна Вафина

Җәй ахыры – кызарып пешкән алмалары, ә «Татарстан» журналының редакция кухнясы шул алмалардан пешерелгән бәлеше белән матур. Бүген аны «Миссис Татарстан – 2025» VI Республика гүзәллек һәм уңышка ирешкән хатын-кызлар конкурсында «Татарстанның II вице-миссисы» титулына ия сөйкемле һәм мөлаем ханым – Венера Шәмсетдинова пешерә.

Венера – Татарстан китап нәшриятының массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү буенча баш мөхәррир урынбасары, димәк, гүзәл ханым гына түгел, акыллы ханым да. Хәер, кайсы татар хатын-кызын алма, барысы да шундый. Сүз «чабып барган атны туктату, янгын чыккан өйгә керү» турында түгел, ә без яшәгән цифрлы заманда онытыла башлаган, дөнья көткәндә, хатын-кыз белергә тиешле гап-гади күнекмәләр турында әйтүебез.

ТӘМЛЕ «КИТАПЧЫК»

– Конкурсның финалына бер атна кала әзерлек бик каты барды, – дип исенә төшерә Венера. – Безгә, өлгереп җиткән алмаларны һәм грушаларны бик оста итеп телемнәргә турап, жюри алдында иҗади сәләтебезне дә, аш-суга осталыгыбызны да күрсәтергә кирәк иде. Шул ук вакытта интеллектуаль сынауны да үтәргә тиешбез.

– Кеше алдында ашарга әзерләү ничегрәк соң?

– Дулкынландырды, әлбәттә, – ди вице-миссис, – әмма мин ашарга пешерергә яратам, шуңа да тәмле килеп чыкты. Жюри өчен конкурсның символы булган лаләләр рәвешендә мантый пешердем. Ә баллы ризыкка китаплар рәвешендә печеньелар әзерләдем. Һәр печеньены кулдан глазурь белән бизә-

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛА:

- Алма һәм грушалар – 4 данә;
- Карабодай оны – 0,5 стакан;
- Бодай оны – 0,5 стакан;
- Йомырка – 4 данә;
- Бал – 2 аш кашыгы;
- Шикәр – 0,75 стакан;
- Атланмай – 150 г.

Фото: Ната Смирнова

– Ә баллы ризыкка китаплар рәвешендә печеньелар әзерләдем.

– Китап чыгару өчен башта «продуктларын» – текстын, рәсемнәрен җыялар, редактура, корректурасын эшлиләр.

дем: рус һәм татар хәрефләре төшердем. «Китапчык» идеясе гаиләмдә туды, һәр детальне бергәләп эшләдек: кайсыбыз камыр басып җәйде, кайсыбыз бизәде. Печеньеларны гаилә белән пешерү бу сынауга җылылык өстәде. Шуңа да финал концертында мин үземнең чыгышымны күптән түгел генә алтын туйларын билгеләгән әтием белән әниемә багышладым.

Аш-су ярышындагы соңгы аккорд мин алдагы көнне генә җыеп алган бөтнек гөлләмәләреннән булды. Конкурста катнашучы һәркемгә һәм жюри әгъзаларына шундый хуш исле бүләк ясадым...

«КИТАПЛЫ» СӘЯХӘТЛӘР

– «Лаләләр» һәм «китапчык»лардан тыш, тамашачыларны тагын нәрсә белән шаккатырдыгыз?

– Минем өчен социаль проектларны яклау көне әһәмиятле булды, – Венера камыр эшенә тотына. – Ул миңа күңелемдә күптән йөргән проблемалар турында сөйләргә һәм аларны хәл итү өчен тәгаен юллар тәкъдим итү мөмкинлеге бирде. Мин берьюлы ике проект тәкъдим иттем, алар китап дөньясының чикләрен киңәйтүгә юнәлтелгән иде. Беренче проект – күзләре начар күрә торган балалар



өчен 3D-китаплар. Андый китаплар бәләкәй укучыларга иллюстрацияләрне тотып карап өйрәнү мөмкинлеге бирә, шул рәвешле алар кызыклы әдәби әсәрләр белән таныша алачак. Икенче проект Казанда уңышлы гына гамәлгә ашырылган иде – «Әдәби автобус». Аны Татарстанның зур шәһәрләрендә дә эшләп булыр иде.

– Проектның асылы нәрсәдә?

– Җәмәгать транспортында пассажирлар танылган язучылар һәм шагыйрьләр белән очраша, алар автобус салонында үзләренең әсәрләреннән өзекләр укый, – дип бүлешә Венера. – Автобус үзенә күрә күчмә күргәзмә-китапханәгә әйләнә, анда шигырьләр һәм хикәяләр тыңларга, күргәзмә итеп куелган китаплар белән танышырга һәм кызыклы кешеләр белән аралашырга була. Бу проект китап укуга мәхәббәтне үстерүгә һәм автобусларда көн саен уза торган вакытны әдәбият дөньясына маҗаралы сәяхәткә әйләндерүгә юнәлтелгән.

КИТАП МОДАДАН ТӨШЕП КАЛА АЛМЫЙ

– Китапларга мондый мәхәббәт каян? Ул хәтта пешергән ризыкларыгызда да бар. Бөтен яктан китап уку модада түгел дип тәкрарлыйлар...

– Бала чактан, бәләкәйдән үк әти-әнием китап яратырга өйрәтте. Үземне белә-белгәннән бирле укыйм, хәтта юрган астында фонарь яндырып укыган да булды (совет балачагы

– Минем дә алма бәлешенең үзенә генә хас тәме бар, чөнки мин барысына да таныш шарлотканы традицион булмаган рецепт буенча пешерәм.

классикасы. – **Авт.**). Китаплар модадан төшеп кала алмый, дип саныйм. Алар һәрвакытта да трендта, чөнки укымыйча, надан кеше белән аралашуга караганда, укыган, акыллы кеше белән аралашу күпкә кызыклы.

СИМВОЛИК РИЗЫК

– Сезнең бүгенге алма бәлеше дә әдәбият дөньясыннанмы? Соңгы вакытта «китаплы рецептлар» популяр булып китте: Джоан Харриснең «шоколады», мәсәлән, Рэй Брэдбериның «тузганаклардан шәраб»ы...

– Бу күбрәк символик мәгънәгә ия ризыктыр, – ди Венера. – Һәрбер китапта автор нияте була, язучы еш кына илһамны үзенең тормышындагы вакыйгалардан яки әйләнә-тирәне күзәтүләреннән ала. Минем дә алма бәлешенең үзенә генә хас тәме бар, чөнки мин барысына да таныш шарлотканы традицион булмаган рецепт буенча пешерәм.

– Әйе, груша, бал һәм карабодай оны күзгә чалынды шул...

– Аны пешерү өчен йомырка, он, алма, груша бал, шикәр һәм атланмай кирәк була. Нәшрияттагы кебек: китап чыгару өчен башта текст, рәсемнәр җыялар, редактура, корректура аша уза.

АЛМАЛЫ ИДЕЯЛӘР

Өстәвенә, минем рецептның кайбер ингредиентлары китап чыгару эшенең мөһим элементлары белән турыдан-туры бәйле. Мәсәлән, алмалар. Мин иң тәмле, тәмам өлгереп җиткән алмалар сайлап алырга тырышам. Быелгы уңышлы елда бу алай ук җиңел түгел. Болай сайлау яңа идеяләр, кызыклы темалар сайлап алуга тиң, алар да бит китапның эчтәлеген бай һәм кызыклы итә.

АВТОР ИЛҺАМЫНЫҢ ИНДИВИДУАЛЬ ТӘМЕ

Алга таба – бал. Ул татлы тәм генә биреп калмый, ул – хуш ис чыганагы да. Гап-гади ризыкка да үзенә бер тәм бирә торган бал кебек, илһам да гап-гади текстны онытылмаслык гүзәл әсәргә әйләндерә ала.

СТАНДАРТКА ТУРЫ КИЛМӘГӘН КАРАБОДАЙ

Үз эшендә нәшир һәрвакыт яңа вариантлар эзли, төрле иллюстрацияләр куллана, тышлыгын сайлый, интерактив ярдәмендә яңа форматлар уйлап таба – гомумән, китапны үзенчәлекле итәргә тели. Рецептымда да мин, стандартлардан тайпылып, алма бәлешемне үзенчәлекле итә торган ингредиент – карабодай оны кулланам. Ул шар-

1 Җылытабыз

2 Салабыз

3 Сибәбез

4 Эретәбез, суытабыз

5 Ватабыз

7 Кушабыз

8 Өстибез

9 Турыйбыз

10 Салабыз

11 Агызабыз

лоткага чикләвек тәме бирә. Сүз уңаеннан, бу он ризыкның калориялелеген дә киметә, файдалы матдәләр белән баета, чөнки аның составында В төркеме витаминнары, тимер, магний бар.

ДИЗАЙНЕРЛАРЧА МАЙ ҺӘМ БАШКА ШУНДЫЙЛАР...

Шарлотка рецептындагы атланмай камырны мамык кебек йомшак итеп кабарта. Моны дизайнер һәм рәссам эше белән чагыштырып булыр иде. Алар бизәгән текст матуррак була, укырга уңайлы килеп чыга, китап үзенә җәлеп итеп тора.

Ингредиентларны игътибар белән, пөхтәләп болгатырга кирәк – нәшриятның командасы да һәрбер китапны нәкъ шулай бердәм итеп эшли, һәм нәкъ менә бу процесста катнашучыларның дусларча хезмәттәшлеге уңай нәтиҗә бирә.

Пешеп суынган шарлотканы Венера бизәп җибәрә – моны ул маркетинг стратегиясе белән чагыштыра:

– Матур итеп төрелгән булуы, бизәлеш, реклама китап белән кызыксынуны көчәйтә, – дип раслый бүген безнең аш-су остасы.

ЗАРЫГЫП КӨТҮ

Чәйнектә бөтнекле чәй пешә. Барыбыз да, зарыгып, алма бәлеше белән чәй көтәбез. Һәм, ниһаять, бүгенге көннең төп ризыгы табынга куела.

Карабодайлы-баллы-грушалы шарлотканың тәмен тел белән аңлатып бетереп булмый. Моның өчен шарлотканы пешерергә һәм ашарга, ашарга һәм пешерергә кирәк... Әмма белгеч булмаганнарның килеп чыгармы – менә бит эш нидә.

– Барыбызныкы да килеп чыга! – дип өметләндерә Венера. – Тиз дә, җиңел дә әзерләнә. Мондый тәмле әйбер белән чәй эчкәндә, китаплар да җиңел укыла. Тагын да яхшырагы – языла да.

– Нәрсә турында китап язар идегез?

– Кем турында! Мин язучы түгел, әмма минем шундый талантым булса, мин гүзәллек конкурсының җитәкчесе Изольда Генриевна Сахарова турында китап язар идем. Үз эшенең чын остасы! Миңа калса, эшкә илһам уята торган шәп китап килеп чыгар иде. Аның һәрбер катнашучының

6 Туглыйбыз

12 Пешерәбез

13 Алабыз

14 Сибәбез

– Китаплар модадан төшеп кала алмый, дип саныйм. Алар һәрвакытта да трендта, чөнки укымыйча, надан кеше белән аралашуга караганда, укыган, акыллы кеше белән аралашу күпкә кызыклырак.

– Программа тыгыз, кайчагында хәт-та катлаулы булса да, без катнашучылар бер-беребезгә терәк була алдык, бу бик рәхәт тойгы иде. Минем өчен әлеге дуслык һәм үзара ярдәмләшү атмосферасы җылылык һәм бердәмлек тойгысы бирде, без һәрвакыт бер-беребезгә ярдәм итеп тордык. Һичшиксез, минем җиңү – якыннарымның, дусларымның һәм хезмәттәшләремнең теләктәш булуының нәтиҗәсе. Аларның миңа ышанычы әзерләнергә һәм конкурс сынауларын уңышлы узарга көч бирде.

потенциалын ача белүе – китап язарлык – мин моны нәшрият хезмәткәре буларак әйтәм.

***

Ахырдан гына Татарстанның иң гүзәл һәм иң күп укыган вице-миссисы, «Тамашачы мәхәббәте» номинациясендә дә җиңү яулаган Венера Шәмсетдиновадан конкурс нәрсә белән истә калды дип сорыйбыз.

КҮРШЕҢ ҮЗЕҢНӘН НАЧАР БУЛСА...

Руфия Фазылова

Редакциягә Казанның Нокса авышлыгы урамыннан шалтыраттылар. «Күршебез аркасында подъездга керә торган түгел, зәһәр искә буылабыз. Алай гына булса иде, унитазы тизәк белән тулган, нәтиҗәдә, бөтен шакшы стена аркылы безгә агып керде...»
Ни аяныч, шәһәр җире өчен гадәти проблема бу. Өйдә песи, эт асраучылар, чүплектә казынып, шуннан капчык-капчык чүпрәк, башка әйбер ташучылар... Иң аянычы – алар белән көрәшү авыр. Шулай да, моны хәл итү юлы бар, ди, белгечләр.

ТЕРӘҮГӘ КАЛГАН ИШЕК...

Галия Хәерова Нокса авышлыгы урамындагы бер йортта егерме ел яши икән. Әлегә кадәр мондый проблемалар булмаган. Ә менә бер ел элек күршеләре өстән су бастырган. Дөрес, әллә ни зур зыян килмәгән, иң гаҗәбе – эзләп тә гаеплене таба алмаганнар. Бүлмәгә ремонт ясап, мондый хәл башка кабатланмасын, дип яши башлаганнар. Тик... җәен янә шул як стена каралып чыккан. Монысында инде Галия апа бөтен йортны аякка бастырган.

– Гаеп күрше подъезддагы берәүдә булып чыкты, – ди әңгәмәдәшем. – Без ул фатирга кердек һәм... телсез калдык. Баксаң, анда өлкән яшьтәге чирле ханым яши икән. Фатирындагы зәһәр искә чыдый торган түгел, ишеге бикләнми, җимерек урындык белән терәтеп куйган. Ә иң куркынычы – унитазы тизәк белән тулган. Безнең белән кергән сантехник укшып чыкты. Унитазында суы да юк, димәк, безгә шул бәдрәф шакшысы ага булып чыга...

Хуш, гаепле табылды. Инде проблема хәл ителергә тиеш бит. Бу чирле ханым ялгызы яши булып чыкты. Фатирның яртысы тагын бер милекчегә язылган. Тик бу туган тиешле кеше үз фатирының нинди хәлгә килүен «күрми».

Фото: Александр Ефремов

– Идарәче оешма вәкиле килеп, акт төзеп китте, – дип дәвам итте Галия Хәерова. – Тик монда проблеманы тамырдан хәл итәргә кирәк: бу чирле ханым шундый шартларда яши алмый бит. Закон буенча, опекага алган кеше чирле туганы өчен җаваплы. Менә хәзер шушы закон эшләсен дип йөрим. Полициягә, Совет районы администрациясенең опека бүлегенә, Совет районы социаль яклау бүлегенә рәсми хат яздым. Җавап көтәм. Ләкин сөйләшүләргә карагандa, әлегә берсенең дә бу эшкә җаваплылык аласы килми. Опека бүлеге, ул бездә исәптә тормый, ди. Социаль яклау бүлегендә, социаль хезмәткәр билгели алабыз, әгәр кеше үзе риза булса, диләр. Бу хезмәт тә түләүле икән. Авыру кешенең түләүле хезмәткә риза булуы, әлбәттә, шикле. Иң гаҗәбе – күршеләре хәлне күптән белгән, чөнки подъездга керә торган түгел, сасы. Ләкин бер генә инстанциягә дә хәбәр итмәгәннәр. Хәзерге вакытта төрле оешмаларга коллектив хатлар да юлланды.

Язмабыз басмага әзерләнгәндә, хәбәр килде: ханым хастаханәгә урнаштырылган, икенче милек хуҗасы табылган. Ул, килеп, фатирны чистартуга керешкән. Бу очракта әлеге йортта яшәүчеләр өчен шатландык һәм тагын бер кат көчнең бердәмлектә булуына инандык.

СЕВЕРНЫЙ БИСТӘСЕНЕҢ «ПЛЮШКИНЫ»?!

Николай Гоголь үзенең атаклы «Мёртвые души» поэмасын язганга ике йөз елга якын вакыт узган. Ә аның герое Плюшкин кебекләр һаман да бар. Хәтта арттырып та җибәрәләр. Гоголь абыебыз Казанның Северный бистәсендә яшәүче Вадим Матвеевны күрсә, өнсез калыр иде, мөгаен. Һәрхәлдә, без башта үз күзләребезгә үзебез ышанмый тордык. XXI гасырда адәм баласы болай яши ала дип күз алдына да китерүе авыр!

Вадим Алексеевичның кечкенә агач йорты чүп астында калган (!). Нәтиҗәдә, бүген ул капка төбендә торган иске «тугызлы» машинасында яши. (Сүз уңаеннан, аның алты җиңел машинасы тора, берсе дә йөри торган түгел.) Яши, дип, шунда кереп төн куна. Үзе әйтүенчә, утырып йоклый. 71 яшендәге бабай әлеге нигездә 1977 елдан бирле гомер итә. Кайчандыр хатыны, балалары булган. Тик аларның монда соңгы ун ел эчендә аяк та басканнары юк икән.

Без килгәндә, Вадим Алексеевич капка төбендә юк иде. Соңрак ачыкланды – Жилплощадка бистәсендәге «Кеше приюты»на, кайнар ризык алырга киткән. Аның каравы, күршеләре белән иркенләп сөйләшергә җай булды.

Эдуард З. – бабайның терәлеп торган күршесе. Аптырагач, ике арага өч метр биеклектәге таш койма салып куйган.

– Янгын чыкса, бөтен ихаталарыбыз көлгә әйләнә бит, – диде Эдуард. – Өстәвенә, безнең монда йортлар да бер-берсенә якын урнашкан: барыбызда да дүрт сутый ярым җир.

– Мондый мәхшәрдә күптән яшисезме? – дим.

– Ун-унбиш еллап буладыр инде. Северный бистәсенә унҗиде ел элек килеп урнаштык. Ул чагында Вадим Алексеевичның чүбе капкасыннан чыкмый иде әле. Ә хәзер йөри торган түгел.

Ул да түгел, каршы якта яшәүче Римма К. чыкты. Ул да тәртипсез күршесеннән тәмам гаҗиз булган. Зур-зур күселәр ишегалдында йөри икән.

– Бу тормыш түгел, – диде Римма ханым. – Бер кеше аркасында, ким дигәндә, алты-җиде гаилә тилмерә. Әле ярый этләре үлеп бетте, капка төбенә чыгарга куркыныч иде. Бабайның хәзер бер генә эте калды.

Күршеләр, җыелышып, быел июнь аенда бабайның капка төбен чистарткан, чүп өеме юлга кадәр чыккан булган. Эдуард экскаваторы белән утыздан чүмечтән артык чүп чыгарган. Иске машиналарын тарттырып, кибет янына чыгарып куйган. (Район администрациясе аларны утилләштермәсме, дип.) Тик... берничә көннән ул машиналарны Вадим Алексеевич яңадан капка төбенә алып кайтып куйган.

– Ә ничек? – дибез, аптырап.

– Шул урамда яшәүчеләр ярдәме белән. Аларга да бит урамда череп беткән машиналар торуы кирәк түгел.

Иң гаҗәбе – бу аяныч хәлдә күршеләргә берәү дә ярдәм итми. Алар инде Авиатөзелеш районы админстрациясе, Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, ТР экология министрлыгына, кыскасы, бөтен оешмага рәсми мөрәҗәгать калдырганнар. Ә нәтиҗәсе юк!

– Киләләр дә бабайга штраф язып китәләр. Шуның белән бетте, – ди Эдуард. – Ярты пенсиясен штрафларга тотып калалар. Узган ел ук әҗәте 320 мең сум дигәннәр иде. Тик аңа карап безнең хәл җиңеләйми бит...

«МИН ИНДЕ ОЗАК ЯШӘМӘМ...»

Озакламый Вадим Алексеевич үзе дә кайтып җитте. Чандыр гына, шактый таушалган

«БАЛАЛАРЫНА КИРӘК ТҮГЕЛ...»

Александр Иванов, Авиатөзелеш районының торак массивлар белән эшләү бүлеге җитәкчесе:

– Әйе, Вадим Матвеевны яхшы беләбез. Үзем дә анда бер генә булмадым. Тик... хәлне үзгәртә алмыйбыз. Дөресрәге, закон кысаларында без хәлдән килгәнне эшләдек. Суд карары бар, анда: «Йорт тирәсен чүп-чардан арындырырга», – дип язылган. Суд приставлары килде, ул аларны үз территориясенә кертмәде. Картлар йортына барырга теләми, берничә тапкыр тәкъдим иттек.

Шуңа охшаш хәл булган иде: өлкән яшьтәге хатын-кыз, нәкъ Вадим Матвеев кебек, йорт тирәсен чүп оясына әйләндерде. Бәхеткә, балалары ярдәмгә килде: әниләрен үз янына алдылар. Йорт-җирен администрация хисабына чүптән арындырдык. Утызлап арба чүп чыкты. Тик бу очракта бабайның балалары әтиләре турында ишетергә дә теләми.

«БУ – ДИАГНОЗ!»

Ләйлә Шәйдукова, психотерапевт, медицина фәннәре докторы:

– Психиатриядә «Плюшкин синдромы» дигән термин да бар. Андый кешеләр үз тирәсенә кирәкмәгән бөтен чүп-чарны ташый. Бу, чынлап та, чир. Авыруны кеше яшәми торган утрауга алып барсак та, ул анда да нинди-дер таяклар, шырпылар җыячак. Олыгайган саен кеше дөнья малы дип хафаланмый башлый һәм, ахыр чиктә, үлем алдында ялгыз килә. Ә бу кешеләр үзләре тирәсенә чүп-чар җыеп тынычланалар, шул рәвешле үзләрен ялгыз түгел, дип хис итәләр. Ни аяныч, әлеге чирне дәвалап булмый. Әгәр авыру тирә-юньдәгеләргә реаль куркыныч тудырмаса, аны мәҗбүри дәваларга җибәреп булмый.

кыяфәтле бабай икән. Кулында – сумкасы, янәшәсендә эте атлый.

– Соңгы биш елда кибеттән ризык сатып алганым юк, волонтёрлар биргән кайнар ризык ашап көн күрәм, – диде ул.

Тыны кыса икән, еш-еш сулап тора.

– Сезнең табибларга күренгәнегез бармы? – дим.

– Бар. Узган ел дүрт тапкыр хастаханәдән ятып чыктым. Мине монда үлгән дип сөйләгәннәр. Сөенгәннәрдер инде, юк, үлмәдем әле.

– Ни өчен болай чүп җыясыз?

– Чүп түгел ул, барысы да – мөлкәт. Минем монда нәрсә генә юк: суыткычлар, әллә ничә велосипед, шкафлар...

– Тик алар барысы да эшкә яраксыз бит?

– Арада яраклылары да бар. Сезне күршеләр чакырдымы? Мине күралмый алар. Алай гына да түгел, мин юкта кереп әйберләремне урлыйлар.

– Ә сезнең монда урларлык нәрсәгез бар?

– Һы! Нәрсә генә юк! Ишегалды тулы бит!

– Күптәннән чүп җыясызмы?

– Үземне белгәннән бирле. Свияжск бистәсендә үскән егет мин. Гаиләдә сигез бала идек, тормышлар бик авыр булды. Бернәрсәне дә ташламадык. Киресенчә, нәрсә очрый, шуны алып кайта идем. Ул гадәт гомергә калды.

«КҮРШЕЛӘРЕНӘ АКТИВ БУЛЫРГА КИРӘК!»

Марат Нуриев, РФ Дәүләт Думасы депутаты:

– Мондый хәлләр миңа бик яхшы таныш: күп еллар торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә эшләдем. Кызганыч, торагына чүп ташучы кешеләр еш очрый, аеруча өлкәннәр арасында. Гадәттә, район администрациясе белән идарәче компания уртак фикергә килеп эшли: үз хисапларына фатирны чистарталар. Иң аянычы – ул кеше ярты елдан тагын шуның кадәр чүп ташып куя. Закон буенча, кешене бердәнбер торагыннан мәхрүм итеп булмый. Шуның өчен дә, суд карары булганнан соң да, аларны фатирларыннан чыгара алмыйсың. Әйе, андый кешегә карата штраф салына, хезмәт хакы яки пенсиясе булса, ул штрафлар шуннан тотыла.
Ә инде гражданинның тагын бер торагы булган очракта, аны суд карары белән аукционга куярга мөмкин. Ул акчага пычрак фатирны чүптән арындырырга, коммуналь түләүләр өчен бурычлары булса, шулай ук әлеге акчаны тотарга мөмкин.
Северный бистәсендә яшәүче Вадим Матвеевка килгәндә, күршеләргә Авиатөзелеш районы администрациясен судка бирергә киңәш итәм. Дәүләт тарафыннан ел саен районга караган ташландык җирләрне чистарту өчен аерым бер күләмдә акча бүленеп бирелә. Шул акча хисабына Вадим Матвеевның ихатасын чүптән арындырырга була. Күршеләргә активрак булырга кирәк.

«ҖИҢЕЛ ЮЛ ТҮГЕЛ...»

Илдар Фазлыев, гражданлык хәлләре буенча адвокат:

– Мондый күршеләр белән яшәүчеләргә сабырлык кирәк булачак. Ни аяныч, йортыннан чүплек базы ясаган кешеләргә карата конкрет механизмнар юк, ягъни законда ул турыда әйтелгән, ләкин алар эшләми. Мондый антисанитария тудыручылар башка гражданнарның хокукларын бозучы булсалар да. Шулай да, «Плюшкин»га зарланып, гаризаны полициягә дә, санэпиднадзорга да язарга кирәк. Әйе, чүплек базында яшәүче участковыйны өенә кертмәскә дә мөмкин, ишекне ачмый, һәм шуның белән бетте. Әмма полиция хезмәткәре, тиешле беркетмә төзеп, булган хәлләрне рәсми рәвештә теркәргә тиеш. Ә бу алга таба судка мөрәҗәгать иткән очракта бер документ булып торачак.
Монда шунысы кызганыч: торак бинада чүп-чар саклау закон тарафыннан тыелмаган. Әлбәттә, алар РФ территориясендә тыелган предметлар һәм матдәләр булмаса. Шулай да бер фатирда чүп-чар туплау, яки күп итеп песи, эт асрау бу йортта яшәүче башка кешеләрнең хокукларына каршы барырга тиеш түгел. Инде сезгә комачаулый икән, әлбәттә судка мөрәҗәгать итәргә.
Бу очракта зыян күрүче як тарафыннан сәламәтлегенә, гомеренә, шулай ук мөлкәтенә куркыныч янавын күрсәтергә һәм судтан тәртипсез яшәүче күршесенә мәҗбүри суд-психиатрия экспертизасы билгеләүне сорарга кирәк. Әгәр экспертиза «Плюшкин»ны, башка кешене чирле дип таба икән, андый кешегә опекун билгеләнә. Һәм бөтен сорау опекунга кайтып кала.

– Вадим Алексеевич, картлар йортына барыгыз, кеше болай яшәргә тиеш түгел бит...

– Әле көннәр җылы, машинада йокларга була. Салкыннар башлангач, Жилплощадкадагы приютка барып төн кунам. Юк, картлар йортына китмим, әйтмә дә. Минем инде гомерем күп калмагандыр. Дөресен генә әйткәндә, яшәп туйдым, китсәм дә була. Мин үлгәч, менә шушы этем генә елар, ә кешеләргә кирәк түгелмен.

– Сезнең бит балаларыгыз бар. Алар хәлегезне белмиме?

– Оныклар да бар минем. Әллә нигә бер шалтыратып алалар. «Синең өчен оят безгә», – диләр. Ә нәрсәдән оялырга, кеше әйберен урламыйм, чүплеккә чыгарып аткан әйберләрне генә җыям.

Чынлап та, Вадим Алексеевичның кесә телефоны бар. Законнарны яхшы белә, УФСИН хезмәткәре булган.

– Капка төбенә машиналарны махсус алып килеп куйдым, югыйсә чүпне чистартабыз, дип, экскаваторлар белән килделәр.

– Бу машиналарны сатып алдыгызмы?

– Әйе, әллә кайчан инде. Арзанга гына, ун, унбиш меңгә... Кайчандыр унбер машина иде, хәзер җидегә генә калды...

СОҢГЫ СҮЗ

Күңелдә бик авыр тойгы калды: мондый картлыктан Аллаһ үзе сакласын. Тик дөресен әйтим, бабайга караганда күршеләрен ныграк кызгандым. Ни өчен әле алар мондый шартларда яшәргә тиеш? Барысының да балалары бар, урамга чыгарга куркып тор инде, ә ишегалдында күселәр чабышсын!

Күршеләрнең кулында Казан шәһәренең Авиатөзелеш районы суды карары бар. Анда акка кара белән язылган: Вадим Алексеевич үз ихатасын чүптән арындырырга тиеш. Ә бабайга суд ни дә, башкасы ни. Ул үз дөньясында яши, аңа шулай рәхәт, ә сез теләсә нәрсә эшләгез.

Бер карасаң, Вадим Алексеевичның чирле икәнлеге көн кебек ачык. Ләкин бер генә оешма, социаль хезмәт, түрәләр әлеге хәлне күрергә теләми. Шушы язмага алынгач, без генә дә бернičә рәсми оешмага мөрәҗәгать иттек. Социаль оешмаларга, «Кеше приюты»на да чыктык. Соңгысында исә болай дип җавап бирделәр: «Без бу бабайны бүген үк йортыннан барып алырга риза. Әмма ул биредә бер көн дә яшәмәячәк. Бу бит колония түгел, монда фәкать кешене үз теләге белән генә яшәтеп була».

Әлеге хәлгә нокта куймыйбыз. Бәлки, язманы җаваплы кешеләр укыр. Ә без, үз чиратыбызда, республиканың рәсми оешмаларына мөрәҗәгать итәчәкбез. Болай яшәргә ярамый, егетләр!

«СУДКА МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘРГӘ ХОКУКЛЫ»

Роспотребнадзорның ТР буенча идарәсенең матбугат хезмәте:

– РФ административ хокук бозулар Кодексының 6.4 маддәсе нигезендә, торак һәм җәмәгать урыннарын, биналарны, корылмаларны һәм транспортны эксплуатацияләүгә санитар-эпидемиологик таләпләрне бозган өчен административ җаваплылык билгеләнгән.

СанПиН 2.1.3684-21 «Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен карап тотуга, су объектларына, эчә торган суга һәм халыкны чиста су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракка, торак урыннарга, җитештерү, җәмәгать урыннарын эксплуатацияләүгә, санитар-эпидемиягә каршы профилактик чаралар оештыруга һәм үткәрүгә санитар-эпидемиологик таләпләр», бина һәм биналарны төзүгә, җиһазлауга һәм карап тотуга регламентлаштыручы санитар-эпидемиологик таләпләр торак биналарны карап тотуга (торак бинаны чүпчарга, пычратуга юл куймау) таләпләр билгеләми.

РФ Торак кодексының 29.12.2004 елгы 188-ФЗ номерлы законы таләпләре нигезендә:

– торак кагылгысыз, беркем дә торакта яшәүче гражданнарның ризалыгыннан башка яисә суд карары нигезендә торакка үтеп керергә хокуклы түгел (3 нче маддә);

– торакның хуҗасы әлеге бинаны тәртиптә тотуны үз өстенә ала, шулай ук күршеләрнең хокукларын, аларның мәнфәгатьләренә зыян салмыйча, күпфатирлы йортның гомуми мөлкәтенә сак караш булырга тиеш.

Югарыда санап кителгәннәрдән чыгып, гражданинны РФ КоАП 6.4 маддәсендә каралган хокук бозу өчен административ җаваплылыкка тарту өчен хокукый нигезләр юк.

РФ Торак кодексының 11 нче маддәсе нигезендә, торагына зыян салынган очракта, аның хокукларын яклау процессуаль законнарда билгеләнгән ведомство аша суд тарафыннан гамәлгә ашырыла, ягъни күпфатирлы торак йортта яшәүчеләр судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Онытылмас исемнәр арасында **кемнәр** бар

Миләүшә Хәйруллина **нинди** китаплар укый

Балалар китап дөньясы **ничек** үзгәрә

Уракчы авылының үзенчәлеге **нәрсәдә**

Берлянд-Филипсон йорты **ничек** сакланган

ЗАКИР ГАЛИ: ЯЗМЫШ ТӨЕННӘРЕ

Айдар Шәйхин

Исеме җуелган, ә бәлки җуйдырылган байтак шәхесләребезнең берсе – журналист, әдәби тәнкыйтьче Закир Гали. Аның энциклопедияләр, сүзлекләргә кергән кадәр тәрҗемәи хәле бик буталчык. Еш кына туган елы да, атасының исеме дә дөрес бирелми, кайда, нинди эшләр башкарганы да чыганакларның күбесендә теркәлми калган. Шуңа да күбрәк «З. Гали» дип кенә билгеле булган кеше турында табылган кадәр мәгълүматны укучыга тизрәк җиткерергә омтылдык.

КЕМ СИН, З. ГАЛИ?

Закир Гали турында ачык чыганаклардагы мәгълүмат бик буталчык, дидек. Совет чоры документларында ук күрсәтелгән, аннан хәзерге китапларга кереп киткән туу вакыты – 1902 ел, әмма бу дөрес мәгълүмат түгел. Татар энциклопедиясенә, ә аңа карап башка җыентыкларга, фәнни мәкаләләргә кереп киткән атасының исеме – Халит. Әмма бу да дөрес түгел.

Дөреслек – метрика язмасында. Татарстан Дәүләт архивында сакланган Ямбакты авылының метрика кенәгәләренә таянсак, менә нинди мәгълүмат ачыла.

Закир Хатыйп улы Галиев 1901 елның 10 гыйнварында Казан губернасы Спас өязенең Пичкас волостена кергән Ямбакты авылында туган.

Аның тууы хакында язмадан баланың тулы исеме Мөхәммәтзакир икәнен, әтисенең дә борынгы гадәткә ярашлы рәвештә, тулы исеме Мөхәммәтхатыйп Мөхәммәтгали улы булганлыгын беләбез. Бәхеткә, метрикада бабасының да тулы исеме кереп калган: Мөхәммәтгали Шәмсетдин углы. Анасы исә – Хәтирә Низаметдин кызы. Шәмсетдин бабай нәселе дәүләт крестьяннары катламына караган.

Ямбакты – Болгар чорларында ук кешеләр күпләп яшәгән урында урнашкан, исеме 1690 нчы еллардан башлап рәсми кәгазьләрдә теркәлә башлаган авыл ул. Инкыйлабка кадәр өч мәхәлләсе була, 1908 елда авылда 2617 кеше яши. Мәдрәсәсе тирә-юньдә данлыклы, анда булачак язучы Абдулла Алиш та балачак елларының бер өлешен үткәрә.

Әлегәчә өйрәнелгән документларда бу хакта әйтелмәсә дә, Закир Галинең педагогика техникумында (Казан татар укытучылар мәктәбендә) укыган булуы мөмкин. Мондый фаразларга төп нигез – атаклы химик, профессор Гыйлем Камайның студент чагында бер төркем татар яшьләре белән төшкән фотосурәте. Анда 1916–1920 елларга хас киемнәрдәге кызлар-егетләрне күрәбез. Түбәтәйле бердәнбер егет – Закир Галиев үзе! Камайның 1916–1918 еллар тирәсендә укытучылар мәктәбендә укуын исәпкә алсак, аның яшьтәше Закирның да шул ук урында белем алуы ихтимал.

Документаль расланган тагын бер биографик чыганак – партия архивыннан 1961 елда бирелгән белешмә. Аның күчермәсе Татарстан Милли музее фондына тапшырылган. Шуңа нигезләнеп, Закир Гали биографиясенең төп нокталарын тергезә алабыз.

20 яшьлек чагында, ягъни 1921 елда, Закир Спас өязе РКП(б) комитетында оештыручы (организатор) вазыйфасын башкара. Бик тиздән ул Казанга күчеп китә булса кирәк, чөнки комсомолның губерна (бу вакытта инде – республика) бюросына керә, Татарстан комсомол оешмасы каршындагы 16 нчы хәрби курсларда укыта.

Галиевнең бер ел гомере хәтәр исемле оешмада – ОГПУда үтә. Биредә ул уполномоченный вазыйфасын башкара. Берләштерелгән дәүләт сәяси идарәсе – ОГПУ – СССРда 1923–1934 елларда дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итә торган төп оешма була. Ул, бер яктан, бандитизм, шпионаж кебек күренешләргә каршы көрәшсә һәм совет милициясен контрольдә тотса, икенче яктан, сәяси репрессияләр үткәрү, контрреволюциягә каршы тору

Фотолар ТР Милли музее фондыннан

да аның вазыйфасына керә. ОГПУның республика һәм өлкәләрдә, өяз һәм кантоннарда вәкаләтле вәкилләре була. Әлеге вәкилләр урыннарда куркынычсызлыгы оешмасының эшен тәэмин итә. Бер ел тирәсе Закир Гали шушы эш белән мәшгуль була. Мондый хезмәткә билгеләнер өчен сәяси яктан ышанычлы дип табылу таләп ителә. Ә Закир үзенең кемлеген партиягә кереп раслый: 1920 елда партия әгъзасына кандидатлыкка кабул ителсә, 1923 елдан ул – чын коммунист.

Ул еллардагы татар язучы-журналистлары арасында хәрбиләр аз түгел. Әмма ОГПУда эш тәҗрибәсе булган әдипләр – сирәк күренеш. Закир Галиев шундый сирәкләрнең берсе. Бу аңа киләчәктә нинди йогынты ясаган икән? Әйтүе кыен. Әмма аның исеменә тап төшермәгән дип әйтеп булмый. «З. Гали»нең бүгенгә кадәр «онытылуы» да шуның белән бәйле түгелме икән?

МАТБУГАТКА КИЛГӘН ЯШЬ КӨЧ

1920 нче еллар уртасына җитәрәк, Закир Гали Казандагы әдәби даирәгә якыная башлый. Татар педагогика техникумында оешкан әдәбият түгәрәгендә катнаша, шунда «Яшь көч» дигән кулъязма журнал оештырган яшьләрнең берсе була. Сүз уңаеннан, кулъязма журналның бер саны 1970 нче еллар ахырында партия архивында табыла. «Яшь көч»нең зур форматлы 28 биттән торган әлеге санында унбишләп шигырь, өч очерк, бер хикәя, бер нәсер, ике парча урнаштырылган. Алар арасына рабфак студенты Муса Җәлилнең дә шигыре кергән.

ОГПУдагы вазыйфасыннан котылган Закир Гали 1923 елда «Кызыл Татарстан» газетасына эшкә урнаша. Биредә ул озак еллар хезмәт куя, хәзерге «Ватаным Татарстан»ның тарихына үз өлешен кертә. 1925 елның көзенә кадәр ул газетада партия бүлеге җитәкли. Шунысы кызык: Закир Галидән соң бу урынга Казанга яңа гына күченеп килгән Шәриф Камал билгеләнә.

Ә Закирның алдында исә яңа зур бурыч тора: белемен күтәрергә! Шуңа күрә дә ул Мәскәүдәге Дәүләт журналистика институтына укырга керә. Әлеге уку йорты Советлар Союзында махсус рәвештә коммунист журналистларны әзерли торган беренче институт буларак 1919 елда ук оештырыла. Закир монда белем алган елларда институтта чагыштырмача көчле кадрлар эшли, алар гуманитар юнәлештә шактый әзерлекле белгечләр укытырга сәләтле була. Биредә Закир Гали 1925–1928 елларда укып чыга.

Яңа белем туплап, Казанга әйләнеп кайткач, Закир янәдән «Кызыл Татарстан»га урнаша, әмма бу юлы җаваплы сәркатип вазыйфасына куела. Бу чорда татар матбугатында Закир Галинең әдәбият тормышына кагылышлы тәнкыйть мәкаләләре күренә. Теоретик белеме ныгыгач, тагын да кыюрак яза башлый.

1929 елда татар язучылары илнең көньяк төбәкләренә оештырган зур сәяхәттә Закир Гали дә катнаша. Юлдашы, «Беренче зур сәяхәт» исемле истәлек китабы авторы Газиз Иделле аңа менә мондый характеристика биргән:

«Урта буйлы, ябыграк гәүдәле журналист Закир Гали генә ничектер уйланыбрак утыра,

Казан студентлары. Утырганнар: Закир Гали (уңнан беренче), Гыйлем Камай (сулдан өченче).

гомуми әңгәмә – бәхәскә, шаяруларга катнашмый. Ул салон уртасындагы зур өстәл кырыенарак утырган да, түшәмгә табарак карап, нәрсә турындадыр һаман уйлана, маңгаен җыерган, күз кабаклары салынган, чырае ачулы сыман, әйтерсең лә ул менә пароход салонында түгел, ә «Кызыл Татарстан» редакциясендәге үзенең кабинетында, кытай хунхузларын тиргәп, зәһәрле бер мәкалә язып утыра. Шулай булуы да мөмкин».

Әйе, Закир Галинең язмалары «Кызыл Татарстан»да да, әдәби журналларда да чыгып килә. Өстәвенә, ул язучыларның «Атака» журналында – редколлегия әгъзасы, 1932 елда аның җаваплы сәркатибе дә була әле. «Атака» – Татар пролетар язучылары ассоциациясе (ТАПП) тарафыннан гамәлгә куелган басма. Кави Нәҗми, Гомәр Толымбайлар коллективы оештырган бу журнал, соңрак «Яңалиф», «Колхоз яшьләре» журналлары белән берләшеп, «Совет әдәбияты», ягъни хәзерге «Казан утлары»на нигез булып китә. Әмма 1930–1932 елларда ул, әдәби әсәрләр, тәнкыйть мәкаләләре, күзәтүләрне бастырудан тыш, ТАПП оешмасының мәсләгенә туры килгәнчә, «әчке эмигрант»ларны, «кулак җырын җырлаучы»ларны һәм пролетар яки крестьян булмаган әдәбиятны фаш итү белән дә шөгыльләнә.

Мәгълүм ки, ТАПП үзе 1932 елда таратыла. Кыска вакытлы тарихында аның белән бәйле берничә зур низаг та чыга, шуларның иң атаклысы – «җидегәнчеләр» тарихы. ТАПП органы «Атака»ның идарәсендә дә, оешма җитәкчелегендә дә Закир Гали күренекле урынны били. Ә ТАССР Язучылар берлеген төзү эше башлангач, аны оештыру комитетына Закир Гали рәис урынбасары итеп билгеләнә.

Закир Гали хатыны Зөһрә белән.

ТЕАТРДА ҺӘМ ХӘРБИ МАТБУГАТТА

Биографиясенең партия белешмәлегенә кертелмәгән бер ноктасы – татар театрын җитәкләве. Архивлардагы кайбер документларда «театр директоры З. Гали» сүзтезмәсе очрый, әмма анысын безнең Закир Галинең тулы адашы гынадыр дип, уйлый идем. Ул еллардагы татар дөньясында «Галиевләр», «Галиләр» бихисап бит! Гариф Галиев, Закир Галиев, Гали Галиев, Мөхәммәт Гали һәм башка бик күпләр бар.

1931 елда «Атака» журналының 1 нче санында Риза Ишморатның «Татар театры турында» дип аталган мәкаләсе басыла. Ул фотографияләр белән баетыла, театр коллективында җитәкче вазыйфаларны биләгәннәрнең сурәтләре бирелә. Тәүге битендә үк астына «Татар академия театры, З. Гали» дип язылган портрет – журналист Закир Галинең фотосурәте урнаштырыла. Димәк, күпмедер вакыт дәвамында ул чынлап та татар дәүләт академия театрын җитәкләгән икән.

Ә инде партия белешмәлегендә сызылган юл буенча барсак, Закир Галинең 1932–1934 елларда «Кызыл Татарстан» газетасында мөхәррир ярдәмчесе булып эшләвен, ә аннары «Кызылармеец» газетасына җаваплы сәркатип итеп билгеләнүен беләбез. Идел буе хәрби округының сәяси идарәсе тарафыннан башта Самарада, аннары Казанда татар телендә чыгарылган бу газета 1924–1938 елларда гамәлдә була. Барлыгы 1404 саны чыга. Яшь татар язучылары һәм журналистларыннан күпләр бу басмада эшләргә өлгерә: Кави Нәҗми, Нур Баян, Мөхәммәт Парсин, Фатих Кәрим, Закир Сәмитов, Закир Гали исемнәрен аерым атарга мөмкин. Рәссам Байназар Әлминов газета Самарада чыккан чакта аның бизәлеше өчен җавап биргән. Газетада мәкаләләре басылган хәрбиләр арасында атаклы генерал Якуб Чанышев та бар. Хәрби газета булгач, мөхәрриренең азмы-күпме шушы даирә белән бәйләнеше соралган, әлбәттә. Мөгаен, шуңадыр Закир Галиев соңгы елларында политрук дәрәҗәсенә ия булган. Исеме аклангач, 1958 елның 29 октябрендә, хатыны Зөһрәгә реабилитацияләнгән ире өчен Татарстан хәрби комиссариатының финанс-пенсия бүлеге 462 сум күләмендә пособие түли.

Театр, матбугат, хәрби хезмәт… Болардан тыш, Закир Галине тасвирлый торган тагын ике зур эш бар: тәрҗемә һәм әдәби тәнкыйть. Тәрҗемәче буларак, аның татар теленә Иосиф Сталин мәкаләләрен тәрҗемә итүдә катнашканы билгеле. Кузьма Горбуновның «Ледолом» романын та татарчага Закир Гали тәрҗемә итә. Ә тәнкыйтьче буларак, әлбәттә, Закир Гали дөньяга ТАПП идеологиясе күзлегеннән карый. Шагыйрь Сирин, язучы Газиз Гобәйдуллин җыентыкларына язган мәкаләләрендә ул аларның иҗатларына «вульгар социологизм» карашыннан чыгып бәя бирә.

Әдәбият галиме Фоат Галимуллин язганча, «Закир Галине без шулай ук социологизм тарафдарларының аеруча фанатиклары төркеменә кертә алабыз. Ник дигәндә, әдәбиятның сыйнфый булырга тиешлеген аңардан да кистереп әйтүчене табуы кыен». Чынлап та, мәкаләләреннән күренгәнчә, Закир Гали һәрвакыт әдәби иҗатны сыйнфый каршылык күзлеге аша бәяли. Менә үзенең сүзләре:

«Һәр шигырь сыйнфый, һәр шигырь шул кадәр үк сәнгатьчә булырга тиеш. Моны үтәү өчен һәр шагыйрьгә үзен сыйнфый көрәшнең кызылармееңы, социализм төзелешенең активы итеп әверелдерү беренче шарт булып тора».

Закир Галинең имажинистлар, футуристлар һәм башка төр «экспериментчыларны» тәнкыйтьләп язган мәкаләләре дә сакланган. Ул аларны, «матур әдәбиятта сәясәттән читтә торучылыкка, шуның аркылы матур әдәбиятның сыйнфый көрәш өчен корал булу көчен югалтуга барып чыгалар», дип гаепли.

Яңа заманның яңа әдәбиятын сыйнфый көрәш кагыйдәләренә буйсындырырга теләгән Закир Галинең үзен дә «көрәштәшләре» сындыра шул.

ОНЫТЫЛУ

1936 елның көзендә Татарстан язучылар берлеген «чистарту» башлана. Кави Нәҗми иптәшләрен сакларга теләсә дә, ничәдер кешене барыбер берлектән чыгарырга туры килә. Беренче корбаннар сафына Закир Гали дә эләгә.

Аның ТАССР Язучылар берлегеннән чыгарылуын «котлап», Евгения Гинзбург мәкалә дә яза. «Изгнан также из рядов союза писателей двурушник Закир Галеев. Этот «писатель» был в свое время правой рукой националиста и троцкиста Сагидуллина, способствуя опубликованию в татарской прессе сагидуллинских контрреволюционных статей. Тот факт, что Фатых Сайфи и Закир Галеев могли до последнего времени подвизаться на литературном фронте Татарии, свидетельствует о гнилом либерализме, проявленном и союзом советских писателей, и редакцией журнала «Совет әдәбиатэ», печатавшей Фатыха Сайфи». Мондый куркыныч сүзләрне язганда, Гинзбург, әлбәттә, үзенең дә ярты елдан кулга алынасын, мәхшәр аша үтәсен белми әле…

Закир Гали 1937 елның 8 гыйнварында кулга алына. НКВД аны, «Троцкий тарафдары, террористик оешма әгъзасы», дип игълан итә. СССР Югары судының Хәрби коллегиясе бу сүзләр белән килешә һәм шул ук елның 3 августында Закирны гаепле дип таба. Ул, адашы Гомәр Гали кебек үк, 10 елга ирегеннән мәхрүм ителә.

Нахакка хөкем ителгән Закирны Южлагка – Бурятия башкаласы Улан-Удэ шәһәре тирәсендә урнашкан хезмәт лагерена җибәрәләр. Ул Улан-Удэ – Наушки тимер юл линиясен төзүдә катнаша. Болай да өзлеккән сәламәтлеге авыр хезмәт шартларында тәмам какшый. 1941 елның 18 декабрендә Закир Гали Южлагта вафат була.

Бу вакытта аның хатыны Зөһрә дә төрмәдә була. Зөһрә ханым кулга алынганчы укытучы булып эшли. Аны 1937 елның 21 августында, ягъни ире хөкем ителгәч, хыянәтче гаиләсе әгъзасы буларак кулга алалар. 4 октябрьдә НКВД Махсус киңәшмәсе карары белән 8 елга ирегеннән мәхрүм итәләр. Аны Сиблаг карамагына тапшыралар һәм Томскидагы лагерьга җибәрәләр. Балаларын – 11 яшьлек Марат белән 7 яшьлек Ренатны махсус приемникка урнаштыралар. Уллары Маратның кызы Луиза ханым Фомичева гаиләсендә Зөһрә һәм Закир Галиевләрнең документлары һәм фотосурәтләре сакланып калган. 2007 елда ул, аларны Татарстан Милли музеена тапшырып, якыннарының истәлеген галимнәргә ачты.

1958 елда Закир Галинең дә, хатыны Зөһрәнең дә эшләре яңадан карала, гаепләре өсләреннән төшерелә. Әмма исеме акланса да, Закир Гали озак елларга онытылып кала. Хәзер аның турында да мәгълүматыбызны тирәнәйтергә, шул чор матбугат тормышын җентекләбрәк өйрәнергә вакыт җиткәндер.

Закир Гали гаиләсе белән. Сулдан уңга: туганы (исеме теркәлмәгән), улы Марат, улы Ренат, хатыны Зөһрә.

китап к

«КИТАП – МӘҢГЕЛЕК!»

Әңгәмәдәш: Луиза Янсуар

Соңгы елларда татар музыка сәнгате күгендә Миләүшә Хәйруллина йолдызы калыкты дисәк тә, ялгышмабыз. Татар театрлары репертуарында барган спектакльләрне аның композицияләре бизи, заманның иң затлы җырчылары аның бүгенге һәм классик шагыйрьләр иҗатына язган җырларын җырлый, «Кави-Сәрвәр» операсын А. Сладковский җитәкчелегендәге ТР Дәүләт академик симфоник оркестры һәм М. Тәминдарова җитәкчелегендәге ТР камера хоры башкара, музыкасы хакимият концертларында һәм республиканың төп бәйрәмнәрендә яңгырый. Ул – ТР һәм РФ Композиторлар берлекләре әгъзасы, күпсанлы россиякүләм һәм халыкара бәйгеләр, фестивальләр лауреаты.

-Балачак китапларыгыз нинди?

– «Волшебник изумрудного города», «Кошкин дом», «Шүрәле», «Су анасы», «Чёрная курица, или Подземные жители», Агния Барто шигырьләре. Әнием белән бергә бик күп китаплар укыдык. Китап уку – ул безнең өйдә матур гадәт иде. Хәзер дә – шулай.

– Иң беренче хәтерләгән китабыгыз?

– Самуил Маршакның «Кошкин дом» китабы. Гаиләдә бүген дә искә алып сөйли торган матур бер хатирә бар: 3 яшемдә мин бу китапны яттан белгәнмен һәм, барысын да шаккатырып, шатырдатып сөйләп тә бирә торган булганмын.

– Нинди китап сезне формалаштырды, дип әйтә аласыз?

– Төгәл генә менә монысы, дип әйтү кыенрак, билгеле... Әкиятләр булгандыр, дип уйлыйм. Төрле халыкларның, милләтләрнең әкиятләрен күп укыдык без. Шулай ук – Андерсен, Пушкин, Тукай әкиятләрен...

– Тормышыгызда иң зур тетрәнү китергән китап?

– Борис Полевойның «Повесть о настоящем человеке» бик тетрәндерде. Тамара Смирнова-Карпинскаяның «Вера Горская», Джек Лондонның «Мартин Иден» әсәрләре, Чыңгыз Айт-

Фото: Миләүшә Хәйруллина архивыннан

иштәсе

матов повестьлары белән романнары. Оскар Уайльдның «Исповедь» китабы һәм экиятләре. Үзебезнекеләрдән – Кави Нәҗми белән Сәрвәр Әдһәмованың хатлар җыентыгы...

– Китап уку өчен сезгә нииндидер аерым халәт, көйләнеш кирәкме? Бәлки, урын?

– Юк, кирәкми. Вакыт гына кирәк! Вакыт җитми күп нәрсәгә...

– Милли классика һам заман әдәбиятыннан кемнәрне югары бәялисез?

– Татар әдәбиятыннан күбрәк шагыйрьләрне беләм. Йолдыз Миңнуллина, Луиза Янсуар, Рүзәл Мөхәммәтшин, Гөлүсә Батталова иҗатларын бик хөрмәт итәм.

– Дөнья әдәбиятын күзәтеп барасызмы? Кайсы телләрдә укыйсыз?

– Дөнья әдәбиятын тулаем күзәтеп барам дип әйтә алмыйм. Нәрсәләр турындадыр ишетеп беләм. Ә менә профессиональ музыкаль әдәбиятны җентекләп укыйм, өйрәнәм. Миндә үз һөнәри өлкәмә караган шактый бай китапханә тупланып килә: ул искерми, һәрчак актуаль һәм кирәк. Мәсәлән, Георгий Гаранянның «Основы эстрадной и джазовой аранжировки», Юрий Каспаровның «Темброфактура в современном камерном ансамбле», Сергей Поповның «Инструментоведение для профессиональных композиторов, оркестровщиков» һ.б. Киңрәк аудитория дә укый алырлык Дэвид Юэнның «Джордж Гершвин. Путь к славе» китабы, Валентина Холопованың София Гобәйдуллинага багышланган атаклы монографиясе, Сергей Прокофьевның автобиографиясе...

– Әдәбиятның милли йөзебезне, менталитетыбызны саклаучы булуы белән килешәсезме? Ул үзенә, чынлап та, мондый вазыйфаны алырга тиешме?

– Килешәм. Татар телендә дә, рус телендә дә татарларның тормышы, асылы турында, милли элемент белән язылган әсәрләр кирәк. Алар безнең йөзебезне саклый ала. Югары дәрәҗәдәге, сыйфатлы тәрҗемәләр булырга тиеш. Милли әдәбиятлар һәм милли сәнгать – дөнья культурасының бер өлеше бит ул.





– Сез бөтенләй кабул итә алмаган авторлар/китаплар бармы?

– Юк, ахрысы. Төрле фикерләр, карашлар булуына тыныч карыйм.

– Кәгазь китапмы, электрон форматмы?

– Кәгазь китап.

– Хәзерге вакытта (бәлки, һәрвакыт) өстәл китабыгыз?

– Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре».

– «Китап ул – минем өчен...» – әлеге фразаны ничек тәмамлар идегез?

– Китапның тормышымда нинди роль уйнавын «Тукай мәйданы» музыкаль китабымны чыгарган вакытта бик яхшы аңлаган идем. Менә бу сүзләр белән җавап бирә алам: «Китап кеше цивилизациясе тудырган иң югары казаныш. Кешелек бүген һәм киләчәктә тагын нәрсә генә уйлап тапмасын, китапны алыштыра алмый. Китап – мәңгелек!»





БАЛАЛАР КИТАБЫ ЯҢАРЫШЫ: АРТБУКЛАР, ИНТЕРАКТИВ, ФАН-ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК

Ксения Пупкова



Республика көнендә Казанда Казансу яр буендагы «Елмай» балалар паркында «Тау Фест» гаилә китап фестивале башланды. Ул ике көн дәвам итте, шушы арада казанлылар һәм шәһәр кунаклары бу урынны яратып өлгерде. Биредә балалар язучылары, китап бизәүчеләр, нәширләр һәм фестивальне оештыручылар балалар китабы дөньясының ничек үзгәрүе турында фикер алышты. Үсмерләр һәм нәниләр өчен хәзерге заманда китап уку ничек үзгәрә, традицион уку рәвеше мультимедиа форматлар белән ничек үрелеп китә һәм әдәбият нинди ысуллар белән буыннарны берләштерергә ярдәм итә.

«Татарстан» китап рәтләре буйлап йөреп чыкты, яңа китапларны тотып, битләрен актарып карады, мастер-классларда катнашты, китап буенча белгечләрдән балалар өчен яңача китап бастыру серләрен белеште. Һәм аларны бүген рәхәтләнеп укучылары белән бүлешергә дә әзер.

Шулай итеп, нәрсә ул – балалар өчен яңа китап? Күбрәк «телефонда утыручы» укучыны китап укырга ничек җәлеп итәргә? Гомумән, бүген туктаусыз үзгәреп торган дөньяда бу мөмкин хәлме?

Фото: Александр Ефремов, Ксения Пупкова, Андрей Бутко/ru.wikipedia.org, illustrator.odub.tomsk.ru

КИТАПЛАР БИЗНЕС ЧЫНБАРЛЫГЫНА ЯРАКЛАШЫРГА ТИЕШ

Сергей Чекмаев, Россия язучысы, фантаст, сценарист һәм әдәби мөхәррир:

– Хәзерге заманда китапның йөзе бик тиз үзгәрә, ул инде ияләшенгән кәгазь формат кысаларыннан күптән чыкты. Артбуклар һәм мультимедиа басмалар текстны визуаль, интерактив һәм цифрлы элементлар белән берләштерә: өстәлгән чынбарлык булган китаплар укучыны 3D-форматка күчерә, китап битләрендә видеоматериалларга, блогларга, аудиоверсияләргә һәм мультмедиа календарьларга алып чыга торган QR-кодлар куелырга мөмкин. Китап тирәсендә кросс-медиа проектларын торган саен ешрак күрергә була, уйлап чыгарылган галәм хәзер текстта гына түгел, уеннарда, фильмнарда, өстәл уеннарында да яши, персонажларның социаль челтәрләрдә үзләренең профильләре һәм аккаунтлары барлыкка килә, бу исә укучыга яраткан геройлары белән китаптан тыш та бергә калу мөмкинлеге бирә.

Китапларны коллекцияләү бөтенләй яңа төс ала – чикләнгән тираж, эксклюзив материаллар, югары сыйфатлы басма һәм уникаль бизәлеш матур детальләр булып кына калмый, ә китапның кыйммәтен билгеле торган күрсәткечкә әверелә. Сатып алучылар, китапны укып чыгу белән генә чикләнмичә, аны коллекция предметы сыйфатында үзендә булдырырга омтыла, социаль челтәрләргә куя. Китапны төргәктән чыгару, битләрен актарып карау мизгелен видеога төшерә, бизәлеше турында фикер алыша һәм фан-җәмәгатьчелектә катнаша. Китаплар бизнес чынбарлыгына яраклашырга мәҗбүр: яхшы текст кына түгел, ә «тәмле» визуал, дөрес маркетинг, коммуникациянең барлык каналлары белән эшләү таләп ителә. Китап – бүген зур медиапространствоның бер өлеше. Бары тик эчтәлегеннән алып тышлыгына кадәр – комплекслы эшләнгән басмага гына бүген чын ихтыяҗ була ала, ул аны яңа буын мәдәниятендә озын гомерле, тере итә.

ҮСМЕРЛӘР ҮЗЛӘРЕН АҢЛАРГА ЯРДӘМ ИТӘ ТОРГАН КИТАПЛАРНЫ УКЫЙ

Любовь Маханькова, «Графо» нәшрияты мөхәррире:

– Соңгы елларда үсмерләр әдәбиятына ихтыяҗ артты, һәм китап базары әлеге катлаулы, шул ук вакытта әһәмиятле аудиториягә торган саен ныграк йөз белән борыла. Үсмерләр үзләрен, хисләрен аңларга, кабул итәргә, әти-әниләре һәм әйләнә-тирә белән мөнәсәбәтләрен җайларга ярдәм итә торган китапларны укый. Үз юлын эзләү, беренче мәхәббәт, дуслык, хатлар һәм киләчәккә хыяллар турындагы әсәрләр аеруча популяр. Еш кына шундый китаплар аша үсмерләр тормышта була торган төрле хәлләргә читтән карый ала, чынбарлыкта нәкъ менә шулай читтән карау җитмәскә мөмкин бит.

АЛАРНЫ МАҖАРАЛЫ, ГАДӘТИ БУЛМАГАН ТАРИХЛАР ҖӘЛЕП ИТӘ

Ольга Шуравина, балалар язучысы:

– Бүгенге үсмерләр әдәбиятны бик сайлап кына укый, күптән түгел үземнең тикшеренүләремнең нәтиҗәсен чыгардым – 12 000 бала арасында сораштыру үткәрдем. Аларны иң элек фантастика һәм фэнтези җәлеп итә, бу жанрны 9 628 катнашучы сайлаган. Детективлар да популяр – 6 446 кеше, аннан соң романтик тарихлар бара – 5 353. Классиканы – 4 302, фәнни-популяр китапларны 2 551 үсмер укый, ә шигърият белән 1 424 респондент кына кызыксына. Бу статистика шуны күрсәтә: үсмерләрне бүген мажаралы, гадәти булмаган тарихлар җәлеп итә, һәм менә нәкъ шундый китаплар аша без аларның күңеленә юл саба, китап укырга кызыксыну уята алабыз.

РӘССАМ КУЛЫ, ЯКИ КОМПЬЮТЕР КОДЫ

Надежда Бугославская, рәссам-иллюстратор:

– Минем өчен кулдан ясалган рәсемнәр аеруча кыйммәтле булып кала – аларда рәссам рухы, аның холкы сизелеп тора, нәкъ менә шул китапны тере итә. Гәрчә бүген комикслар турында торган саен ешрак сөйләшсәләр дә, бездә алар барыбер классик китап иллюстрацияләрен алыштыра алмады. Безнең өчен кадрлар сериясе түгел, ә аерым, тәгәлләнгән образлар мөһимрәк.

Комикс ясау җиңел түгел, ул бөтенләй башка җирлек. Миңа иялңгән юл якынрак – иллюстрацияләрне туп-туры кәгазьгә төшергәндә, аның һәр сызыгы күңел җылысы кушып эшләнә.

Балалар һәм үсмерләр өчен иллюстрацияләр бер-берсеннән аерыла: нәниләргә җете төсләр кушылган картиналар кирәк, үсмерләрне ак-лы-каралы сурәтләр җәлеп итә – аларда әйтеп бетерелмәгәнлек, сер кала, бу исә аларның мөстәкыйль рәвештә эзләнүләренә, уйлануларына җавап бирә.

Миңа калса, китап өчен ясалган иллюстрация сюжетка, аның атмосферасына күмелергә булышырга тиеш, рәсемнең бурычы – текстны кабул итүне җиңеләйтү. Модада булган агымнарга иярү генә түгел ул. Хәзер күп нәрсә компьютерда ясала, һәм кайбер стильләрнең кабатлануы сизелә. Нәкъ менә шуның өчен дә миңа рәссамның үз стилен табуы, популяр трендлар артыннан чапмавы мөһим. Иң әһәмиятлесе – эшең тере, ихлас булсын, иллюстрация чыннан да китапны баетып җибәрсен.

БАЛАЛАР ҮЗЛӘРЕ МЕНӘ ДИГӘН ЯЗУЧЫЛАР



Розалина Мусабирова, Р. Миңнуллин исемендәге Республика балалар китапханәсендә проект җитәкчесе:

– Балалар үзләре китап язып чыгаруга юнәлтелгән проект Казан өчен уникаль, һәм андый проектлар башка юк. Ул Р. Миңнуллин исемендәге Республика балалар китапханәсе ярдәме белән оештырылды, китапханәнең шундый башлангыч белән чыгуы бик мөһим.

Балалардан китап уку гына таләп итү җитми хәзер – системаны үзгәртергә һәм балаларга үзләренә китап язу мөмкинлеге бирергә кирәк. Шунысы кызык: бала үз китабын эшли башлагач, ул башка әсәрләргә мөрәҗәгать итә. Яхшырак язасы килеп, күбрәк укый, мисаллар эзли, бизәлеш турында фикер алыша, идеяләр белән бүлешә башлый. Шулай үзләре тоеп, кичереп яшәүче укучылар мохите формалаша.

Катнашучылардан күреп торам: үз китабын кулга алу аларда көчле кичерешләр уята – дулкынлану, шатлык, горурлык, үз-үзенә ышану. Әти-әниләре еш кына яшьләрен тыеп кала алмый, чөнки алар балаларының иҗади уңышын үз күзләре белән күреп тора. Балалар үз китапларын тудыра торган мондый проектлар һәркайда барлыкка килергә, киңрәк төс алырга тиеш, дип саныйм. Асылда, бу мөмкин булмастай эш түгел: теләк кенә кирәк, калганы табыла. Теләсә кайсы мәктәп иганәчеләр җәлеп итеп оештыра ала аны. Мәсәлән, безгә иганәчеләр китапларны бастырырга булышты, ә кайбер әти-әниләр, балаларының уңышы белән илһамланып, басмаханә чыгымнарын үзләре күтәрде. Китапны дусларыңа, туганнарыңа бүләк итәргә була.

Таләпләр белән генә чикләнмәскә кирәк, балаларны иҗатка рухландыру һәм аларга казанышлары өчен горурлык хисе кичерү мөмкинлеге бирү яхшырак. Андый тәҗрибә гомерлеккә сеңеп калачак.

БИРЕДӘ АТА-АНАЛАР БЕЛӘН БАЛАЛАРНЫҢ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕ КИСЕШӘ

Полина Скидан, «Читай город» чараларының менеджеры:

– Китап чаралары оештыру буенча тәҗрибәмнән чыгып, шуны әйтә алам: балаларга мульфильмнар, мәсәлән, «Союзмультфильм», «Простоквашино» буенча чыккан китаплар һәм классика кызыклы.

Чебурашка, Кот Матроскин кебекләр һәрбер яңа буын өчен актуаль булып кала.

Ата-аналар да аларны үз балачакларын искә төшереп сайлап ала. Вакыт сынавын узган китаплар аларда ышаныч уята. Шулай ук яңа авторларның төрле буыннарны берләштерә алырдай яңа китапларын да яраталар.

Ил буенча китап фестивальләре, клублар, авторларның гаиләләр белән очрашулары артуына без бик сөенәбез – әдәбият офлайнга чыга һәм күз алдында терелә. Бу чынбарлыкка кайту, шул ук вакытта «китап» тылсымы да сакланып кала: башта балалар геройлар белән китап аша таныша, аннан соң аларны интернеттан эзли, фестивальләрдә исә аларның үзләре белән очраша ала – Чебурашканы кочаклый яки яраткан язучысы белән селфи төшә.

Нәкъ менә биредә әти-әниләр, үсмерләр һәм нәниләрнең мәнфәгатьләре очраша: өлкәннәр балачак геройларын очрата, ә хәзерге заман персонажлары яшь китап укучыларның дөньясына атлый. Мондый вакыйгаларда гаилә үзара якыная, бер-берсен яхшырак аңлый башлый, уртак мәдәни код барлыкка килә. Нәтиҗәдә, китап белем һәм хис-кичерешләр чыганагы гына түгел, ә гаилә белән бергәләп искә ала торган кадерле хатирәгә һәм чын маҗарага да әйләнә.

IV
семейный
книжный
фестиваль
ТАТ
ФЕ

МАМА
КАК ВЫРАСТИТЬ ИЗ МАЛЬЧИКА МУЖЧИНУ
КОРОЛЬ

Алиса Котова
Школа
для двоечников

КАЗАНДА УКЫЙ ТОРГАН ХАЛЫК ЯШИ

Мария Сидлер, балалар язучысы:

–Яшь китап укучылар һәм аларның әти-әниләре китапка бик таләпчән мөнәсәбәттә хәзер. Елдан-ел бу таләпләр арта гына, мин барлык эре китап фестивальләрендә диярлек өч ел рәттән катнашам инде. Ул һәрнәрсәгә кагыла: басманың сыйфатына, шрифтка, рәсемнәргә, китапта кызыклы фишкаларга. Гаджетлар заманында балаларны әйбәт текст белән генә мавыктырып булмый. Китап үзе гаджет ролендә булырга тиеш. Минем ике китабымны һәм төрле җыентыкларда хикәяләремне чыгарган «Вверх!» нәшрияты, мәсәлән, юкка гына китапка интерактив элементлар кертүгә басым ясамый. Мәсәлән, «Киләчәктә очрашырбыз!» дигән китабым скетбук форматында дөнья күрде. Ул классик төпләмә урынына пружинага утыртылды, анда 22 гасырда сәяхәт иткән ике игезәкнең кызыклы тарихларыннан тыш, креатив биремнәр дә бар, укучы үзен дә фантаст итеп хис итә ала.

Ә «Юлбарыс малае эти эзли» китабында чын курчак театры урын алды – тышлык театраль пәрдәгә әйләнә, китап белән бергә геройларның фигуралары да сатыла. Китапны укып кына калмыйсың, ә аның белән уйнап та була.

«Тау Фест» фестивалендә беренче тапкыр катнашам. Мине Р. Миңнуллин исемендәге Республика балалар китапханәсе «Фантастлар лабораториясе»нә чакырды. Мин ике көнне дә фестивальгә килүчеләр белән аралаштым – күпләр өчен китапны сатып алганда, авторның имзасын алу һәм китап турында, аны булдыручылар турында күбрәк белү хәлиткеч роль уйный икән.

Казанда укый торган халык яши, китаплар белән кызыксынулары күренеп тора. Балалар рәхәтләнеп китаплар актарды, рәсемнәрен карады. Күпчелек әти-әниләрнең балаларына китапны үзенә сайлап алу мөмкинлеге бирүе шатлыклы. Гомумән, бәйрәм атмосферасы бар иде, миңа калса, китап фестивалендә ул шулай булырга тиеш тә.

Дүшәмбедән без сентябрьгә керәбез, ә аның белән укулар башлана. Ышанасы да килми.

Мин Казанны бик яратам, бирегә еш киләм. Якты, матур шәһәр һәм фестиваль аңа бик килешә. «Елмай» паркы да бары тик уңай хисләр генә уятты – матур да, уңайлы да. Оештыручылар бөтен үтенечләргә бик игътибарлы булды. Фестивальдә катнашуымнан канәгать калдым. Тагын киләчәкмен әле!

«ИКЕЛЕ КАПЧЫКЛАРЫ ӨЧЕН МӘКТӘП»

Иң күңеллесе «Икеле капчыклары өчен мәктәп» китабын тәкъдим итү булды. Анда барысы да сыйныфларының уку дәрәҗәсен генә түгел, бөтен мәктәпне оятка калдыра торган гадәти икеле капчыклары белән нәрсә булырга мөмкин икәнне белде. Тагын икеле капчыкларын ничек итеп дөньядагы иң кулай ысул ярдәмендә бишлегә укытып булуын да белделәр.

Бу китапның нәрсә турында икәнлеген «Татарстан» журналының баш мөхәррире, Алиса Котова тәхәллүсе белән язучы автор үзе сөйләде:

- Икеле капчыклары төркемен начар укыган өчен үз мәктәпләреннән «Икеле капчыклары өчен мәктәп»кә куганнар. Аларның андагы маҗаралары үз эченә менә нәрсәләрне алган:

- куркыныч серләрне (алар аны уңышлы ача);
- җир асты юлларын (алар аны уңышлы уза);
- адым саен сагалап торган искиткеч ачышларны;
- дәрес саен сагалап торган көтелмәгән бишлеләрне;
- үзеннән-үзе телгә килгән һәм табылган нәтиҗәләр белән әхлак кагыйдәләрен;
- һәм мәхәббәтне – алар яшендә аннан башка буламы соң инде?

УРАКЧЫ: КҮҢЕЛЕҢ КИҢ БУЛСА...



УРАКЧЫ

Без сәфәргә кузгалган көнне урамда егерме биш градус эссе иде. Югыйсә сентябрьнең икенче атнасы бара, ә табигатьтә әле һаман җәй хакимлек итә. Чистай районының Уракчы авылына барышыбыз. Мондый авылны сайлавыбыз юкка түгел, кырларда урак өсте бит. Уракчыда да урак өсте гөрлиме икән?

Руфия Фазылова

Фото: Лилиана Вәлитова

«ГРАНТЛАР ОТАБЫЗ!»

Уракчы чагыштырмача яшь авыл, 1928 елда оешкан. Ул елларда Татар Талкышыннан берьюлы биш кечкенә авыл аерылып чыга. Аларның инде икесе юк та икән, ә менә өчесе матур гына яшәп килә, шул исәптән Уракчы авылы да. Бүген монда 135 кеше гомер итә, 50 хуҗалык бар. Социаль объектлардан ФАП, клуб эшли. Ә менә башлангыч мәктәп ябылган, кибет тә юк. Авылга ямь биреп торучы җир мәчет кебек тоелды, тирә-юне чәчәккә күмелгән, һәр көн ир-атлар биш вакыт намазга җыела монда...

1928 елда Уракчы ике урам булып оеша һәм ул бүген дә шулай. Йөз ел эчендә йортлар үзгәрсә дә, яшел хәтфә чирәм шул ук калган. (Бу чирәмгә бала чактагы кебек ятып ауныйсы килде, хәзер авылларда мондый яшеллек бик юк бит.) Урам башында күл җәелеп ята, әлегә ул каз-үрдәкләр өчен хезмәт итә. Тик киләсе елга инде бу урын ял үзәге булырга тиеш икән.

– Ел саен дәүләт грантларында катнашабыз, – диде Татар Сарсазы авыл җирлеге башлыгы Салих Мусин. – Һәм җиңәбез дә. Өч-дүрт ел эчендә генә дә Уракчы авылында балалар өчен махсус бау паркы, футбол уйнар өчен заманча спорт мәйданы эшләдек. Беренчесе – «Шүрәле» паркы, икенчесе «Батыр» дип атала. Ә киләсе елга күлне төзекләндерергә исәп. Башта төбен чистартып,

– Өч-дүрт ел эчендә генә дә Уракчы авылында балалар өчен махсус бау паркы, футбол уйнар өчен заманча спорт мәйданы эшләдек, – диде Татар Сарсазы авыл җирлеге башлыгы Салих Мусин.

чишмә юлларын ачып җибәрергә кирәк. Аннары, балыклар үрчетеп, күлнең тирә-ягында шашлык пешерү урыннары ясарга уйлыйбыз. Аны «Яшьлек паркы» дип атарга ниятлибез. Якынча 5 миллион сумга төшәчәк. Болар инде барысы да документлаштырылган, чөнки грантка биргәндә шактый күп кәгазь тутырырга туры килә. Авылдашыбыз икътисад фәннәре докторы Асия Галимовага рәхмәт, ул Чистайда яши, югары уку йортында белем бирә. Документларны бергәләп эшләдек, чөнки Асия Камилевна аның тәртибен яхшы белә. Әле күптән түгел генә билгеле булды: «Яшьлек паркы»н төзекләндерүгә грант отканбыз. Димәк, язга бик зурлап эшкә тотыначакбыз. Безнең монда барысы да комплекслы итеп уйланылган: спорт мәйданчыклары, ял итү урыны – бөтенесе бер җирдә. Грантка документлар тапшырганда болар бик мөһим, чөнки анда конкурс бик зур. Проектны яклаганда, аның үзенчәлеге булырга

Уракчының иң эре фермеры – Бадыйгиннарның да җирләре юк. Дөрес, район администрациясе аларга, 49 елга дип, арендага 77 гектар җир биргән. Һәм фермер шуңа да бик канәгать.

тиеш. Ничә еллар шул конкурсларда катнашкач, тәртибен аңлап бетердек кебек.

Авыл башында тагын бер матур җир бар – ул да булса кое. «Торна сазы» дигән язу олы юлдан килгәндә үк күренеп тора. Уракчы кешеләре генә түгел, күрше авыллардан да киләләр икән: коеның суы шифалы, тикшерткәннәр. Суның составы турындагы рәсми мәгълүматны да шунда ук язып куйганнар.

– Ә ни өчен «Торна сазы», монда торналар бармы әллә? – дим Салих Сәйдәшевичка.

– Бабайлар сөйләве буенча, бу урынга элек гел торналар килә торган булган. Дөрес, соңгы елларда күренмиләр. Ләкин кем белгән, бәлки торналар яңадан кайтыр. Мондый матур урынны алар, һичшиксез, яратырга тиеш.

«ПАЙ ҖИРЕБЕЗ ЮК!»

Уракчы гомергә тырышлыгы белән аерылып торган. Әле колхозлар чорында ук районда иң зур уңышны биредә алганнар. Бөтен хикмәт – халыкның эш сөючәнлегендә. Һәм уракчылылар эчкерсез дә. Әнә шуның өчен пай җирләрсез калганнар да. Әйе, җирле халыкның пай җирләре юк. Сәбәбе бик гади – 1980 елда Уракчыны «Роман» совхозына кушалар. Дөрес, башта халык бик нык сөенә, чөнки эшләгән өчен яхшы гына хезмәт хакы алалар. Фермалар гөрләп тора, кырларда элиталы орлыклы ашлык үсә. Тик 90 нчы елларда совхозның көймәсе комга терәлә, нәтиҗәдә ул банкрота чыга. Ә җирләр шәхси кулларга күчә. Шулай итеп кайчандыр ата-бабаларына бүленеп биргән җирләр рәсми рәвештә юкка чыга. Башта халык моңа әллә ни игътибар да итми, янәсе, дәүләт ташламас. Җирсез калганнарын алар соңрак, күрше авыллар пай җирләрен рәсмиләштерә башлагач кына аңлыйлар. Тик инде бернәрсә дә үзгәртә алмыйлар. (Бу проблема бер Чистайда гына түгел, Балтач, Югары Ослан, республиканың башка районнарында да бар. Совхоз булган авылларда халыкка пай җире бирелмәгән. Әлеге проблема турында «Татарстан» журналы язган иде).

Уракчының иң эре фермеры – Бадыйгиннарның да җирләре юк. Дөрес, район администрациясе аларга, 49 елга дип, арендага 77 гектар җир биргән. Һәм фермер шуңа да бик канәгать.

– Безгә шул җир җитә, – диде Мөнир Бадыйгин. – Шунысын эшкәртергә сәламәтлек җитсен. Дөрес, җир булмаганга, үз вакытында дәүләттән грант ала алмадым. Шуның өчен дә ферманы фәкать үз акчабызга эшләдек. Гомер буе мал асрыйбыз, ә фермерлык эшендә 2015 елдан бирле. КФХ булып теркәлдек без. Аңа кадәр колхозда хезмәт куйдым, ферма мөдире дә булдым. Аннары инде, дөньялар үзгәргәч, үзебезгә эшли башладык. Төп ярдәмчем – олы улым, ул өйләнде, безнең янда калды.

– Иген уңышы ничек? – дим.

– Шөкер, әйбәт. Ашлыкны амбарга алып кайтып урнаштырдык инде. Солы гектарыннан – 27 центнер, арпа 30 центнер чыкты. Игеннең бер өлешен сатабыз да.

Мөнир абыйның хәләл җефете Әлфинур апа авылда фельдшер ярдәмчесе булып хезмәт куя. Ләкин төп эше, әлбәттә, өйдә. Егерме ике сыерны саварга, кортын, эремчеген ясарга кирәк, әле итне чыгартып, фарш итеп тә саталар икән.

– Мөнир белән күршеләр идек без, – диде Әлфинур апа. – Гаилә корганга утыз дүрт ел булды. Ике ул үстердек, икесе дә гаиләле. Дүрт оныгыбыз бар, алар да малайлар. Авылда нәрсә, кул хезмәте инде. Гомергә эштән курыкмадык, балалар да үзебезгә охшаган. Менә хәзер киленнәр дә кушылды, бөтен эшне бергә башкарабыз. Яз, көз өйдә ирләрне күрмибез дә, басуда алар. Кышын инде җайлырак. Тик барыбер ир-атлар тик тормый: машина белән Чистайга барып сөт сатып кайталар.

Гомәровларның йорты чәчәккә күмелгән.

ГАРМУНЛЫ ЯШЬЛЕК

Авылның тагын бер матур гаиләсе белән таныштык – Гомәровлар. Йортта иң өлкән кеше Факия апа, күптән түгел 90 яшен тутырган. Әбекәй бик матур картлык кичерә: янәшәсендә улы Җәүдәт белән килене Мөнирә. Бу йортта көн саен биш вакыт намаз укыла, Җәүдәт абый – авылның мулласы. Хатын-кызлар да күптәннән диндә икән.

– Килен-каенана булып бер йортта 47 бергә яшибез, – дип сүз башлады Факия апа. – Мөнирә белән бер-беребезне аңлап көн итәбез. Сабыр булып, кайсын күрмәсәң, ишетмәсәң яшәп була ул. Ике яклап та шулай кирәк. Җәмәгатем бик иртә, кырык өч яшендә вафат булды. Балаларны ялгызым аякка бастырырга туры килде. Аллага шөкер, тәртипле булды балалар. Хәзер дә шулай, кайтып йөриләр, оныклар да өзелеп тора.

Факия апаның үсмер чагы Бөек Ватан сугышы елларына туры килә. 1943 елны Уракчы башлангыч мәктәбенә укырга керә, урта мәктәпне исә Чистайга барып укый. Һәм шуннан соң фермага эшкә керә.

– Әти сугышта хәбәрсез югалды, өйдә миннән кечкенә сеңелкәш, энекәшләр бар иде, ничек тә аларга ярдәм итәсем килде, – диде Факия апа. – Ун ел фермада эшләгәч, авылда китапханә ачылды. Урта белемең бар дип, мине шунда эшкә чакырдылар. Әнә шулай итеп, лаеклы ялга чыкканчы, китапханәдә хезмәт куйдым. Кечкенәдән китап укырга ярата идем, анда кергәч рәхәтләндем инде. Ул чорда китапханәгә йөрүче күп иде, башлангыч мәктәп булса да, иләләп бала укыды. Хәтерлим, 1960 нчы елларда бер йортта биш-алты бала иде. Рәхәт чаклар дип, гел искә алам хәзер. 90 нчы елларда инде халык саны күзгә күренеп кими башлады.

Факия апалар үзләре дә җиде бала үсә. Әниләре аларны кечкенәдән бәйләргә өйрәтә, шәл бәйләп саталар алар. Шуның белән йорт та салалар.

– Уракчыда тагын шәл бәйләүчеләр бар идеме? – дим.

– Үзе өчен генә бәйләүчеләр бар иде, әмма безнең кебек сатуга эшләмәде алар. Әни бик уңган, чиста иде, безне дә шуңа өйрәтте. Ирсез килеш җиде баланы аякка бастырырга кирәк булган, шуның өчен дә тырышкан инде.

Авылның акъәбисе белән истәлекләр барлап утырабыз. Гармун тавышлы яшьлеген бик сагына ул. Баксаң, сугыштан соң биредә бик күпләр гармунда уйнарга өйрәнгән. Йорт саен диярлек гармунчы булган.

– Хәзер авылда гармунчылар бармы? – дип сорыйм.

Әңгәмәгә Факия апаның улы Җәүдәт абый кушылды:

– Бик юк шул. Әле без үскәндә дә күпләр гармунда уйнады. Хәзер инде аның кешесе бик юк бит. Аннары, бүген кыйбла да башка, дин юлына бастык, Аллаһ кабул итсен.

– Мәчеткә йөрүчеләр күпме? – дим.

– Җомга намазында унбишләп кеше була, ә мондый вакытта җиде-сигез ир-ат йөри. 1 октябрьдән мәчеттә дин сабакларын укыта башлыйбыз, хатын-кызлар да, балалар да йөри. Мәчетебезне яңарттык, өстәп янкормалар салдык. Бик сөенәм инде.

Узган ел Җәүдәт абый җәмәгате белән хаҗга барып кайткан. Мөнирә апа авылда утыз ел почта ташучы булып эшләгән. Бүген бик яратып чәчәкләр үстерә. Мәчет бакчасын да шау чәчәккә күмгән.

ТАҖИКЛАР ЫРУЫ

Уракчының дүрт йортында таҗиклар яши, барлыгы егерме кеше икән. Һәм авыл кешеләре аларны бары тик яхшы яктан гына телгә алды.

Авылда иң беренче булып төпләнгән гаилә – Сәедовлар. Монда яши башлаганнарына өч ел узып киткән. Әлеге гаиләләр күп итеп яшелчә үстерә, мал асрый. Башта кәҗә генә тотсалар, хәзер сыерлар алганнар. Нигездә, малларны хатын-кызлар карый, ир-атлар эшкә йөри икән.

– Беренчедән, авыл халкына бик рәхмәтлебез, безне шундый җылы кабул иттеләр, – диде гаилә башлыгы Айситдин. – Уракчыда халык бик гади, балаларыбызны мәктәп автобусы килеп ала, кайтарып куя. Бу бит нинди олы хөрмәт! Татар Сарсазы мәктәбе коллективына да олы рәхмәтләремне җиткерәсем килә: балаларга яхшы белем бирәләр. Без монда үзебезне чит итеп тоймыйбыз.

Хуҗалар өйләренә чакырды. Монда күп нәрсә үзгә: идәнгә утырып ашыйлар, шунда ук йоклыйлар. Ул арада хатын-кызлар табын корды: сарык итеннән шулпа әзерләгәннәр һәм көлчә (лепешка) пешергәннәр.

– Бездә кунакны сыйламыйча җибәрсәң, хөрмәт итмәү санала, – диде хуҗабикә Михриниссо.

Баксаң, әлегә гаиләдә көн саен көлчә пешерәләр. Ишегалдында сарай ясап, шунда тандыр салып куйганнар. Хатын-кызлар учакны үзләре яга, көлчәне дә үзләр пешерә, ир-атлар күбрәк күзәтүче ролендә генә.

– Сез монда шундый күп, барыгыз да бер йортта яшиме? – дидем хуҗабикәгә.

– Юк, балалар күрше йортларда яши. Айситдин белән дүрт ул, бер кыз үстердек. Дүрт балабыз да монда, бер улыбыз гына Кытайда яши. Ул анда дәрәҗәле уку йортында белем ала. Аллага шөкер, балалар укымышлы безнең. Бер улыбыз Таҗикстанда медицина университетында алты ел белем алды, аннары КДМУда ике ел укыды. Хәзер Чистай район хастаханәсендә кардиолог булып эшли. Ул инде гаиләсе белән Чистайда. Нәкъ менә шул улыбыз безне бирегә яшәргә чакырды да.

– Татарстанда тормыш шартлары яхшыракмы? – дим.

– И, чагыштыра торган да түгел. Таҗикстанда авылларга газ, су кермәгән, хәтта утны да вакытлап кына бирәләр. Ә монда барысы да бар, җәннәт бу!

Сәедовлар хуҗалыгында ун сыер, җитмешләп сарык бар. Ашлыкны, печәнне сатып алалар. Ике улы, бер кызының гаиләсе – барысы бергә маллар карыйлар. Кыскасы, аш та, эш тә уртак бирегә.

Сәедовлар татарча сөйләшми, алай да кайбер сүзләрне аңлыйлар. Гаилә башлыгы көн саен Уракчы мәчетенә йөри, шуның өчен дә татарчаны ныграк өйрәнгән.

– Чистай районында таҗиклар шактый, – диде Айситдин Сәедов. – Безнең ыруның җитәкчесе Чистай мәчетләренең берсендә имам булып тора. Очрашкан саен ул безнең хәлләрне сораша. «Балаларыгызга да әйтегез: җирле халыкның телен, гореф-гадәтләрен өйрәнсеннәр. Без – килгән кешеләр, димәк, аларның законнарына буйсынырга тиешбез. Шул чакта гына татулык булачак», – дип киңәш бирә. Мин бу фикер белән тулысынча килешәм.

...Авыллар кечерәк булган саен халык татурак була, Уракчыга баргач, янә шуңа инанып кайттык. Хәтта авылдан чыгып киткән яшь буын да дуслык җепләрен өзми – туган нигезләренә кайткач, бергә җыелышалар, гаиләләре белән кунакка йөрешәләр икән. Ә бөтенләй белмәгән кешеләрне – таҗикларны үзләренеке итеп кабул итүләре янә бер гаҗәпләндерде. Эчкерсезлек, гадилек, изге күңелле булу – болар барысы да Уракчы авылы халкы турында.

Авылда иң беренче булып төпләнгән гаилә – Сәедовлар.



Ишегалдында сарай ясап, шунда тандыр салып куйганнар.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Октябрь революциясенә кадәр Татар Талкышы авылында 500 дән артык хуҗалык, 5 мәхәллә була. 1927 елда зур авылдан поселоклар ясау сәясәте башлана. Иң элек Чаткы авылы аерылып чыга. 1928 елда Уракчы оеша башлый. Ул Татар Талкышыннан биш чакрым ераклыктагы «Торна сазы» дип йөртелгән урынга күчә.

Ни өчен авылга Уракчы исеме бирелә соң? Элек-электән Талкыш халкы бу җирләргә килеп урак урган. Аларга карап халык: «Әнә, уракчылар кайта», – дип әйтә торган була. Нәтиҗәдә, шушы исем авылга бирелә дә.

«Талкыш тарихы» китабыннан

МУЗЫКА ДӨНЬЯСЫНДА (6+)

Популяр классика һәм заман авторлары иҗаты, оригиналь эшкәртүдәге халык көйләре, чит ил һәм үзебезнең эстрада хитлары... Россиянең халык артисты Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге Татарстан Республикасының Дәүләт халык музыка уен кораллары ансамбле XXXII сезоны ачылышын музыка сөючеләр өчен чын мәгънәсендә бәйрәм тантанасына әйләндерәчәк. Программаның махсус кунагы – бик күп халыкара бәйгеләр лауреаты Фёдор Орлов (фортепиано, Мәскәү).

18 сентябрь, 18:30

Г.Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе, Казан, Павлюхин ур., 73 йорт

ГҮЗӘЛ ЭПОХАДАН – РЕНУАР, МАТИСС, ҺӘМ ПИКАССО (12+)

Дәүләт Эрмитажыннан читкә сирәк чыга торган җәүһәрләрне «Гүзәл Эпоха. XIX гасыр азагы – XX гасыр башы Европа сәнгате» күргәзмәсендә күрергә була. Экспозициядә Дәүләт Эрмитажы тупланмасында сакланган рәссамнарның 175 эшен тәкъдим итәләр. Камиль Писсарро, Клод Моне, Поль Гоген, Андре Дерен, Огюст Ренуар, Анри Море, Альфред Сислей, Поль Сезанн, Анри Матисс, Пабло Пикассо, Анри Руссо, Альфред Моурер, Альфонс Муха, Анри де Тулуз-Лотрек, Эжен Грассе һәм башка бөек осталарның картиналары – сәнгать сөючеләр өчен зур бүләк. Барлык картиналар да Гүзәл эпоха, яки Belle Epoque дәверендә – XIX гасыр ахырыннан алып 1914 елга кадәр иҗат ителгән. Бу – Европаның ваемсыз, имин чаклары. Бәрәкәт, муллык, тынычлык чәчәк аткан чор. Бигрәк тә Франциянең бәхетле еллары, нәкъ менә ул Belle Epoque бишегенә әверелә дә инде. Күргәзмәдә сез рәсем сәнгате, графика, декоратив-гамәли сәнгатькә караган әсәрләр белән таныша алачаксыз.

Көн саен 10:00 дән алып 18:00 га кадәр (җомга 11:00 дән 20:00 гә кадәр). Ял көне – дүшәмбе

«Эрмитаж-Казан» үзәге, 3 нче кат

«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

АЛМАЗЛАР, САФ КИЛЕШ ТАБЫЛГАН КАЗЫЛМАЛАР, БРИЛЛИАНТЛАР (12+)

2020 елда «Юбилейная» трубка» чыганагында табып алынган 69,87 карат авырлыктагы алмазны һәм гаять сирәк очрый торган казылмалар белән кыйммәтле ташларны, затлы, зәвыклы зәркән эшләнмәләрен «Якутия хәзинәләре. Казан – 2025» күргәзмәсендә күрә аласыз. Экспозициядә – Саха Республикасының (Якутия) уникаль мирасы. Аны карап туеп булмый. Атаклы якут алмазлары һәм бриллиантларыннан кала, монда борынгы ышануларга, мифологиягә бәйле артефактлар да урын алган. Шулай ук – традицион костюмнар, бизәнү әйберләре, мамонт сөягеннән әзерләнгән эшләнмәләр, көнкүреш предметлары.

28 сентябрьгә кадәр

Көн саен 11:00 дән алып 18:00 гә кадәр

Җомга көнне 11:00 дән алып 20:00 гә кадәр

Кабул итү урыннары Күргәзмә заллары, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

Фото: kazan-kremlin.ru, tinchurinteatr.ru, tatfil.ru, kamalteatr.ru, tatar-inform.ru

ОРГАН, КУРАЙ ҺӘМ ДУДУК. БОЛАР БЕРГӘ НИЧЕК КИСЕШӘ? (6+)

Дудук уен коралында уйнала торган музыка кешелекнең матди булмаган мәдәнияте һәм халык авыз иҗаты байлыгы җәүһәре санала. Курай исә безне татар мәдәниятенең борынгы тамырларына кайтара. Ә Айгөл Гардисламова башкаруындагы яраткан татар көйләребез берәүне дә битараф калдырмаячак. Камал театры солистлары тәкъдим иткән музыкаль кичә кабатланмас аһәңнәре белән җәлеп итәчәк. Без яхшы белгән кадерле көйләр орган тембрлары, серле дудук моңнары һәм газиз курай тавышы белән кушылачак.

Программада татар халык җырлары, Р.Яхин, С.Рахманинов, М.Екмалян һәм Э.Низамов көйләре яңгыраячак.

28 сентябрьдә, Шәрык клубы залында
Г.Камал исем. Татар дәүләт Академия театры (яңа бина), Казан, һ. Такташ ур., 74 йорт

ХАЛЫК КӘСЕПЧЕЛЕГЕ. ҮТКӘНГЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕ (0+)

Әлеге күргәзмәдә халык иҗатының традицион үзәкләре һөнәрчеләре белән осталарының гаҗәеп эшләре тәкъдим ителә. Сүз Россия дәүләт һәм муниципаль музейларындагы уникаль экспонатлар турында бара. «Һөнәрчеләр шәһәре» интерактив зонасында рәссамнар иҗат серләре белән бүлешәчәк. «Җиңүгә ирешкән Россия – халык кәсепчелеге сәнгате» бәйгесе нәтиҗәләре буенча тупланган әлеге күргәзмә сезнең күңелегезгә дә хуш килми калмас. Экспозициядә индивидуаль осталарның да, 65 тән артык халык кәсепчелеге оешмаларының да эшләре тәкъдим ителәчәк. Болар барысы да Россиянең дистәләгән төбәгеннән җыелган хәзинә.

21 сентябрьгә кадәр
Көн сен 10:00 дән алып 18:00 гә кадәр, пәнҗешәмбе 11:00 дән алып 20:00 гә кадәр. Ял көне – дүшәмбе
ТР ДССМ «Хәзинә» Милли сәнгать галереясы, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

МАЙЯ ПЛИСЕЦКАЯНЫҢ АК МАГИЯСЕ (0+)

XX гасырның бөек балеринасы узган профессиональ юл – ул сынаулар, җиңүләр һәм яңалыкка омтылулар тарихы. Классик традиция белән куәтле индивидуальлекнең бербөтенгә берләшү үрнәге. Ә бию биредә кеше дәрте, рухы белән эчке ирекне тантанасына әверелә. Бахрушин исемендәге театр музее фондларыннан тупланган күргәзмәне оештыручылар рус балеты легендасы калдырган бай мирас белән танышырга чакыра. Экспозициянең алты бүлегендә тәкъдим ителгән 200 дән артык экспонат менә нәрсәләрдән гыйбарәт: фотографияләр, костюмнар, декоратив-гамәли сәнгать предметлары, Майя Плисецкаяның портретлары белән сыннары, уникаль архив материаллары. «Кабул итү урыннары Күргәзмә залларында Майя Плисецкаяга багышланган күргәзмәнең ачылышы – Казанның бөтен мәдәни җәмәгатьчелеге өчен зур вакыйга. Көч һәм грация, чын мәгънәсендә хөрлек символы – бөек балерина Плисецкая калдырган иҗат балет сәхнәсе кысаларыннан күпкә киңрәк һәм колачлырак. Бүген без бу мираска орынып карый алабыз, Бахрушин музеена әлеге мөмкинлек өчен рәхмәтебез чиксез», – ди «Казан Кремле» музей-тыюлыгы директоры Илнур Рәхимов.

Көн саен 10:00 дән алып 18:00 гә кадәр (җомга – 11:00 дән алып 20:00 гә кадәр)
Ял көне – дүшәмбе
Кабул итү урыннары Күргәзмә заллары, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

«ЙӨРӘККӘ ДӘ РЕМОНТ КИРӘК!» (12+)

Бу тарих бер җөмләгә сыеп бетә ала. Ул кранны көйләргә генә килә дә аның бөтен тормышын җайга сала, көйли. Югыйсә, инде бернәрсәгә дә өмет калмаган була... Төп героиняның яшәеше дә фатиры шикелле үк: тоташ бер авария. Җитмәсә, моңа көнчел ире тилмерткән дуамал дус хатыны, астагы каттагы шигырьләр язып һәм сөйләп йөрүче бабай, шәһәрнең өзлексез ыгы-зыгысы да килеп өстәлә... Тик ул гына юк – гомере буе көткән бердәнбере. Әмма очраклы бер танышу героиняның тормышын тамырыннан үзгәртәчәк! «Йөрәккә дә ремонт кирәк!» комедиясе тормыш мәгънәсен эзләү, ялгызлыктан ялыгу һәм качарга теләү, үзеңнең чын «мин»еңә сусау, кешеләргә ышанырга омтылу турында.

26 сентябрь, 18:30
К.Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Казан, Горький ур., 13 йорт

КАЗАНДА – «ПЕЧӘН БАЗАРЫ»

26-29 август көннәрендә башкалабыз Казанда «Печән базары» – шәһәр татар мәдәнияте һәм дизайны фестивале узды. Быел ул инде 13 нче тапкыр оештырылды һәм беренче мәртәбә дүрт көн дәвамында барды. Гадәттәгечә, «Печән базары» оештырылган төп мәйданчык Кабан күле яр буендагы Иске Татар бистәсе мәйданы булды.

Фото: Александр Ефремов; Салават Камалетдинов, «Татар-информ»

Быел фестиваль татар йортының традицион көнкүрешенә һәм аның заманча бизәлешенә багышланган иде. Шуңа күрә ассортимент та әлеге идеяне чагылдырды: киштәләрдә – агач эшләнмәләр, кулдан эшләнгән керамик савытлар, чигүле, бизәкле ашъяулыклар, өй өчен хуш исләр... Ярминкәдә 200 гә якын оста катнашты, аларның күбесе Казанга беренче тапкыр килгән.

Программада күргәзмәләр, фильмнар күрсәтү, балалар өчен мастер-класслар һәм башкалар оештырылды. Килгән кунаклар, шәһәрдәшләребез бәйрәмнән канәгать калды.

Сезгә дә фотохәбәрчебез сурәтләрендә чагылыш тапкан бәйрәм мизгелләрен тәкъдим итәбез.





Казаныбызда сакланып калган, тарихлары мәдәниятебезнең асыл шәхесләре белән бәйле агач йортлар белән таныштыруны дәвам итәбез. «Казанның агач йортлары» проектын «Татарстан» журналы «Татар ядкәрләре» шәхси оешмасы белән берлектә эшли.

БЕРЛЯНД–ФИЛИПСОН ЙОРТЫ: ЗАТЛЫ АРХИТЕКТУРА ҮРНӘГЕ

Луиза Янсуар, Фәнзилә Җәүһәрова

Казан үзәгендәге Волков урамы – борынгы агач төзелеш сәнгатенең гүзәл үрнәкләре белән заманча бетон йортларга каршы торучы уникаль җирлек. Бу саннан башлап, шушы урамга игътибарыбызны ныграк юнәлтербез. Беренче объект – Волков урамы, 66/17 адресы буенча урнашкан, элек-электән табиблар, галимнәр, профессорлар күпләп яшәгән, затлы бер рухны саклаган Берлянд-Филипсон йорты.

Фото: Александр Ефремов

ЙОРТНЫҢ БЕРЕНЧЕ ХУҖАЛАРЫ, ЯКИ ЯЗМЫШ БОРЫЛМАЛАРЫ

Аның тарихы 1900 елдан башлана. Йортны унтер-офицер Григорий Степанович Берлянд төзетә. 1910 елда дворяннар нәселеннән булган, Зөя дворяннар җыены җитәкчесе, аннары Казан губернасы земство җыены гласные Николай Николаевич Филипсон сатып ала. Шуңа да йорт икесенең дә фамилиясен саклап кала, шулай икеләтелгән атама буларак йөрүен дәвам итә.

Документлар буенча, Николай Филипсон йортка тоташкан участокны да сатып ала. Аңардан соң, йорт хуҗасы булып Сергей Николаевич Филипсон кала. Ул йортны үзгәртеп кора.

Сергей Филипсон әле Совет хөкүмәте урнашкач та йортның хуҗасы, ягъни «собственник» буларак теркәлгән. Ә аннары, 1923 елдан, йорт Агриппина Ивановна Филипсон кулына күчә. Документларда аның турында мәгълүматлар өзелә.

Инкыйлабтан соң, 20 нче елларда биредә табыш йорты оештыралар. Фатирларга яңа гаиләләр, башлыча, инде сугыштан соң килеп урнаша. Соңыннан бу йортның, «доляларга» бүленеп, әллә ничә хуҗага теркәлгән булуы да ачыклана...

ВОЛОНТЕРЛАР КАНАТЫ АСТЫНДА, ЯКИ МЕДИНСКИЙ ҮЗЕ ОРЫНГАН КОЙМА

Берлянд-Филипсон йорты, Казанның шул чор архитектурасына хас булганча, симметрик фасадлы. Аның тышкы бизәлеше гаять үзенчәлекле: ышкы ярдәмендә катлаулы технология белән уеп эшләнгән рельефлы бизәкләр төшереп ясалган ул. Фатирларның эчендә, инде хәзерге көндә кулланылмаса да, җылыту, ашарга пешерү мичләре сакланып калган.

Йорт үзе тыштан караганда нык күренә. Әмма аның түбәсе, су агу җайланмалары, канализация системасы, нигезе капиталь төзекләндерүне сорый.

2016 елга, ягъни «Том Сойер Фест» волонтерларының игелекле хәрәкәтенә кадәр, йорт беркайчан да төзекләндерелмәгән була. Фестиваль кысаларында аның тышкы ягы буялып, бизәкле тәрәзәләре тәртипкә китерелә, яңартыла.

Мондагы йортлар арасындагы агач койма да төзекләндерелә һәм буяла. Волков урамындагы бу йортларны буяганда, ул чактагы Россия Федерациясе мәдәният министры Владимир Мединскийның да кулы орынган, дип сөйлиләр. Һәрхәлдә, массакүләм матбугат чараларында аның бу урамда «Том Сойер Фест» кысаларында катнашканы, волонтерлар арасында булышып йөргәне фотоларда теркәлеп калган.





«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫН САТЫП АЛЫРГА

ozon.ru

market.yandex.ru

tatmedia.shop/ru

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНДА РЕКЛАМА БИРЕРГӘ

Рәссам Л. Гамбургер эше. 1925 ел

«Татарстан» журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9033-132-741

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ЯҢАЛЫКЛАРЫН УКЫРГА

protatarstan.ru

t.me/pro_tatarstan

vk.com/protatarstann

Реклама 16+